

ТАҺИР КӘРИМ

# ҮТКӘННӘРЕН БЕЛ КАТАЙНЫҢ

ТАҺИР КӘРИМ

# ҮТКӘННӘРЕН БЕЛ КАТАЙНЫҢ

Башкортстанның Бакалы районы

Катай авылы тарихы

Казан
«Яз» нәшрияты
2018

ББК 63.3
К95

**Кәримов Т.Т.**
**К95** Үткәннәрен бел Катайның. – Казан: Яз, 2018. – 224 б., төс. илл. белән.

978-5-9500696-6-6

Тарихчы-галим һәм язучы чираттагы хезмәтендә туган авылы Катайның XVII гасыр ахырыннан XXI гасыр башына кадәр тарихын бәян итә. 1999 елда язылган, яңа чыганаклар белән тулыландырылган бу китап авторның 30 елга якын фәнни эзләнүләрен йомгаклый. Зур хезмәтнең тагын бер нәтиҗәсе – «Җиде бабаңны бел, катайлым» исемле китабы, ул киләсе елга дөнья күрәчәк.

ISBN 978-5-9500696-6-6

© Кәримов Т.Т., 2018
© «Яз» нәшрияты, 2018

## Сүз башы

Туган авылым, газиз җирем... Зур мәгънәле, һәрберебез өчен кадерле сүзләр. Уйлап карасаң, күпме истәлекләр, күпме күңелле мизгелләр бәйле туган җир белән! Шуңадыр да, форсат чыгу белән, ераклардан ашкынып, сагынып кайтабыз ата-бабайлар нигезенә.

Туган җир үткән чорларда яшәгән бабаларыбызның, алар катнашкан вакыйгаларның тарихы белән дә истәлекле. Бала чакта без бу хакта имеш-мимешләргә, ата-бабалар сөйләгәннәргә генә таянып белә, фикер йөртә идек. Бабаларыбыз тормыш мәшәкатьләреннән арына алмыйча, китап язу турында уйламаганмы яисә язганын да бастыра алмыйча югалтканмы, алар гомер иткән ерак чорлардан безгә кулга алып укырлык бернинди язма истәлек калмаган, шәҗәрәләребез дә юкка чыккан. Тарихыбыз өйрәнелсен, язылсын өчен биниһая күп вакытлар, гасырларны эченә алган чорлар үтү кирәк булгандыр, күрәсең.

Туган авылыннан читтә, ерак тарафларда гомер итүче бу юллар авторына, архив ишекләрен киң ачып, күпсанлы документларны берәмтекләп өйрәнергә, шуларга таянып беренче тапкыр авылыбызның үткәннәрен күзалларга насыйп булган икән, бу – чор таләбе дә, язмыш кушуыдадыр. Үзең туып-үскән туган төбәк тарихын тирәнтен өйрәнү өчен дә биреләдер кебек тарихчы шөгыле.

Авылым тарихы кайсы чордан башлана, аңа кемнәр нигез салган кебек сораулар мине профессиональ тарихчы булып җитешкәнче үк кызыксындыра иде. Узган гасырның туксанынчы еллары уртасында бу сорауга күпмедер ачыклык кертеп, беренче тапкыр районыбыз газетасына зур мәкалә язып бастырдым. Гасыр ахырынарак авыл тарихының китап вариантын да эшләп, аны бастырып чыгарырга да уйлаган идем, тик насыйп булмады. Әмма аңа карап күңелне төшермәдем, эзләнүләрне дәвам иттем, китапка өр-яңа фактлар керттем, кайбер өлешен редакцияләдем.

Китаптан укучы төбәк тарихы буенча үзен кызыксындырган бик күп сорауларга җавап табар. Алай да кемнәргәдер андагы совет чорына караган мәгълүматлар аз, кайбер мөһим фактлар читтә калган кебек тоелырга мөмкин. Моңа җавап бер: искиткеч күп шәхесләрне, шанлы вакыйгаларны эченә алган тарихыбыз шундый зур ки, аны бер генә кеше белеп тә, өйрәнеп тә бетерә алмый. Китап белән танышкан авылдашларым, «без – катайлылар – тарихлы, бу җирдә тирән эзле», дип горурланып әйтсәләр, автор өчен шуннан да югары бәя булмаячак.

Катай авылына багышланган бу китап – Бакалы районы авыллары буенча минем икенче зур күләмле фәнни-популяр хезмәтем. 2002 елда Камышлы

авылы тарихына багышланган китабым дөнья күргән иде. Иске Куян һәм тагын берничә авыл тарихын да китап итеп бастырырга әзерли башладым. Якын араларда 1995 елда язылган «Бакалы төбәге тарихыннан очерклар» исемле хезмәтем дә китап киштәсендә урын алыр дип өметләнәм, аның бер өлеше район гәзитендә басылды инде.

Архив чыганакларын тирән өйрәнмичә, тарихны күрәләтә үз максатларында бозып язучылар күбәйде. Моңа мисал итеп кайбер язмаларны, мәсәлән, Мортаза Рәхимов фондының эчтәлеге белән безнең төбәккә кагылышлы «Кыргыз» һәм «Юрмый» кебек китапларын китерергә була. Әлеге китапларны язган иҗади төркем 1917 елга чаклы яшәгән җирле халыкның сословиесен милләт итеп күрсәтергә тырыша, архив документларындагы сословие сүзен бөтенләй кулланмый, шул сәбәпле укучыга дөрес юнәлеш бирми – тарихны аңлы рәвештә боза, милләтчел-сәяси заказ үти түгелме?

Без – 1917 елга чаклы башкорт, типтәр, ясаклы татар ише сословиеләргә кергән татарларның варислары, күзәнәкләрендә һәрвакыт татар үзаңы булган, милләтен сатмаган ата-бабаларыбыз алдында баш иябез. Ерак бабаларыбыз өчен сословие сүзе ят булмаган, китабымда бирелгән күпсанлы архив документларының копияләре моны дәлилли. Бу документларны авылдашларым-якташларым белсеннәр һәм татар үзаңын томаларга тырышучы кайбер башкорт милләтчеләренә кискен, дәлилле җавап бирсеннәр өчен мин аларны күпләп урнаштырдым, текстта ассызыклап үттем. Тарих барлык чыганакларга нигезләнгәндә генә гадел була, ул чыганакларның кайберләрен аңлы рәвештә яшерүчеләр гаделсезлек вә җинаять кыла, тарихи дөреслектән читкә китә.

# Без монда борын-борыннан

«Бер бик каты яудан соң, патша гаскәрләреннән качып, эз яздырып, безнең ата-бабайлар Чиләбе якларыннан ошбу якка килеп чыкканнар.

Катай карт – Катай нәселеннән. Аның ике улы булган. Бер улы Агыйдел буенда төпләнеп калган. Кече улы белән үзе бу тирәгә килеп утырган. Бу тирә Катай карт килгәндә үтеп чыккысыз урман булган. Агач бурап, өй салганнар, урман төпләп, әзрәк иген чәчкәннәр. Төп кәсепләре агач кисеп, дегет кайнату, агач күмере яндыру булган.

Рязань ягыннан, Ока буйларыннан, бер төркем халык күчеп килгән. [...]

Башкорт җирләренә марилар да килгән. Катай җиренә аларның Тукмак дигән бер карты башлап килеп утырган. Җирләр кысыла, азая башлагач, башкорт-типтәрләр мариларны хәзерге Тукбирде авылы ягына кысрыклап чыгарганнар. Элек авылның шәҗәрәсе дә булган, диләр»[1].

Әлеге риваятьне 1974 елда авылыбызның китапханәчесе Әлфия апа Хәйдәровадан танылган башкорт галиме һәм язучысы Гайса Хөсәенов язып алган булган.

Риваять – документ түгел, әмма аның төбендә тарихи чынбарлыкка нигезләнгән күпме тирән мәгънә, фәлсәфә ята. Чиләбе яклары да, Рязань җирләре дә кайчандыр татар биләмәләре булганлыгы тарихтан мәгълүм. Шуңа күрә безнең бабайларның бу төбәкләрне телгә алуы очраклы түгел.

«Без монда 1730 елдан бирле яшибез», дип әйткәннәр XIX гасыр урталарына караган бер документта Иске Катай «типтәр»ләре. Документта болай язылган:

Его Превосходительству господину командующему Башкирским войском!

Белебеевского уезда деревни Старой Катаевой, ***переименованного изъ тептярей въ башкирцы*** 13 кантона Мухутдина Бикташева

Прошение

Съ 1730 года предки мои вместе съ башкирцами Киргизской волости поселилисъ въ сказанной деревне Старой Катаевой [...].

Бу документ нәрсә уңаеннан язылган, ни өчен Катай «типтәр»ләре башкорт дип күрсәтелгән (документта «переименованного изъ тептярей въ башкирцы») – болар турында сөйләп тормыйбыз. Безнең өчен әһәмиятлесе – 1730 ел.

---

[1] Башкорт халык иҗады. II том.– Өфө, 1997, б.145, 146



Его Превосходительству,

Господину Командующему Башкирским войском!

Белебеевскаго уезда, деревни Старой Катаевой, ... Бикташева

Прошение

ЦѢНА 30 КОП.
СЕРЕБРОМЪ

**Документ күчермәсе. Башкортостан Үзәк дәүләт тарих архивы (алга таба – БҮДТА), И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 179 б.**

Документ никадәр игътибарга лаек булмасын, авыл 1730 елда нигезләнгән дип әйтү дөрес булмас. Килеп утырганнан бирле күпме буын алышынган, шуңа күрә чама белән генә әйткәннәрдер ерак бабаларыбыз.

Башка чыганаклар бабаларыбызның моннан күпкә алдарак килеп утырулары хакында сөйлиләр. 1727 елның 11 февраленә караган документ, мәсәлән, Кыргыз олысының Катай авылы «башкорт»ы Сөләй Досаевның (аның Әбелгази исемле улы 1737 елгы документта татар дип бирелә) һәм аның иптәшләренең өч йорт исәбеннән казнага ясак (шул чордагы салымның, ягъни налогның бер төре) түләүләре хакында сөйли. 1700 елда Катайдан берничә кеше хәзерге Татарстанның Баулы ягындагы Ташлы авылына күчеп утырган (бу хакта алдагы бүлектән кара). Димәк, авылның барлыкка килүе XVII гасырдан да соңрак



**Документ күчермәсе. БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 108 б.**



**Документ күчермәсе. БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 108 б.**

була алмый, ә бу чорга караган документлар сакланмау сәбәпле, аның кайсы елларда нигезләнүен дә төгәл күрсәтеп булмый.

Алга таба киткәнче, 1737 елгы документка аерым игътибар биреп үтик. Анда болай язылган: «1737 года марта в день Уфимского уезду Казанской дороги деревни Катаевой ***татаринъ*** Аблазей Сулеев в деревне Маты новокрещенъ Никита кобылу светло серую цена три рубли пошлинъ платилъ целовальникъ Филипъ Бабин».

Документ, бер яктан, Әбелгази Сөләевнең татарлыгын (ул – авылның «башкорт» ягындагы Күчемов фамилиялеләрнең ерак бабасы), икенче яктан, авылның территориаль яктан Уфа өязе Казан даругасына караганлыгын күрсәтә. Әйе, Казан, безнең өчен кадерле Казан, бүгенге көндә мин гомер иткән Казан!

Даруга – безнең борынгы дәүләтебез Алтын Урда чорыннан кулланылып килгән, территориаль берәмлекне аңлатучы сүз. Урысча «дорога» дип язылса да, аны «юл» дип тәрҗемә итү дөрес булмас.

Катай җирләре, Бакалы төбәгенең башка тарафлары кебек үк, беркайчан да хуҗасыз булмаган. Сакат, Мостафа якларындагы «нугай», «кыпчак», «урда» атамаларын гына алыйк, алар мондагы тарихның тирән гасырлар катламыннан килүен күрсәтә. Бу хакта озак итеп, тәфсилләп сөйләргә булыр иде, әмма максатыбыз ул түгел.

Катай тарихына кайтыйк. Архив документларыннан күренгәнчә, унҗиденче гасырда Бакалы төбәгендәге очсыз-кырыйсыз урманнарның, бик күптәннән кеше кулы тимәгән, буш яткан кыргый җирләрнең зур өлеше Кыргыз олысы «башкорт»лары карамагында була.

Монда кечкенә бер искәрмә ясыйк. Алга таба кулланылачак «башкорт» сүзе 1917 елга чаклы, беренче чиратта, сословиене аңлатканын укучы истә тотсын. Төрле милләт кешеләренең ничек итеп привилегияле бу сословиегә беркетелүләре тарихта мәгълүм факт. Шундый бер фактны мин Баулы авылы тарихын язганда күрсәтеп үттем. Катай авылы мисалында исә татар Әбелгази Сөләевнең оныклары «башкорт» Күчемов булып китүләре әлеге нәсел шәҗәрәсендә чагыла. Шуңа күрә бабаларыбыз рәсми документларда үзләрен «будучи я родом из ***башкирского сословия***» яисә «переименованного изъ тептярей въ башкирцы» дип язганнар икән, моңа аптырарга кирәкми, тарихны аңлап, дөрес вә гадел фикер йөртергә кирәк.



**Документ күчермәсе. БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 119 б.**

Унҗиденче гасырда олыс старшиналарының һәм аерым кешеләр-нең-биләмә хуҗаларының рөхсәтен алып, бергәләп ясак түләү шартына килешеп, монда башка як халкы да күчеп килә башлый. Күчеп килүчеләрнең бер өлеше типтәр сословиесенә языла. Типтәр сүзе чыгышы буенча дәфтәр сүзенә бәйле. Аерым дәфтәрләргә теркәлгәнлектән, аларны дәфтәргә язылганнар яисә типтәрләр дип әйткәннәр.

Катай авылы җирләренең бер өлешенә иң беренче килеп утыручылар әнә шул «типтәр»ләр, безнең мисалда Тукбирде авылы «типтәр»ләре (марилары яисә чирмешләре) була. Шуңа да Катайда алар белән бәйле атама – Кирәмәт тавы – сакланган.

Мариларның күчеп килүе урыс документында «Утакман» (риваятьтәге Тукмак карт, бәлки, шул буладыр) дип язылган кеше белән бәйле. Аның белән үзара сөйләшеп-килешеп Казыяр елгасы буена 1659 елда «ясаклы чирмеш» Бикбирде Тукбаев килеп утыра. Мондагы җирләр аңа охшаган, күрәсең, кияве Анчук Аклычевны да үзе янына чакыра, аннары башкаларны да[1].

Тора-бара күченүчеләр шактый җыела, алар кеше үтеп кермәслек куе урманнарны кисеп-төпләп, басу-көтүлекләргә әйләндерә, күп итеп мал асрый, иген игә башлый. Менә шулай Тукбирде авылы барлыкка килә. Тирә-ягы урман белән капланган, Маты елгасы буендагы иң биек нокта – Кирәмәт тавы берникадәр вакытка мәҗүсиләрнең үз алласына (кирәмәтенә) табыну урынына әйләнгән, күрәмсең.Күченеп килүчеләр арасында Катай Иштерәков (тексттагы документта 2 нче булып күрсәтелә.– *Т.К.*), Туктагол Тукбердин (Тукбирде картның улы; документта 5 нче.– *Т.К.*) һәм тагын дистәләп ир-ат нәселләре була. Алар барысы да гомерләренең соңгы көннәренә чаклы Тукбирде авылында яшәп, шунда дөнья куйганнар.

Тукбирде карт «Тукбирде» атамасы килеп чыгуга сәбәпче булган. Катай Иштерәковның «Катай» атамасына мөнәсәбәте бармы-юкмы, моны тәгаен ачыкларлык борынгы документлар юк. Иң әһәмиятлесе шул, мондый исемле кешеләр булган, димәк, риваятьнең авыл атамасын Катай карт исеме белән бәйләве дөрес.

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 72 б., 82 б. а.



**Документ күчермәсе. 1747–1762 елларда вафат булганнар исемлеге; Россия борынгы актлар дәүләт архивы (алга таба – РБАДА), 350 ф., 2 тасв., 3801 сакл. бер., 468 б.**

1753 елда катайлылар – мулла Мерәс Габитов, Арысланбәк Якупов, Яумәт Юлмәтов, Азамат Дәүәтиев, Дәүләт Суюшев, Йөзәй Мәннәев, Даут Сөләйманов – үзләренең урманнарының бер өлешен Бәтке авылы «ясаклы татар»ларына (мулла Әдһәм Ибрашев, Муса Дусаев, Мәксүт Ишмәтов һәм Танатар





**Документ күчермәсе. БҮДТА, 172 ф., 1 тасв., 61 сакл. бер., 51, 52 бб.**


толмачемъ Мусульм[illegible]
1775 года Апреля 3 дня изъ Уфимской
провинциальной Канцеляріи Казанской
дороги Старшинѣ Абдулину Аитову
Содержанія присланныхъ
Слѣдующего канцеляріи Казанской
провинциальную
дороги Старшина [illegible] указовъ
рапортомъ Объявилъ что прошлого 1771
Года марта 22. [illegible] писаннымъ изъ оной
Канцеляріи указомъ велено Старшинамъ
Кучуму Сулеву Алдашу Моисееву
Баязиту Кильметеву Адначуму [illegible]
рову и ему Абдулину Аитову и [illegible]
цамъ бесписьменнымъ накрѣпко подтвер-

**Документ кучермәсе. БУДТА, И-172 ф., 1 тасв., 18 сакл. бер.**

Рсаевларга) саталар. Үзара килешү буенча, алар катайлыларга 5 сум түләргә һәм ел саен һәрбер хуҗалыктан 10 тиен оброк түләп барырга тиеш булалар. Әлеге документта күрсәтелгән кешеләр хәзерге Яңа Катайның Арысланбәк, Азамат, Күчем һәм Дәүләт нәселләренә карый (әлеге һәм башка нәселләр тарихы бу юллар авторының «Җиде бабаңны бел, катайлым» исемле китабында актыр-тылачак). Аңлашылганча, Арысланбәкнең атасы Якуп, Азаматныкы – Дәүәти булган. Ә менә Даут Сөләйманов (ул бу бүлек башында телгә алынган Сөләй Досаевның улы; Сөләйман исемен кыскартып, халык Сөләй дип кенә әйтә торган булган) Күчем нәселенә карый. Боларга өстәп шуны әйтик, Күчем – Сөләй (Сөләйман) Досаевның кече улы һәм Даут Сөләймановның бертуганы. Күчем Сөләев 1770 елларда старшина була.

1762 елда Россиядә III ревизия үткәрелә. Катайда 44 ир-ат «ясаклы татар» теркәлә[1].

Болар – Иске Катайның төп нәселләре (Табыш, Юлдаш, Ырсай, Йортбагыш, Моталлап, Рәмәй, Сайран һәм башкалар) булып киткәннәр. Алдарак әйткәнебезчә, бу тарафларга күчеп килүчеләрнең бер өлеше махсус дәфтәрләргә теркәп барылганлыктан, Катайның «ясаклы татар»лары типтәр (бу атама урысларның «дәфтәр» сүзен бозып әйтүдән барлыкка килгән) сословиесендә күрсәтелә башлыйлар.

Катайның калган халкы өстенлекле башкорт сословиесендә торганлыктан, алар 1762 елгы һәм аннан соңгы ревизия документларында күрсәтелми, бары тик 1816 елгы ревизиядә генә теркәлә.

[1] РБАДА, 350 ф., 2 тасв., 3801 сакл. бер., 446, 447 бб.

1774 елның кышы. Бакалы крепосте янында каты сугышлар бара. Февраль аенда монда баш күтәрүчеләрнең бригадиры Иван Степан улы Кузнецов һәлак була. Әле күптән түгел генә Салават Юлаев белән Көнгер шәһәрен штурмлауда катнашкан кыю атаман соңгы сулышын, шулай итеп, Бакалы җирендә ала. Мәгълүм булганча, Салават Юлаев шул штурм вакытында, 24 гыйнвар көнне каты яралана[1].

Бакалы крепосте стратегик әһәмиятле ныгытмаларның берсе булганга, баш күтәрүчеләрнең аны калдырып китәсе килми. И. И. Ульянов кул астында тупланган фетнәчеләр әлеге шәһәрчек тирәли ныгытмалар төзеп, хөкүмәт гаскәрләренә каршы хәлиткеч сугышларга әзерләнәләр. 12 март көнне генерал А. Л. Ларионов гаскәрләре һөҗүм итә, әмма зур каршылыкка очрап кире чигенергә мәҗбүр була. Туплар гөрселдәгән, бертуктаусыз мылтык аткан тавышлардан урманнардан гына диярлек торган бөтен тирә-юнь дер селкенеп торган, авылларда, шул исәптән, Катайда да бик күпләрне әледән-әле дога укырга мәҗбүр иткән бу көн.

Бөтен дарыны атып бетергәч кенә, баш күтәрүчеләр оешкан төстә шәһәрчекне калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Ларионов башкисәрләренә бары ике йөк туп ядрәләре генә кала. Генералның мәгълүматларына караганда, Бакалы ныгытмаларында аңа 500 гә якын фетнәче каршылык күрсәткән. Күпчелеге тирә-як авыл кешеләре – урыслар һәм керәшеннәр – булган.

18 март көнне Бакалыга үзенең командасы белән подполковник Михельсон да килеп җитә, монда генерал Ларионов гаскәрләре белән кушылып, башкисәрләр Уфага юл тоталар. 24 март көнне канкойгыч сугышлардан соң Уфа янында атаман Зарубин гаскәрен тар-мар иткәч, аннары берничә көннән хыянәтчел казаклар ярдәмендә фетнәчеләрнең җитәкчеләре И. Зарубин-Чика, И. Ульянов, И. Губановны һәм башкаларны да тотып алгач, подполковник Михельсон башкорт җирләрендәге фетнәне бастыруга керешә. Зарубин-Чика җиңелгәннән соң да әле Бакалы төбәге каршылык күрсәтүне дәвам иткән.

Катайның һәм тирә-як авылларның «ясаклы татар»лары да (аларның старшинасы Катайдан Табыш Абдуллин була) бу фетнәдән читтә калмый. Тик менә алар арасыннан кайсылары һәм ничек катнашкан, моны тәгаен ачыклап бул-


Есашных татар [старшины] Табыша Абдуллина в деревнях: Иш-
терякової 43, Тупысвой 42, Токтагуловой 46, Камаевой 45, Куче-
вой 40, Килкабызовой 42, Катаевой 44; Токбердиной черемис 78,
Куяновой 43, Сакытовой 45, Устимовой 35, Мяндеевой 8, Чюрюбае-
вой, что на речке Чюкас, 7, Ташлиной 70, Верхней Тошлиной 26,
Яитемировой 33, Кусады 42, Зириклиевой 43, Камышли 23, Заито-
вой 24, Битиковой 6, Круеевой 1; итого 786.

**1762 елда Катайда ясаклы татар сословиесендә 44 ир-ат була**

[1] *Гвоздикова И. М.* Салават Юлаев.– Уфа, 1992, б. 164.

мый. Фетнәчеләр турындагы 1774 елгы документта [сез аның ксерокүчермәсен текстта күрәсез; Крестьянская война 1773–1775 гг. на территории Башкирии. Сб. документов.– Уфа, 1975] авыллар (шул исәптән, Катай) буенча ир-атлар саны күрсәтелсә дә, ул бары тик III ревизия (1762 ел) вакытында исәпкә алынган кешеләргә генә карый булып чыкты.

Бишенче ревизия (1795 ел) вакытында Катай халкының бер өлеше «типтәр»ләр дип бирелә (укучы игътибар иткәндер, әле яңарак кына алар «ясаклы татар» дип күрсәтелә иде). Алар (64 ир-ат һәм 78 хатын-кыз) старшина Бикбатыр Биктимеров (ул Иске Куян авылында туып-үскән өлкән дустым Рәмил Әмир улы Ибәтуллинның ерак бабасы булып чыкты.– *Т.К.*) командасында исәпләнгәннәр. Болардан тыш, тагын 22 «башкорт» хуҗалыгы булып, анда 97 ир-ат һәм 100 хатын-кыз яшәгән. Авыл бу чорда Уфа наместничествосының Бәләбәй округына кергән[1].

Авылыбызның аксакалы, тарихыбыздан тирән мәгълүматлы Хәсән Шакировның сөйләвенә караганда, «башкорт»лар «ясаклы татар»лар белән бер чордарак, ниндидер фетнәдән соң килеп утырганнар. Әмма элек-электән Кыргыз олысында башкорт булып теркәлеп килгәнгә, мондагы җирләргә хокуклары зуррак була. «Без кыпчак-татардан башкорт булып киткәнбез, шуңа чын башкорт түгел», дип кистереп әйткән иде Хәсән абый бу юллар авторы белән очрашканда.

Катайның ясаклы татар, аннары типтәр булып теркәлеп килгән кешеләренең яртысыннан күбрәге (36 ир-ат һәм 47 хатын-кыз) XVIII гасыр ахырында башкорт сословиесенә язылмакчы була. Алар турында документта «оныя просятъ о выключке себя в ***башкирское звание***, о чем ныне производится в здешней


118

| № списка | Званіе селеній и людей | по 4й ревизии состояло: мужеска | женска | из того числа убыло: мужеска | женска | ныне ревизии лицо: мужеска | женска | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Катаевой | 22 | 20 | 4 | 9 | 28 | 31 | |
| 2 | [illegible] | 31 | 39 | 5 | 23 | 36 | 47 | оныя просят о выключке себя в башкирское звание о чем ныне производится в здешней палате и следствие |
| | | 53 | 59 | 9 | 32 | 64 | 78 | |

**Документ күчермәсе. БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 35 сакл. бер., 616 б.**

[1] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 34 сакл. бер., 211 б.а.– 213 б.а., 255–258 бб.; 35 сакл. бер., 616–630 бб.

расправе и суде изъследование» дип әйтелә. Әмма үтенечләре канәгатьләндерелми, типтәр булып калалар.

Алга китеп әйтик, XVIII гасыр ахырынарак башкорт сословиесенә язылырга тырышучылар күп, үтенечләре канәгатьләндерелгәннәр дә була. Мәсәлән, хәзерге Туймазы районына керүче Токтагул авылыннан берьюлы 43 ир-ат һәм 44 хатын-кыз 1795 елдан «башкорт» булып китәләр. Алар турында документта «оные выбыли по указу казенной палаты в ***башкирской род*** в 1795 году» дип әйтелә[1].

Өстенлеккә ия башкорт сословиесенә керергә омтылышның сәбәбе – куллана торган җирнең күләме аз булу, аны арттырырга теләү. Алга китеп әйтик, XVII ревизия (1816 ел) вакытында Катайда теркәлгән һәр ир-ат «башкорт-вотчинник»ка 40 дисәтинә җир бүленсә, «типтәр»гә нибары 15 дисәтинә тиеш була.

Уфа өязендәге фетнәләр хакимиятне мондагы халыкларны даими хәрби-казак күзәтүе астында тоту кирәклегенә этәрә. 1798 елның 10 апрелендә Оренбург губернасында (Катай шул губерна составында була) төбәк белән идарә итүнең кантон системасы кертелә. Барлык территория хәрби округларга (кантоннарга) бүленә. Кантон үз чиратында вак административ берәмлекләрдән – юрталардан торган. Әлеге система кертелү белән башкорт һәм мишәрләр хәрби сословие (казак) саналып, махсус төзелгән башкорт-мишәр гаскәрләре командованиесенә буйсына башлый. Хәрби хезмәт аларның төп вазифасына әйләнә һәм тулысынча үз исәпләренә-чыгымнарына башкарыла. Ел саен «башкорт» һәм мишәрләр чират буенча казак хезмәтенә, Россиянең көньяк чикләрен сакларга чакырылганнар. Типтәр сословиесендәге ир-атлар исә Оренбург шәһәрендәге ике мең атлы типтәр полкына чират буенча хәрби хезмәткә алынганнар һәм полк чыгымнарын түләргә мәҗбүр ителгәннәр.

Сүз уңаеннан әйтик, кантон системасы 1864 елга кадәр яши, ул бетерелгәнче «типтәр»ләр дә 1855 елдан башлап башкорт-мишәр гаскәрләре командованиесенә буйсындырылып, «яңа башкорт»лар булып китәләр (Иске Катайның метрикә кенәгәләрендә аларны нәкъ шулай яисә «башкорт» дип кенә язганнар, аерым алганда, 1892 елгы кенәгәдә). Шуңа күрә ерак бабаларыбыз үз сословиесен күрсәтеп документларда «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептяр») дип яза торган булганнар.

1816 елда Катай «типтәр»ләре (29 хуҗалыкта 93 ир-ат) – Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең 5 нче типтәр командасында, «башкорт»лар (46 хуҗалыкта 151 ир-ат һәм 137 хатын-кыз) исә 12 нче башкорт кантонында күрсәтелә. Шулай итеп, авыл бу чорда барлыгы 75 хуҗалыктан торган[2].

«Башкорт»лар исемлегендә 46 нчы хуҗалык булып кыргыз Исәнгилде Мингалиев (64) һәм төрек Акмирза Даутов (39) күрсәтелгән.

[1] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 34 сакл. бер., 370–372 бб.

[2] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 151 сакл. бер., 261 б.а.– 267 б.а.; 154 сакл. бер., 425 б.а.– 430 б.



**Документ күчермәсе. БҮДТА, И-138 ф., 2  тасв., 151 сакл. бер., 267 б.**

Каян килгән бу кешеләр һәм ни өчен «башкорт»лар исемлегендә? Моңа җавап бер: төрле сугышларда әсирлеккә төшкән бер өлеш мөселманнарны хөкүмәт башкорт сословиесенә язып, шул сословие кешеләре яшәгән авылларга урнаштыра торган булган.

Бу кешеләр монда ят саналгандыр: берсе, нәсел дә калдырмыйча, 1827 елда 75 яшьтә дөнья куя, икенчесе, рөхсәт алып, Царьград шәһәренә күчеп китә.

XVIII гасыр ахыры-XIX гасыр башларында Россиядә җир межалау үткәрелә («генеральное межевание земель»). Аның документлары Мәскәүдә, Россиянең борынгы актлар дәүләт архивында саклана. Әлеге документлардан күренгәнчә, Катай һәм Кыргыз олысына кергән тагын 9 авыл (Тыпый, Ишмәт, Туктагол, Камай, Иштирәк, Килкабыз, Корыч, Куян, Тукбирде һәм Балчыклы) бер дачага межалана. Бу дача шактый зур (64299 дисәтинә; 1 дисәтинә=1,09 гектар) территорияне биләгән. Аның күпчелеген урман (53272 дисәтинә), калган өлешен сөрүлек (5600), печәнлек (2873), ялан (2300) һәм йорт яны җирләре (281) алып торган.

Урманнарда (ә алар барлык биләмәләрнең 82,8% ы) җәнлекләрдән – аю, бүре, төлке, куян, сусар, ас, тиен, кошлардан көртлек, боҗыр, карчыга, лачын, сандугач, сыерчык, карабүрек (балан чыпчыгы), сары чыпчыклар тереклек иткән. Басуларда торна, тургай, бытбылдыклар өере-өере белән очып йөргән. Алабуга, чуртан, опты һәм башка балыкларга бай Маты һәм Казыяр елгаларында кыр үрдәкләрен, шөлди, чуллык кебек кошларны күрергә мөмкин булган.

Мондый бай табигать, билгеле, читтәге эшмәкәрләрне җәлеп итми калмый. Сәүдәгәр Мөхәммәтрәхим Вәлитов Кыргыз олысы «башкорт»лары белән килешү төзеп, Балчыклы авылы тирәсендәрәк урман эчендә поташ җитештерү заводы төзи. Моның өчен ул 15 зур чан сатып ала һәм аларны монда урнаштырып, эшчеләр яллап, күпләп поташ җитештерә башлый. Төп чимал – агач күп, аны кисеп, яндырып, көлен чаннарда кайнатып, поташ (селте үзлекләре булган

каты ак матдә) хәленә китергәннәр. Ел саен 3 мең пот поташ кайнатып, аны Казанга һәм Нижгарга (Мәкәрҗә ярминкәсенә) ташып, потын өч сумнан күн эшкәртү белән шөгыльләнүче эшмәкәрләргә сатканнар[1].

Урманнарны күпләп кисүчеләр-юк итүчеләр бер Вәлитов кына булмый. Бөгелмә өязенең Бәйрәкә авылыннан отставкадагы прапорщик Рәхмәтулла Гапсәлам улы Аетов 1801 елда ук Кыргыз олысы «башкорт»ларыннан договор нигезендә Корыч авылы яныннан урман сатып алып, поташ заводы төзи, аннары Тула сәүдәгәрләре Алексей һәм Иван Сазыкиннарга арендага бирә. Сазыкиннар егерме мең пот күләмендә «шадрик» яндыралар, нәтиҗәдә, бу яктагы табигатькә зур зыян килә. Корыч авылы уртасында урнашкан бу заводның калдык көле Маты елгасына аккан, суны пычратып, эчә алмаслык хәлгә китергән (ул заманнарда елга-чишмә суларын эчкәннәр, елгалар элеккеге чисталыгын югалта башлагач кына кое казырга мәҗбүр булганнар). Өстәвенә, елганы буып, рөхсәтсез-нисез тегермән дә салып куйганнар. Алар үзләрен шул кадәр иркен тотканнар ки, хәтта мичкә ясар өчен күпләп имән агачларын кисә башлаганнар. Бу эшкә Кусады авылында яшәүче туганнары Федор Сазыкинны да җәлеп иткәннәр. Сазыкиннарның башбаштаклыгына чик куюны сорап, катайлы «юртовой старшина» Габҗәлил Күчемов кантон түрәләре исеменә прошение яза. Бу хакта 1814 елда Оренбург губернасының хәрби губернаторы князь Г. С. Волконскийга хәбәр ителә. Тик бернинди чара күрелми, тагын да әрсезләнгән Сазыкиннар Габҗәлил старшинага үтерү белән яныйлар. Габҗәлил түзми, 1828 елда турыдан-туры Оренбург губернасының граждански губернаторы О. Л. Дебуга прошение яза. Әлеге прошениенең берәр нәтиҗәсе булганмы-юкмы, документта бу хакта әйтелми[2].

...Кайчандыр күпләп урман яндырылганны хәтерләтеп, завод кулы атамасы калган. Поташ заводы дип тә йөртелүче бу урын өлкәннәргә мәгълүм булырга тиеш, диеп язган идем 1999 елда. Хәзер бу атаманы ишетеп белүчеләр бөтенләй юктыр инде, өлкән буыннар белән алар белгән, кулланган атамалар да юкка чыга, калса да, шул китап битләрендә генә.

Катай авылының тирә-ягы файдалы казылмаларга да бай булган. Монда Осокин фамилияле эшмәкәрнең бакыр рудниклары урнашкан. Бакыр рудасын хөкүмәт указы белән аның үзенә беркетелгән эшчеләре Югары Троицк заводына көне-төне атлар белән ташыганнар. Кирәмәт тавында шул чордан калган бакыр базлары әлегә чаклы сакланган, дип язып алган идем моннан егерме ел элек картларның сөйләгәнен.

Әйтергә кирәк, Бәләбәй өязендәге тагын ике бакыр эретү заводының да (Түбән Троицк һәм Усень-Ивановскийдагы) хуҗасы Осокин булган. 1836 елда прапорщик Г. И. Осокин үзенең әлеге өч заводын поручик Д. Е. Бернардакига сата. Түбән Троицк заводы 1842 елда эшләүдән туктый, ә калган заводларда елына 11 мең пот (176 тонна) чиста бакыр җитештерелә. Аның 10 проценты

[1] БҮДТА, 1355 ф., 1 тасв., 929 сакл. бер., 159–163 б.
[2] БҮДТА, И-1 ф., 1 тасв., 719 сакл. бер., 151–153 б.

Екатеринбургның монета дворына акча сугарга җибәрелгән, калган өлеше Нижгар (Түбән Новгород) ярминкәсендә сатылган. 1866 елда Д. Е. Бернардаки үз заводларын казнага сата[1].

Игенче өчен төп байлык файдалы казылмалар түгел, ә урман-басулар. Җирне генераль межалау вакытында (XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы) Катай һәм Куян авыллары «типтәр»ләренең үз җирләренә хокукларын раслаучы документлары булмаулары ачыклана. Шул сәбәпле алар монда рөхсәтсез-килешүсез килеп утырган кебек булып чыга. Ә Тукбирде марилары үзләренең җиргә хокукын дәлилли алганнар. Алай гына да түгел, үз кулларындагы документларга таянып, мондагы биләмәләрдән ничек тели, шулай файдаланырга уйлыйлар. Менә шунда инде моңарчы дустанә яшәп килгән Катай һәм Куян авылы «типтәр»ләре белән тукбирделеләр арасында җир мәсьәләсе буенча әледән-әле ызгыш-талаш килеп чыга башлый.

Сүз нинди документлар турында бара? Мондагы җирләр, тукбирделеләр раслаганча, чынлап та, аларның милке саналамы? Тукбирделеләр җир бәхәсе вакытында XVII гасырның икенче яртысына караган бер документның күчермәсен (оригиналын түгел!) төп дәлил итеп күрсәткәннәр. Ул кәгазьдә сүз ясаклы чирмеш Бикбирде Тукбаевның ясак түләргә ярдәмгә үзенең кияве ясаклы бабыл Анчук Аклычевны чакыруы турында бара (аның турында бу бүлек башында әйтелгән иде). Әлеге 1659 елгы документтан Бикбирденең бу җирләргә Кыргыз олысы «башкорт»ы Утакман рөхсәтенә таянып, ясак түләү шарты белән генә килеп утыруы аңлашыла. Ә менә җир мариларга бүләк ителгәнме яисә алар аны сатып алганмы – бу хакта документта берни әйтелми.

Шуңа карамастан, бәхәсле җирнең варисы-хуҗасы итеп бары тик тукбирделеләр санала, һәм 1826 елда ул алар исеменә рәсмиләштерелә. Сенатның 4 нче департаменты 1827 елның 21 февралендә аларга 16 мең дисәтинә җир (өлешчә Катай, Куян һәм Минизә авылларыныкын да кертеп) межаларга карар чыгара. Озакламый Бәләбәйдән өяз землемеры Товарницкий килеп, җир чикләрен билгеләп тә китә.

Шуны гына көткәннәр диярсең, 1832 елда тукбирделеләр әлеге бәхәсле җирләрнең бер өлешен, ягъни 6000 дисәтинәсен Бәләбәйнең 3 нче гильдияле сәүдәгәрләре бертуган Алексей һәм Иван Сазыкиннарга сатып та җибәрәләр. Озак та үтми, шул ук сәүдәгәрләргә үз биләмәләреннән тагын 2000 дисәтинә өстәп бирәләр. Ә инде 1840 елда 20 мең сумга (ассигнация белән) Курск губернасы алпавыты титуляр советник Петр Синельниковка да 2000 дисәтинә җир саталар. Моңарчы үзләре файдаланып килгән якын-тирә урман-басуларның башка кулларга күчүе Катай һәм Куян халкын хафага сала. «Ник сатасыз, җирләребез болай да аз бит», дип тә карыйлар. Тукбирделеләр белән бу мәсьәләдә уртак тел таба алмагач, алар югары хакимияткә – Сенатка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булалар. Нәтиҗәдә, Сенат 1847 елның 30 июль карары белән Синель-

[1] *Г. Ф. Гудков, З. И. Гудкова.* Из истории южноуральских горных заводов XVIII–XIX веков. Часть вторая.– Уфа, 1993, б. 472–476.

никовка сатылган җирнең 1103 дисәтинәсен генә раслый. Тик тукбирделеләрнең моңа исләре китми, ахры. Сазыкинга тагын 900 дисәтинә җир сатмакчы булалар. Күршеләренең әлеге нияте Катай һәм Куян халкын тагын бер мәртәбә (бу юлы соңгы тапкыр) югары хакимияткә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә.

Тукбирделеләрнең Сазыкин-Синельниковлар белән алыш-биреше Катай һәм Куян авылларының биләмәләрен шактый кечерәйтә. Чит кулларга күчкән җирләрдән алар берничек тә файдалана алмый, чөнки хуҗаларыннан рөхсәт кирәк. Мәсьәләне хәл итүнең бердәнбер юлы итеп, югары хакимият 1842 елда бер өлеш халыкка яңа урыннан җир бүлеп бирергә карар чыгара. Кыргыз олысы «башкорт»ларының буш яткан, урман-куаклардан торган биләмәләре күп була, шуның бер өлеше Катай һәм Куян «башкорт»ларына тәгаенләнә («типтәр»ләргә кагылмыйлар, чөнки аларның башка барыр урыннары юк). Менә шулай 1842 елда катайлылардан – Яңа Катай, куянлылардан Яңа Куян (хәзерге Камышлытамак яисә Камышлы) авыллары барлыкка килә[1].

Маты елгасының уң ягы ул чакта тоташ урман булган. Күбрәк шомыртлыклардан торган агачларны төпләп, өр-яңадан хуҗалык корып җибәрергә туры килә күчеп утыручыларга. Сөрүлекләр авылдан унсигез-егерме чакрым ерак ике урыннан (Ишмәт һәм Чүмәлә Катайдан) бирелә, монысы да зур кыенлык


Киргизской волости дер. Новой-Катаевой
объ отдачѣ Титулярному Совѣтнику
Синельникову въ 12 лѣтнее оброчное со-
держание береговъ рѣчекъ Маты и Бура
для устройства мельницы.
Начато 7 Апрѣля 1852 года.
Кончено 28 Июня 1855 —

**Документ күчермәсе. БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 7174 сакл. бер.**

[1] *Таһир Кәримов*. Ата-бабалар иле Камышлы.– Казан, 2002; БҮДТА, И-351 фонд, 2 тасв., 5759 сакл. бер.

тудыра. Ишмәт янындагы җирләрне ата-бабаларыбыз соңыннан сатканнар, дип искә алганы булган иде Яңа Катай картларының.

«Иң башта Нөрмәтнең Кәрим дигән кешесе чыгып келәт салган да (авыл башында парник чокыры дип аталган җирнең икенче ягында), Тукбирдедән бер күк бияне алып кайтып суеп, элеп куйган икән. Марилар килеп тапканнар моны, шуннан Кәримне өч елга сөргенгә җибәргәннәр. Агачларны төпләп, яндырып, башкалар да күчә башлаганнар».

Бу риваятьне Хәсән абый Шакировтан язып алдым. Кызыксынып, шул чорда яшәгән кешеләр исемлеген карап чыгарга булдым. Чыннан да, анда Нөрмәтләрдән Кәрим дигән кеше күрсәтелә (тик исемен бозып, «Кәрип» дип язганнар). Димәк, бу риваять күпмедер дәрәҗәдә чынбарлыкны чагылдыра.

Югарыда телгә алынган Синельников 1852 елда яңа катайлылар белән 12 еллык срокка килешү төзеп, Маты елгасында үз тегермәнен булдыра. Тегермән ике як өчен дә отышлы була: Синельников авыл җәмгыятенә ел саен көмеш акча белән 12 сум түләп барырга, онны да халыкка кулай бәядән тартырга тиеш була. Алпавыт бу чорда «коллежский асессор» дигән дәрәҗәгә ия, Бөгә елгасы башында үз исемендәге хуторы (документта «Петровский хутор») була. Ул шундый ук килешүне Күгәрчен Бүләк авылы халкы белән дә төзеп Бөгә елгасында да тегермәнен булдыра.

Авыл тормышында әледән-әле үзгәрешләр булып тора: кемдер китә, кемдер килә. 1858 елда Оренбург казна палатасы («Оренбургская казенная палата») рөхсәте һәм фәрманы белән Яңа Катайдан мөәзин Таҗетдин Яугилдин (65 яшь) һәм аның икенче хатыныннан туган уллары Бәдретдин (27), Разетдин (24), Хөснетдин (18), Хисаметдин (10) – Килкабыз, мулла Габделгалләм Хисмәтуллин (58) һәм аның улы Габделхәлим (30) – Иске Куян, мөәзин Сафуан Әхмәтов (42) һәм аның улы Әхмәтхарис (9) – Рәҗәп, Сафуанның туганы Гарифулла Әхмәтов (28) Корыч авылларына күчеп утыралар. Әлеге фактлар Катайда дини гыйлемле, укымышлы кешеләрнең күп булуын, шуңа да башка авылларның аларны теләп чакыруларын күрсәтә.

Нәкъ шул чорда Иске Катай исемлегендә беренче тапкыр Вәлимөхәммәт Габделгазизов һәм Габденнасыйр Мостафин гаиләләре (алар Катайга 1811 елны Түбән Бишенде авылыннан килеп утырган) күрсәтелә[1].

Бу кешеләрнең сословиесе ревизия документларында «башкорт», метрикә кенәгәләрендә «иске башкорт» дип күрсәтелә. Кайбер истәлекләргә караганда, тору урыннары башта Чиялекулда, аннан соң гына Казыяр очында була.

Илленче елларда авылны моңарчы күрелмәгән бер вакыйга тетрәндерә: Иске Катайдан Ибәтулла Мәхмүтов (аңа 1859 елда 51 яшь) христиан диненә күчә. Чукынгач әлеге бәндә Иван Григорьев фамилиясе белән йөри. Хатыны – Ирина Ивановна (25), кызы Анна (2) исеме белән теркәлә[2].

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 207 б.; И-138 ф., 2 тасв., 522 сакл. бер.

[2] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 522 сакл. бер., 335, 336 бб.

Иманына хыянәт итәргә нәрсә мәҗбүр иткән, бу хакта белмибез, шуңа күрә фараз кылырга гына кала. Урыс хакимияте салымнардан иза чиккән мөселман халкының мохтаҗлыгыннан оста файдаланган – христиан диненә күчкәннәрне 3 елга салымнан да азат иткән, солдат хезмәтенә дә җәлеп итмәгән. Ибәтулла (Иван) солдатка алыну яше узгач чукына, димәк, аны бу адымга бер генә сәбәп этәргән – мохтаҗлык. Хөкүмәт чукынганнарны авылда калдырмый, урыс-керәшен арасына күчереп утырта (кире мөселманлыкка кайтмасыннар өчен махсус шулай эшләнә), шуңа күрә башка елларга караган Катай исемлекләрендә бу бәндә башкача күренми.

1870 елгы мәгълүматларга караганда, Иске Катайда 81 йорт, 314 ир-ат һәм 286 хатын-кыз була. Яңа Катайда бу вакытта 110 йортта 462 ир-ат һәм 403 хатын-кыз яши. Ике якта да берәр мәчет, икешәр су тегермәне эшли. Умартачылык киң үсеш алган. Яңа Катайда патока заводы эшли, ә Иске Катай башында Озынборын хуторы урнашкан[1].

Әйтеп үтелгән заводның хуҗасы – алпавыт А. П. Синельникова (бу фамилияле алдарак телгә алынган ир-атның варисы.– *Т.К.*). 1882 елда, мәсәлән, анда 2550 сумлык продукция (1500 пот) житештерелгән[2].




**Иске Катай авылының 1879 елгы планы. БҮДТА, 351 ф., 1 тасв., 2127 сакл. бер.**

---

[1] Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Уфимская губерния.

[2] Справочная книжка Уфимской губернии.– Уфа, 1883, б. 77.

...Озынборын хуторы атамасы онытылган, әдәбиятта гына калгандыр дип уйлый идем. Катай янында шундый исемле хутор булганын, без, яшь буын, белеп бетермәгәнбез, күрәсең. Нәселдәшем Хәмит Габдерәхим улы Маликовтан әлеге атаманы ишетү мине гаҗәпләндерде, баксаң, егерменче гасыр ахырында да хәтерлиләр икән аны.

Сүз уңаеннан әйтик, тукбирделеләрдән сатып алынган биләмәләр 1828 елда ук Озынборын хуторы исемендә аерым дача итеп межаланган була. Әлеге дачага берничә хутор (Михайлов, Егоров, Әхмәтов исемендәге) керә[1].

Гасыр ахырына авыл халкы шактый ишәя. 1896 елда Иске Катайда 488 ир-ат һәм 449 хатын-кыз, Яңа Катайда 704 ир-ат һәм 704 хатын-кыз яши. Авылның ике ягында да – икешәр мәчет, Иске Катайда – тегермән һәм тары-борай яргычы, Яңа Катайда икмәк запасы саклана торган магазин була. Бу вакытта Озынборын хуторының хуҗасы булып һаман да алпавыт Синельникова тора[2].

Икмәк запасы саклана торган магазин (урыс телендә «хлебозапасный магазин» дип языла) турында тулырак әйтеп үтми мөмкин түгелдер. Баштарак бу магазиннарны 1822 елгы патша указы нигезендә үз исәпләренә һәр олыс, ә 1875 елдан башлап һәр авыл җәмгыяте төзергә тиеш була, монда һәр хуҗалыктан бушлай җыелган икмәк саклана. Уңыш начар булып, ачлык башлану куркынычы туса, шунда сакланган икмәкне халыкка өләшергә тиеш булалар. Яхшы уңыш булган елларда магазиндагы запасны хуҗалыклардан җан башыннан ярты пот җыеп тулыландырып торганнар. Барлык запас җан башына 4 пот булса гына икмәк җыю туктатылып торган. Авыл халкы үз арасыннан магазин өчен җаваплы кеше («смотритель») билгеләгән, ул күпме һәм нинди икмәк җыелган, кемнең бурычы бар, барысын да халыкка җиткезеп торган. Магазин ике йозакка бикләнгән. Ачкычның берсе җаваплы кешедә, икенчесе старостада була. Икмәк әрәм-шәрәм ителсә, бозылса, урлана калса, алар суд алдында җавап бирергә тиеш булганнар.

Билгеле, икмәкне болай саклау мәшәкатьле була, тиешле шартлар үтәлмәгәндә бозылып яраксызга да әйләнгән. Бары тик дәүләт элеваторлары төзелеп, икмәк сәүдәсе дә зур үсеш алгач кына мондый магазиннарның кирәге калмый, 1910 елдан алар бетерелә.

Алдарак әйтеп үткән Озынборын хуторына кайтыйк. Хутор турында өстәмә мәгълүматларны архив документларыннан табабыз. 1896 елда 52 дисәтинә мәйданны алып торган хутор надворный советник хатыны Анна Петровна Серебрякова һәм надворный советник кызы Софья Петровна Серебрякова милке санала. Надворный советник кызы Анастасия Петровна Синельникова – 53, статский советник хатыны Надежда Петровна Чайковская 350 дисәтинә җир хуҗасы булалар[3].

---

[1] БҮДТА, И-1 ф., 1 тасв., 2589 сакл. бер.; И-338 ф., 2 тасв., 114 сакл. бер.

[2] Полный алфавитный список населенных мест Уфимской губернии.– Уфа, 1896, б. 432.

[3] БҮДТА, И-11 ф., 1 тасв., 340 сакл. бер., 62 б.

Истәлекләргә мөрәҗәгать итик. Хутор хуҗасы Петр Чайковский Киев шәһәреннән күчеп килгәнче хәрби врач булып хезмәт иткән. Бик усал булса да, уен-көлке яраткан. Аны эштән арып кайткан крестьяннарын тарантаска җигеп, кызлары белән яланнардан йөрүдән бик зур ләззәт тапкан, дип телдән-телгә, буын-буынга сөйли торган булганнар.

Алпавытның 4 кызы (Надежда, Вера, Анна һәм Софья) була. Өчесе кияүгә чыга, бер Софья гына ялгыз торып кала. Әти-әниләре, ирләре вафат булгач, кызлар бер-бер артлы бу имениегә даими торырга кайта башлаганнар. Җитәкчелек итү иң өлкәне Надеждага төшкән[1].

Чыннан да, бу кешеләрнең барысы диярлек, Вераны исәпләмәгәндә, моннан алдарак бирелгән архив мәгълүматлары белән раслана. Ә менә истәлекләрнең калган өлеше ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры киләдер, тәгаен әйтү авыр.

Алпавыт хуҗалыгында берничә хезмәтче бил бөккән. 1907 елдан Иске Катайдан 12 яшьлек Кәшифә Шәфикова да әти-әнисе белән монда эшкә ялланган. Ул сыерлар көтүчесе Киләйдән Егор картны, ат караучы Ислам бабайны, кучер Шакир бабайны хәтерли торган булган. Алпавыт кызларыннан урыс хәрефләрен өйрәнеп, авылда урысча сөйләшә белүче беренче кызлардан санала. 1917 елда Чайковскийлар Бакалыга күчәләр, аннан соңгы язмышлары билгеле түгел. Соңрак авыл кешеләре имениенең кирпечләренә кадәр сүтеп алып бетергәннәр[2].

Әлеге имение урыны хәзерге вакытта Бикләнде атамасы белән билгеле. Килкабызга баручы юлның сул ягында (күперне чыккач та) кала ул. Алпавыт килеп урнашу белән, бикләнде безнең бу якка бара торган юллар, дип әйткәннәр, имеш. Мәскәүдә саклаучы III ревизия (1762 ел) документында, Тукбирде һәм башка чирмеш авыллары белән, Бикләнде дип аталган авыл да күрсәтелә. Шуннан соң ул авыл башкача телгә алынмый, димәк, юкка чыккан. Атама тарихы шул авылга барып тоташа булса кирәк.

Катайга кайтыйк. Егерменче гасыр башларында да авылның үсеш темпы зур булып кала. 1906 елга караган статистик чыганактан күренгәнчә, Иске Катай хәзер 223 ихатадан, 574 ир-ат һәм 553 хатын-кыздан тора. Авыл ике мәхәлләгә бүленгән, аның аша земство тракты үткән. Яңа Катайда хуҗалыклар күбрәк – 321. Монда ике мәхәлләдә 751 ир-ат һәм 843 хатын-кыз исәпләнә.

Катайлылар өч бакалея кибетеннән файдаланганнар, аларның икесе авылның «типтәр» ягында урнашкан була (Иске Катайда 1909 елга кадәр бакалея кибетләрен Хәйдәр Шакиров һәм Даут Яхин тотуы мәгълүм). Икмәк запасы саклана торган кибет – Яңа Катайда, су тегермәне, тимерчелек һәм ярма яргыч Иске Катайда күрсәтелә.

Катай бу чорда да Уфа губернасы Бәләбәй өязе Корыч олысына керә. Әлеге олыста ул чорда тагын Базы-Куян (591 кешедән тора), Балчыклы (259), Иске Куян (591), Ишмәт (35), Иштирәк (1289), Кадер (1386), Камай (925), Камыш-

[1] *Әлфия Хәйдәрова*. Катай авылы тарихы. Кульязма. 1967 ел.

[2] *Әлфия Хәйдәрова*. Катай авылы тарихы. Кульязма. 1967 ел.




**1901 елгы карта фрагменты**

лытамак (645), Килкабыз (1197), Корыч (2275), Сеңгерән (1068), Туктагол (1184), Тыпый (1722), Яңа Останково (619), Үрмәт (1743) авыллары, Афанас поселогы (89) һәм 8 хутор (Александров, Михайлов, Дәүләтшин, Чайковский, Якунин, калган өчесе Видинеевларныкы) була, барлыгы 18375 кеше (9477 ир-ат һәм 8898 хатын-кыз) яши. Катай янындагы хуторда (исеме «Чайковский» дип күрсәтелә) бары бер йорт булып, анда ике хатын-кыз исәпләнгән[1].

Катайлылар өчен иң якын базар Бакалыда була. Ул һәр дүшәмбе көнне эшләгән, биредә елга ике тапкыр (22 октябрьдә һәм 2 февральдә) зур ярминкә дә үткәрелгән. Аптекасы, земство шифаханәсе белән дә Бакалы башка авыллардан аерылып торган. Ул чорда Корыч олысына керүче Үрмәттә базар шимбә көннәрне, ярминкә 2 сентябрьдә уза торган булган.

1912—1913 елда хуҗалыклар исәбен алу вакытында Иске Катайда 280 хуҗалыкта 1391 кеше (747 ир-ат һәм 644 хатын-кыз) теркәлә. 72 хуҗалыкның җире бөтенләй булмый. Соңгы тапкыр җир 260 иманага бүленә, аның мәйданы 1392 дисәтинә тәшкил итә. Шуның 1188 дисәтинәсе — сөрүлекләр, 82 се — йорт яны җирләре, 25 е — печәнлек, 5 се көтүлек була. 67 хуҗалык — 2 дисәтинәгә кадәр, 57 хуҗалык — 2 дән 4 кә, 43 хуҗалык — 4 тән 6 га, 29 хуҗалык — 6 дан 10 га кадәр, 10 хуҗалык 10 дисәтинәдән артыграк мәйданда иген игә. Бөтенләй җир эшкәртмәүче 74 гаилә исәпләнә. Барлык чәчүлекләр 847,17 дисәтинә була. Төп бөртекле культуралар булып арыш (383,39 дисәтинә), борчак (136,24), тары (130,94), солы (107,32), карабодай (44,53), бодай (26,68) һәм борай (3,33) санала. Бәрәңге — 14,69, киндер 0,05 дисәтинә мәйданда игелә. Авылда 311 ат, 454

[1] Полный алфавитный список населенных пунктов Уфимской губернии.— Уфа, 1906, б. 63–66.

баш мөгезле эре терлек (шуның 244 е сыер), 678 сарык, 178 кәҗә исәпләнә, 4 хуҗалык 13 баш умарта тота.

Яңа Катай буенча мәгълүматларга тукталыйк. Монда 353 хуҗалык, 1759 кеше (885 ир-ат һәм 874 хатын-кыз) була. Соңгы тапкыр җир X ревизия (1859 ел) вакытында теркәлгән ир-ат санынча 401 иманага бүленә. Аның мәйданы 6230 дисәтинә тәшкил итә. Шуның 2965 дисәтинәсе – сөрүлекләр, 2200 е – урман (ул Әрнешкә кадәр сузылган), 100 е – йорт яны җирләре, 700 е – печәнлек, 50 се көтүлек була. Шул ук вакытта 70 хуҗалыкның җире бөтенләй булмый, алар аны авылдашларыннан арендага алып эшкәрткәннәр. Нәтиҗәдә, җирдән файдаланучы хуҗалыклар саны арта, бары 25 гаилә генә игенчелек белән шөгыльләнми. 124 хуҗалык – 2 дисәтинәгә кадәр, 92 хуҗалык – 2 дән 4 кә, 64 хуҗалык – 4 тән 6 га, 30 хуҗалык – 6 дан 10 га кадәр, 18 хуҗалык 10 дисәтинәдән артыграк мәйданда иген игә. Барлык чәчүлекләр 1161,78 дисәтинә тәшкил итә. Моның исәбенә арыш (491,97 дисәтинә), борчак (187,48), солы (175,99), тары (114,98), бодай (73,10), карабодай (66,74), борай (27,21), бәрәңге (20,62), киндер (2,79) һәм җитен (0,93) керә. Авылда 530 ат, 769 баш мөгезле эре терлек (шуның 369 ы сыер), 1293 сарык, 294 кәҗә исәпләнә, 18 хуҗалык 127 баш умарта тота[1].



**Өч билгесез кешенең берсе – Катайныкы. Фоторәсем авылдашым Ләлә Сәлмановага әбисеннән калган**

Ике як – Иске һәм Яңа Катай буенча мәгълүматларны чагыштырып карау «типтәр»ләрнең барлык җир биләмәләре «башкорт»ларныкына караганда 4,5 тапкырга диярлек аз булуын күрсәтә. Шуңа да карамастан, алар игеннәрнең мәйданы буенча бик азга гына калыша. «Башкорт»лар урман-печәнлекләрдән һәм көтүлекләрдән мул файдаланган, «типтәр»ләрнең исә мондый мөмкинчелекләре чикле була, ә урманнары бөтенләй булмый. Әмма шунысын күрсәтеп үтәргә кирәк, «башкорт»ларның иген басулары авылдан 18 чакрым ераклыктагы ике җирдә урнашканлыктан, барып-йөреп эшләргә мәшәкатьлерәк була.

Беренче бөтендөнья сугышы Катайдагы бик күп хуҗалыкларга кагылып үтә. Бу хакта 1917 елгы хуҗалыклар санын исәпкә алу мәгълүматларыннан (китап кушымтасында бирелә) чыгып фикер йөртәбез. Алардан күренгәнчә, яше җиткән һәр ир-атны диярлек сугышка алганнар. Шул чорга караган бер фоторәсемдә хәрби киемнән бер катайлы теркәлгән.

[1] Крестьянское хозяйство Уфимской губернии. Подворная перепись 1912–1913 гг.– Уфа, 1913, б. 1636–1643.

1917 елны Катай биш мәчетле авыл буларак каршылый. Хуҗалыклар исәбен алу документларын өйрәнгән тарихчылар М. И. Роднов һәм О. И. Дудина исәпләвенчә, Иске Катайда 1917 елда 270 хуҗалык, 1345 ир-ат һәм хатын-кыз, 938,05 дисәтинә чәчүлек, 296 эш аты була. Яңа Катайда 391 хуҗалык, 2083 кеше, 1837,19 дисәтинә чәчүлек, 572 эш аты күрсәтелә[1]. Димәк, М. И. Роднов һәм О. И. Дудина мәгълүматлары бик үк төгәл түгел.

Шул ук тарихчылар М. И. Роднов, О. И. Дудина фикеренчә, 4 дисәтинәгә кадәр иген игүче хуҗалыклар ярлы санала. Урта хәллеләргә 4 тән 10 дисәтинәгә кадәр чәчүлеге булганнар керә. Ә менә чәчүлеге 10 нан 15 дисәтинәгә кадәрләр – хәлле, таза, 15 тән дә артып китсә кулак хуҗалык була икән[2].

«Кулак» дип аталырдай һәм таза хуҗалыклар исәбенә кемнәр кергән? Иске Катайда болар – Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәбиев (чәчүлекләрен дә кертеп барлык җирләре 18,93 дисәтинә), Гыйкрәмә Гаязетдинов (18,34), Афзалетдин Гыймадетдинов (18,01), Хәйдәргали Сайранов (17,10), Габдулла Галләмов (16,85), Сиражетдин Гыймадетдинов (16,25), Фәррахетдин Гыйлаҗетдинов (16,06), Мөхәммәтхарис хәзрәт Шәрәфетдинов (16,02), Саяфетдин Бәдретдинов (15,93), Әхмәтгали Мөхәммәтшин (15,72), Мөхәммәтсафа Вәлимөхәммәтов (14,84), Мөхәммәтзакир Шәйхетдинов (14,62), Шәйхезаман Вәлиәхмәтов (14,41), Әхмәтсафа Әхмәтгәрәев (13,56), Миргали хәзрәт Муллагалиев (12,88), Әхмәтхан Мөхәммәтҗанов (12,87), Фәррахетдин Шәйхетдинов (12,75), Әлмөхәммәт Әюпов (12,49), Әхмәтгали Габдерәфиков (12,09), Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәтов (10,93), Мөхәммәтхарис Мөхәммәтшин (10,72), Габделгаллəм Маликов (10,28), Гомәр Йосыпов (10,13), Сиражетдин Яхшыголов (10,07). Алар арасыннан 9 кеше (Хаҗиәхмәт, Фәррахетдин Гыйлаҗетдинов, Мөхәммәтхарис хәзрәт, Мөхәммәтсафа, Мөхәммәтзакир, Шәйхезаман, Әхмәтхан, Гомәр, Мөхәммәтхарис) хезмәтчеләр тоткан.

Яңа Катайдан бай, таза тормышлылар исәбендә Мөхәммәтхарис Яруллин (55,05 дисәтинә), Мөхәммәтдин Габделлатыйпов (51,87), Габделлатыйф Габделсаттаров (49,97), Хөснулла Шәйхуллин (43,70), Каюм Ганиев (41,78), Мөхәммәтзариф Яруллин (38,50), Әхмәтхан Бәдретдинов (31,30), Галимулла Шәйхуллин (30,51), Габделгамил Җәмилев (30,01), Шәяхмәт Дәүләтшин (30), Ибраһим Гыйбадуллин (29,88), Дәүләтгәрәй Миңлегәрәев (24,78), Нурислам Шәйхелисламов (24,06), Габдрахман Габдерәхимов (21,90), Хәбибрахман Әхмәтҗанов (20,56), Шәрәфулла Шәйхуллин (19,99), Гыйззәтулла Җәләлетдинов (19,34), Әхмәтша Тимергалин (18, 62), Гыйндулла Галиуллин (18,34), Габделмәннан Габдерәфиков (18,21), Вәлиәхмәт Мөхәммәтгалин (18,05), Әхмәтгали Мансуров (17,87), Мөхәммәтхәтим Күчемов (17,63), Солтангәрәй Габделкадыйров (17,59), Әхмәтлатыйф Әхмәтәминев (17,58), Габделсаттар Вахитов

[1] Башкирский край. Вып.2.– Уфа, 1992, б.63; Әмма бу юлларның авторы исәпләүләре буенча, Иске Катайда – 279, Яңа Катайда 397 хуҗалык була (кушымтадагы 1917 елгы исемлекне кара).

[2] Башкирский край. Вып.1.– Уфа, 1991, б. 78.

(17,20), Кәнҗелмәгариф Мөхәммәтзарипов (16,99), Фарукша Әхмәдиев (16,47), Габдулла Төхфәтуллин (15,83), Госмангали Шәяхмәтов (15,81), Мөхәммәтнасыйх Җәмилев (15,81), Нурлыгаян Муллаянов (15,75), Садретдин Нәҗметдинов (15,3?), Әсәдулла Гайнуллин (15,06) санала. Болар арасыннан бары Габделгамил хәзрәт, Габделмәннан, Габделсаттар, Габдулла, Госмангали, Гыйззәтулла, Ибраһим, Нурислам, Солтангәрәй, Фарукша, Әсәдуллалар гына хезмәтчеләр тотмый[1].

Югарыда санап үтелгән хуҗалыкларның күпчелеге базар белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Алар үзләре җитештергән икмәкнең шактый өлешен сатып, акча (капитал) туплаганнар, баеганнар.

Баеганнар икән, димәк, алдагы буыннарның тамырын ныгытканнар, бәхетлерәк тормышка күпер салганнар. Әгәр дә без бүген сау-сәламәт булып яшибез һәм нәселебезне дәвам итәрлек хәлдә икән, ерак бабаларыбыз туфрагына баш иик. Кем белә, алар ялкау һәм шуның аркасында фәкыйрь булган булсалар, нәселебез инде кайсыдыр буында ук ачтан кырылган, өзелгән булыр иде, без дә тумас идек... Димәк, безнең беләкләребездә һәм йөрәкләрдә тырыш нәселебездән мирас булып килүче дәрт бар, көч-көдрәт бар!

[1] БҮДТА, Р-473 ф., 1 тасв., 229 һ.б. сакл. бер.

## Биш мәчеттән биш азан...

Үткәннәргә күз салсак, бик аз авыллар гына биш мәчетле булган. Катай – шундыйларның берсе.

Биш мәчеттән авыл, кыр-яланнар өстенә яңгыраган биш азанны күз алдына китереп карасак әгәр, бик тә илаһи, көчле тамаша килеп баса. Һәр мөәзин үз тавышы ераккарак ишетелсен, башкаларныкыннан аерылып торсын өчен бөтен көч-зиһенен вә осталыгын куеп укыгандыр. Дөньяви уйларны бер читкә куеп, тынлыкка чумган авылда азан тыңлаган, эчтән догаларын әйтеп басып торган, карашлары мәчет манарасы өстендәге ярымайга төбәлгән меңнәрчә бабаларыбыз күз алдына килеп баса. Иманын сатмаган, дини-милли рухын саклар өчен утка-суга керергә әзер торган бабаларыбыз!

Тарихтан мәгълүм булганча, унсигезенче гасырның беренче яртысында Россиядә ислам дине шактый эзәрлекләүләргә һәм кысуларга дучар була. Элек-электән үк яулап алынган җирләрдә урыслаштыру сәясәтен алып барган патша хөкүмәте, бары тик христиан динен изге саный, башкаларны шул дингә көчләп тартмакчы була. Бу максаттан бик күп указлар кабул итә, 1740 елда хәтта махсус «Чукындыру конторасы»н (урыс телендә «Новокрещенская контора» дип атала) оештыра. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1742–1744 елларда, мәсәлән, Казан өязендә генә 536 мәчетнең 418 е юк ителә.

Нәкъ шул чорда Катайның һәм тирә-як авылларның да беренче мәчетләре юкка чыгарылган дип уйларга кирәк. Төбәктәге Нугайбәк крепостендә торып, көчләп чукындыру сәясәтен үткәрүче урыс миссионерлары мәчетләрне җимерү-яндыруда турыдан-туры катнашканнардыр.

Патша хөкүмәтенең явызлыгы дин йогынтысын туктата алмый, әлбәттә. Аз гына форсат туугa, 1745 елдан ук мәчетләр яңадан тергезелә башлый. Алар төбәкнең күпчелек авылларында (Катайда, Корычта, Килкабызда, Камайда) шул ук елны, калганнарында бераз соңрак төзелә[1].

Монда бер кечкенә искәрмә биреп үтү кирәк. Әлфия Хәйдәрова язган авыл тарихында Катайда беренче мәчетнең 1737 елда салынуы хакында әйтелә. Билгеле, бу дата бернинди документ белән нигезләнми, бары тик фараз кылып кына әйтелә. Әмма Катай унҗиденче гасырда нигезләнгәнлектән, мәчет тарихын да шул чордан башлау дөресрәк булыр. Мәчет – мөселманның көндәлек дини тормыш-көнкүреш ихтыяҗы, ул берничек тә кичектерелә, арткы планда кала алмый.

[1] Башкортостан үзәк дәүләт тарих архивы (алга таба БҮДТА), И-295 ф., 2 тасв., 7 сакл. бер., 217 б.а. – 219 бб.

Мәчетләребез дини ихтыяҗ үтәү урыны гына түгел, мәктәп-мәдрәсә дә әле. Дин әһелләребез үзләренең төп вазыйфаларыннан тыш, шәкертләр җыеп, укый-яза белү күнекмәләрен дә биргәннәр. Мәчет каршындагы мәктәп башлангыч белем бирү белән чикләнсә, укуларын дәвам итәргә теләгән шәкертләр өчен кайбер авылларда мәдрәсәләр булган, монда алар дини һәм өлешчә дөньяви югары белем алганнар, имтихан тапшырып үзләре дә дин әһелләре булып киткәннәр.

Архив документлары Катайда беренче мәчетнең кайчан төзелгәнен төгәл ачыклап бирә алмаган кебек, беренче дин әһелләренең дә исемнәрен әйтә алмый. Бу хакта беренче чыганак бары тик XVIII гасыр ахырына карый. Аңа таянып 1795 елда Катайның указлы мулласы Табыш Абдуллинның улы Фәйзулла (1750–1801 елларда яши) булуын әйтә алабыз[1]. «Типтәр»ләрнең ревизия исемлегеннән гыйбарәт булган бу чыганак тулы түгел, шуңа күрә «башкорт»лардан кемнәр мулла булганын әйтә алмый.

XIX гасырга караган чыганаклар күп, шуларга таянып, Катайның дини-рухани тормышын тулырак күз алдына китерә алабыз. Бу чорда авыл тагын да зурая һәм шуның нәтиҗәсе буларак мулла-мөәзиннәрнең дә саны арта.

Иң башлап 1816 елгы мәгълүматларга тукталып үтик. Дин әһелләре исемлегендә беренче булып Яугилде Үрмәтов (указлы мулла) тора. 54 яшьтә, Таҗетдин һәм Сираҗетдин исемле уллары бар. Беренчесен (23 яшь) мөәзин итеп куйганнар. Әлеге исемлеккә тагын Әүдияр Азаматов (1805 елдан имам, 42 яшьтә), Габденнасыйр Кылчымов (указлы мөәзин, 34 яшьтә) һәм Габделмәннан Күчемовлар (1805 елдан мөхтәсип һәм мөдәррис, 35 яшьтә) керә. Авылда ике мәчет – җамигь һәм биш вакыт намазлы. Соңгысы беренче мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов боерыгы нигезендә салына. Җомга намазына халык җамигь мәчеткә җыелган.

Табыш картның оныгы Нигъмәтулла Баязитов, 1809 елда ук указы булуга карамастан, имам һәм мөгаллим урыны ала алмый. Каршылыклар күп була, бигрәк тә Әүдияр Азаматов белән. Хәзрәт картайды, аның урынына билгеләгез дип, мөфти исеменә дә язып карый, әмма файда булмый. Рөхсәтсез имамлык вазифасын үтәргә керешкәне өчен, 1831 елның 5 февралендә Оренбург губерна идарәсе Нигъмәтулла Баязитовның указын алырга карар бирә.

Шул ук елны Әүдияр Азаматов дөнья куя һәм аның урынына улы Габделганине мулла итеп сайлыйлар. 1831 елда тагын Бөгелмә өязе Урыссу авылыннан 46 яшьлек Габденнасыйр Габдерәхимов та имам-хатыйп һәм мөдәррис вазифасын үти башлый. Габденнасыйр хәзрәт Катайда 1852 елга чаклы яши, аннары Әлмәт төбәгендәге Тәйсуган авылына кайтып китә. Ул шул ук төбәктән чыккан икенче мөфти Габдессәлам Габдерәхимовның туганы булса кирәк.

Алдарак әйткәнебезчә, 1842 елда авыл рәсми рәвештә икегә – Иске һәм Яңа Катайга бүленә. Маты елгасының икенче ягына күченгәч тә, яңа катайлылар озак вакытлар Иске Катай ягындагы мәчеткә йөри. Мәчет салырга тәүге тап-

[1] БҮДТА, И-138 ф., 2 тасв., 34 сакл. бер., 211 б.а.

кыр 1850 елда рөхсәт сорап мөрәҗәгать итсәләр дә, бер-бер артлы тоткарлыклар килеп чыгып, мәсьәлә ул елны гына түгел, хәтта 1853 елда да хәл ителмичә калган була[1].

Яңа Катайның беренче имамы һәм мөгаллиме (1841 елда указ алган) Әхмәтҗан Габделҗәлил улы Кылчымов була. Ул хезмәт иткән җамигъ мәчеттә 1863 елдан хатыйп булып Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Кылчымов тора. Габделҗәмил хәзрәтнең атасы Мөхәммәтҗан – Әхмәтҗан белән бертуган.

1867 елда 412 ир-ат һәм 392 хатын-кыздан торган бу мәхәлләдә мәдрәсә эшли[2].

Яңа Катайда мөәзиннәр булып Төхфәтулла Солтанбәков (1826 елда указ алган; ул Арсланбәк картның оныгы), Габделгалим Габделкәримов (гасыр уртасында; ул Азамат картның оныгы), аннары Габдулла Әхмәтҗан улы Кылчымов (1880 елда указ алган) һәм Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы Кылчымовлар (1881) тора.

Мисбах Гариф улы Күчемовның сөйләвенә караганда, аның бабасы Мөхәммәтзариф мөәзиннең тау башында бакчасы була. Монда ул кавын-карбыз һәм башка яшелчәләр үстергән. Суны мичкәләр белән ташыган. Кояш яратучы үсемлекләр тау башында тизрәк өлгерә торган булган. Түтәл эзләре, келәт урыны әлегә чаклы сакланган.

Сүз уңаеннан әйтик, Мисбах абый үзе дә бакчачылык эшенә әвәс иде. Бабасы каныннан килә дип саный ул үзенең хирыслыгын. 1970 елдан башлап күпме генә агач утыртмаган ул! Шул ук тау башындагы чокыр-чакырларда нинди генә агачлар юк: сәрби, чия, камырлык, миләш, каен, карама, нарат, усак – барысы меңләп данә исәпләнә. Энесе Мөстәкыйм алып кайтып биргән 150 төп чыршы һәм 80 төп каен да яңа урында әйбәт кенә үсеп киткәннәр. Элек тирес түккән чокырларны тигезләп бакчага әйләндергән, карлыган, балан, алма утырткан ул. Мал-туар зыян китермәсен дип гектарга якын җирне киртәләп алган. Җимешкә рәхәтләнгәндер бур очындагылар, аларга сүзе юк Мисбах абыйның, сындырмасыннар гына. Табигать тә откан: чокырлар ишелүдән туктаган, хәтта чишмәләр хасил булган. Кайда дым күп, шунда балан үсә икән. Һәрберебез, Мисбах абый кебек, изге гамәлләр кылса, яхшылыклар эшләргә омтылса, шау чәчәкле бакчадай матур булыр иде тормышыбыз!

Мәчетләргә кайтыйк. Иске Катай авылы җамигъ мәчетендә унтугызынчы гасырның икенче яртысында ике имам һәм мөгаллим була. Аларның беренчесе – Миңлегатиятулла Бикташев (аның абыйсы Мөхетдин Бикташев турында Казыяр елгасында тегермән салдырган дип әйтеп үткән идек алдагы бүлектә), икенчесе – алда телгә алынган Нигъмәтулла Баязитовның улы Мөхәммәтнәби (1852 елдан, Габденнасыйр хәзрәт урынына). Мөәзин булып Габделгалим Габделкәримов (1836 елдан) тора, ул укытучы вазифасын да башкара[3].

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 7550 сакл. бер.

[2] БҮДТА, И-295 ф., 3 тасв., 6725 сакл. бер., 58 б.

[3] БҮДТА, И-295 ф., 3 тасв., 6725 сакл. бер., 58 б.

Метрикә кенәгәсе мәгълүматларына караганда, Миңлегатиятулладан соң имам-хатыйп вазифасын 1873—1882 елларда Хөснетдин Фәхретдинов башкара. Бу чорда Мөхәммәтнәби Нигъмәтуллин элеккечә икенче имам була.

Өч дистә ел (1873—1904 елларда) бу мәчеттә мөәзин булып Шаһимөхәммәт Мөхәммәткәримов тора. Картайгач кына аның вазифасы икенче кешегә күчә (1917 елда әле ул исән, аңа 85 яшь була).

Сүз уңаеннан әйтим, шәҗәрәмне төзегәндә Шаһимөхәммәт мөәзиннең нәселдәшем икәнлеген ачыкладым. Үзебезгә дә аның кебек озын гомер яшәргә, туган авылыбызга армый-талмый хезмәт итәргә язсын, амин.

Хөснетдин мулладан соң имам-хатыйп вазифасы Мөхәммәтзакир мулла Мөхәммәтсадыйк улына күчә. 1886 елда икенче мулла итеп Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәбиевне куялар.

Метрикә һәм ревизия кенәгәләреннән Мөхәммәтзакир мулланың Яңа Катайның Күчем нәселеннән, 1836 елда туганлыгын, Мөхәммәтзариф (1857 елда туган), Мөхәммәтгаяз (1859), Мөхәммәтхафиз һәм Мирказелгаяз исемле уллары булуын беләбез. 1889 елда ул үзенең 18 яшьлек кызын Наратлы Елганың Нуретдин Минһаҗетдин улына кияүгә бирә.

Иске Катай метрикәсендә Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Күчемовның 1899 елның 13 апрелендә 64 яшьтә йөрәк авыруыннан мәрхүм булуы турында әйтелә. Иске Катайда аңа куелган таш әлегәчә сакланган, энем Дамир аны фотога төшереп миннән укыткан иде.

1893 ел авыл тарихында аеруча истәлекле ел — Иске Катайда икенче җамигъ мәчет салына. Монда хатыйплыкка Галимулла Галиуллин (1896 елдан), мөәзинлеккә Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев (1895 елдан) раслана.

...Тормыш сукмаклары кайларга гына илтми, кемнәр белән генә очраштырмый! Тарихи истәлекләр язып алу, җыю уе белән Камышлы авылына барып чыккач, 2002 елның 13 мартында көтмәгәндә-уйламаганда Галимулла мулланың шул авылда яшәүче кызы Рәйфә әби белән очрашып сөйләшергә насыйп булды. Ул сөйләгәннәр шактый кызыклы булып чыкты.

Рәйфә әби истәлекләренә караганда, бу мәчетне катайлы Мортаза Мөхетдинов (китапта телгә алынган тегермәнче Мөхетдин Бикташевның улы.— *Т.К.*) салдыра. Аннары ул мулла сорап Бәйрәкәгә хәзрәт янына барган, хәзрәт аңа шундагы мәдрәсәдә укыткан Галимулла хәлфәне биреп җибәрә. Галимулла — атаклы муллалар нәселеннән. Аның бер туганы Нәгыймулла — Баулыда мулла, икенчесе Шәфигулла — Исергәптә мөәзин, өченчесе Вәлиулла Усман-Ташлысында ахун булып хезмәт иткән. Галимулланың хатыны Нәфисә Суфиәхмәт кызы Бәйрәкәнеке, аларның бер-бер артлы 11 баласы дөньяга килә (баштагы икесе — Бәйрәкәдә, калганнары — Катайда), Рәйфә әби 7 нче кыз булып 1914 елда туган, башкалары малайлар була.

Галимулла хәзрәт 1933 елда 63 яшьтә кинәттән вафат була. Бер җомгадан соң башы авыртып, авыртуы бетмичә, икенче җомгага чаклы китеп тә бара. Аның борчулары күп була, шул елны Иске Катайда зур янгын чыгып ул да йортсыз



№ 395

# ДѢЛО

Оренбургскаго Магометанскаго
Духовнаго Собранія

Дело
Об утверждении башкира Галимуллина имамом хатыбом вновь открытой 2-й мечети дер. Старой Катаевой Белебеевского у. Уфимской губ.

Началось 3 Июня 1896 года.
Кончилось 18 Сентября 1896 года.



Галимулла Галиуллин

БУДТА, И-295 ф. , 9 тасв., 20782 сакл. бер.

кала, яңадан йорт тергезү мәшәкате белән йөри, тик аны салып кергәч кенә озак яшәргә насыйп булмый аңа.

Галимулла мулланың балаларына бик күп авырлыклар күрергә туры килә. Рәйфәне мулла кызы дип баштарак колхозга якын китермиләр, бары тик 1936 елда гына алалар.

Рәйфә апа сөйләгәннәрне архив чыганаклары да раслый. Архивта Баулы авылы кешесе Галимулла Галиуллинның 1896 елда Иске Катай авылының икенче мәхәлләсенә имам-хатыйплыкка билгеләнүе турында документ сакланган. Әлеге документның бер битенә Галимулла хәзрәт үз куллары белән кириллицада исем-фамилиясен дә язып куйган.

Мортаза Мөхетдиновның мәчет салдыруы гына түгел, ул мәчеткә имам-хатыйп булырлык тиешле кеше табуы да игътибарга лаек. Якынтирәдә имам-мөәзиннәр әзерләүче мәдрәсәләр берничә булуга карамастан, ул даны еракларга таралган атаклы Бәйрәкә мәдрәсәсенә барган, андагы мулла-хәлфәләрне күреп сөйләшкән, иң лаеклысын үзе төзегән мәчеткә муллалыкка чакырган. Мулла бит халыкны җыеп намазлар укучы, вәгазьләр сөйләүче генә түгел, мәчет каршында мәктәп ачып, балаларны җыеп, аларны укырга-язарга өйрәтүче, аларга беренче дөньяви белем бирүче дә булган. Аның нинди нәселдән булуы да әһәмиятле. Шуларны кат-кат уйлаган Мортаза авылдашыбыз вакытын да,

акчасын да кызганмаган, үз мәхәлләсенә бөтен таләпләргә җавап бирерлек мулла табу бурычын куйган һәм максатына ирешкән. Изге гамәлеңә соклана-быз, баш иябез синең каршыңда авылдашыбыз! Бу язган юллар якты рухыңа дога булып ирешсен.

Истәлекләрне шунда төгәлләп, яңадан Катайга кайтыйк. Бер ел да үтми, тагын зур вакыйга – бу юлы Яңа Катайда 2 нче җамигъ мәчет ачыла. Гасыр ахырында дин әһелләреннән Мөхәммәтгариф Мозаффаров (хатыйп, 1896 елның гыйнвар-февраль айларында, Корыч авылыннан[1]), Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗан улы Кылчымов (мөәзин, 1896 елдан), Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Кылчымов (хатыйп, 1898 елдан) һәм Мөхәммәтзакир Фәттахетдин улы Җамалетдиновларны (имам, 1899 елдан) күрәбез.

Метрикә кенәгәләрендә дә муллалар турында кайбер мәгълүматлар бирелә. 1900 елда Иске Катайның беренче мәхәлләсендә имам вазифасын Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев башкара. Аңа бу вакытта 48 яшь була, ул Корыч авылында Газизҗан хәзрәттә укыган, 1886 елның 8 ноябрендә имам һәм мөгаллимлеккә указ алган. Мөәзин булып 56 яшьлек Шаһимөхәммәт Мөхәммәткәримов хезмәт итә. Ул Минзәлә өязенең Әмәкәй авылында Габдулла хәзрәттә укыган, 1873 елның 8 мартында указ алган. Бу мәхәлләдә 1900 елда 396 ир-ат һәм 322 хатын-кыз исәпләнә.

2 нче мәхәлләдә имам булып 32 яшьлек Галимулла мулла Галиулла улы Гыйсмәтуллин тора. Ул Самара губернасының Бәйрәкә авылында Габделгали Габидуллин хәзрәтнең мәдрәсәсендә белем алган, аңа хатыйплыкка указ 1896 елның 23 маенда бирелгән. Мөәзин хезмәтен Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев (38 яшь) башкара. Ул да алдарак телгә алынган туганы кебек Корыч авылында Газизҗан хәзрәттә укыган, 1895 елның 21 августында указ алган. Бу мәхәлләдә 198 ир-ат һәм 223 хатын-кыз була[2].

Яңа Катай мәчетләренә тукталып үтик. 1 нче мәхәлләдә имам булып 41 яшьлек Ахунҗан Әхмәтҗан улы Күчемов тора. Ул Иске Дөмәй авылында Мөхәммәтсадыйк Габделҗәлилов мәдрәсәсен тәмамлаган, 1890 елның 21 апрелендә указ алган. Мөәзин булып Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗан улы Күчемов (50 яшь) хезмәт итә. Ул да шул ук авылда, шул ук кешедә укыган, тик указны гына алданрак (1881 елның февралендә) алган. Мәчетнең документлары Әхмәтҗан Габделҗәлил улы Күчемов имамлык кылган заманда аның кулында сакланган, тик «каза белән утта янган» (документта шулай язылган). Бу мәхәлләдә 1900 елда 442 ир-ат һәм 438 хатын-кыз исәпләнә.

2 нче мәхәлләдә имам-хатыйп вазифасын Габделҗәмил Мөхәммәтҗан улы Күчемов башкара. Ул 1836 елның 18 гыйнварында туган, 1863 елның 18 февралендә хатыйплыкка указ алган. 1898 елның 11 февралендә әүвәлге мәчеттән яңа барлыкка килгән 2 нче мәчеткә күчерелеп (әлеге мәчетне салырга рөхсәт 1893 елда бирелә), монда да хатыйплык хезмәтен башкара. Имам булып 27 яшьлек

[1] БҮДТА, И-295 ф., 4 тасв., 20781 сакл. бер.

[2] БҮДТА, И-295 ф., 16 тасв., 334 сакл. бер.

Мөхәммәтзакир Фәттахетдин улы Җамалетдинов тора (указ 1899 елның 10 апрелендә бирелгән). Мөәзинлек 59 яшьлек Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗан улы Күчемовка йөкләнгән. Ул башка нәселдәшләре кебек шул ук Иске Дөмәй авылында Мөхәммәтсадыйк Габделҗәлиловта укыган, 1896 елның 13 апрелендә указ алган. Бу мәчетнең документлары Хөснетдин Мөхәммәткәрим улы Күчемовта сакланган, 1900 елда мәхәлләдә 357 ир-ат һәм 353 хатын-кыз исәпләнгән[1].

Егерменче гасырга күчкәч, Яңа Катай халкы 3 нче җамигъ мәчет салырга рөхсәт бирүче Уфа губерна идарәсенең 1909 елның 25 августында кул куелган 3816 нчы санлы указын ала. Хәсән абый Шакиров сөйләвенә караганда, мәчет төзелешенә (ул Мисбахлар урынында була) төп акчаны берничә кеше кертә. Иске Катайдан берәү чыгымнарның утыз процентын үз өстенә ала, мулла итеп куйсагыз дип. Гариф мулланың бабасы (Харис; Азамат нәселеннән) егерме биш процентын кертә. Шуның чаклы ук Шәрәйләр дә (Арсланбәк нәселе) бирә, үз кешеләрен мөәзин итеп куйсагыз дигән шарт белән. Калган акчаны халыктан җыялар. Нәкъ алдан сөйләшенгәнчә, дин әһелләре төп чыгымнарны үз өстенә алган нәселләрдән сайлана. Бер үк көнне, 1910 елның 6 ноябрендә, Мөхәммәтгариф Мөхәммәтзариф улы Күчемов – хатыйп, Габделгалим Ибниәминов имам итеп раслана. Аның икенче елында Габделкаюм Габделмәннапов мөәзин вазифасын үтәргә керешә.



Мөхәммәтгариф мулла 1885 елда туган, Каран мәдрәсәсендә Фәтхелбаян хәзрәттә укыган, 1910 елның 30 октябрендә указ алган. Габделгалим мулла исә өлкәнрәк яшьтә (1871 елда туган) була, Яңа Катайда Мөхәммәтзариф Күчемовта укып, Мөхәммәтгариф мулла белән бер көнне указ ала. Мөәзин Габделкаюм Габделлатыйпов (фамилиясе шулай күрсәтелә) 1863 елда туган, Каранда Фәтхелбаян хәзрәттә укыган, 1911 елның 29 июлендә указ алган. Мәчет документлары Мөхәммәтгариф муллада сакланган.

Шулай итеп, беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Яңа Катайда – өч, Иске Катайда ике мәчет була. Әлеге мәчетләрнең имам-хатыйпларын күрсәтеп үтик. Яңа Катай буенча: Гыйниятулла Габделлатыйпов (1 нче мәчет), Габделҗәмил (чыганакта «Габделҗәлил» дип ялгыш язылган) Мөхәммәтҗан улы Күчемов (2 нче мәчет) һәм Мөхәммәтгариф Мөхәммәтзариф улы Күчемов (3 нче мәчет). Иске Катай буенча: Әбуталип Муллагалиев (1 нче мәчет) һәм Галимулла Гыйсмәтуллин (2 нче мәчет)[2].

Архив чыганакларына таянып, югарыда китерелгән мәгълүматларны тулыландырып үтик. Яңа Катайның беренче мәхәлләсенә Гыйниятулла Габдел-

[1] БҮДТА, И-295 ф., 16 тасв., 251 сакл. бер.

[2] Адрес-календарь Уфимской губернии на 1913 г. – Уфа, 1912, б.107.

латыйпов имам-хатыйп булып 1904 елда раслана. Озак вакытлар (1890–1911 елларда) монда Ахунҗан Әхмәтҗан улы Күчемов имамлык итә. Әлеге мәхәлләнең метрикә кенәгәсендә ул вакытта 440 ир-ат һәм хатын-кыз күрсәтелә. Мөәзинлек вазифаларын Мөхәммәткашшаф Габделҗәмил улы Күчемов (1911 елдан) һәм Шакирҗан Ахунҗан улы Күчемовлар (1913 елдан) башкара[1].

Икенче мәхәллә имам-хатыйбы Габделҗәмил Күчемов 1913 елда дөнья куя. Хатыйп итеп (1914 елның 2 апреленнән) аның улы Мөхәммәтнасыйх Күчемов раслана. Имам һәм мөгаллим булып элеккечә Мөхәммәтзакир Фәттахетдин улы Җамалетдинов тора.

Иске Катай буенча мәгълүматларга тукталыйк. Гасыр башында (1901 ел) беренче мәхәлләдә 250 ир-ат исәпләнә. Шул елның 1 июнендә мәхәллә халкы 24 яшьлек Мирсәгыйть Мөхәммәтзакир улы Күчемовны хатыйп итеп сайлый һәм 15 октябрьдән ул рәсми рәвештә үз вазифасын үти башлый. Имам булып элеккечә Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев тора[2].

Мирсәгыйть хәзрәт хатыйплыктан баш тарткач (моны сәбәбе әйтелми), 1908 елның августында аның урынына алдарак әйтеп үтелгән Әбуталип Муллагалиев раслана.

Иске Катайның икенче мәхәлләсендә дә үзгәрешләр була. 1905 елда монда Мөхәммәтхарис Шәрәфетдинов имамлык хезмәтенә керешә. Элеккечә Галимулла Галиуллин – хатыйп, Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев мөәзин вазифасын башкара.

Хәсән абый Шакиров сөйләве буенча, Яңа Катайга мулла булып Рәйхан исемле кеше дә килә (архив документларында аның турында бернәрсә дә әйтелми). Әмма аның язмышы фаҗигале була – коега батып үлә. Бу фаҗигане Җәмил хәзрәт кешеләре оештырган дигән сүз йөргән соңыннан. Чөнки аның Насыйх исемле улы бу мәхәлләдә мулла булырга җыенган.

1917 елны Катай 605 хуҗалыклы һәм биш мәчетле авыл буларак каршылый. Метрикә кенәгәләренә һәм хуҗалыклар исәбен алу документларына таянып, мулла-мөәзиннәр турында тулырак мәгълүматлар биреп үтик.

Иске Катайның 1 нче мәхәлләсендә 456 ир-ат һәм 463 хатын-кыз исәпләнә. Авылыбызның беренче мәчете бу мәхәлләдә төзелгәнгә күрә, документта аның метрикә китабы 1829 елда бирелгән дип күрсәтелә (башка мәхәлләләр, барлыкка килүләренә карап, бу китапны соңрак алалар). Бу вакытта ике мулла була. Беренчесе – Тыпый авылында туып-үскән Миргали Муллагалиев (35 яшь). Метрикә кенәгәсе мәгълүматларына караганда, аның исеме Әмиргали, ул Тымытык авылында Габделлатыйф хәзрәттә укыган, 1908 елда указ алган, имам-хатыйп вазифасын башкара. Икенче мулла – Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев (64).

2 нче мәхәлләдә 277 ир-ат һәм 235 хатын-кыз теркәлгән. Мәчет төзергә 1893 елның 20 маенда бирелгән рөхсәт язуы Мортаза Мөхетдиновта сакланган (мә-

[1] БҮДТА,И-295 ф., 5 тасв., 2376 сакл. бер.
[2] БҮДТА, И-295 ф., 5 тасв., 439 сакл. бер.

четне үз акчасына салдыручы бу кеше турында Рәйфә апа истәлекләрендә әйтелгән иде). Мәхәлләдә Галимулла Галиуллин (50) һәм Мөхәммәтхарис Шәрәфетдиновлар (44) мулла булып торалар. Метрикә кенәгәсендә Мөхәммәтхарис хәзрәтнең Каран авылында Фәтхелбаян Гайникамал улы мәдрәсәсендә укып, 1905 елның 30 июлендә имамлыкка указ алганлыгы хакында әйтелә. Мөәзин вазифасын элеккечә Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев башкара.

Әлфия апа Хәйдәрова сөйли: «Мөхәммәтхарис мулла исемен картлар бик зурлап телгә алалар иде. Чөнки ул, дин белеме белән бергә, шәкертләргә урыс хәрефләрен дә өйрәтә. Хафизов Гата, Шәкүров Шәйхенур, Гәрәев Сафакай, Сафин Нәгыйм һәм башкалар ярыйсы гына укырга-язарга өйрәнәләр. Ә бу ул заман өчен зур белем саналган».

Яңа Катай мәхәлләләренә күчик. Метрикә кенәгәсе мәгълүматларына караганда, 1 нче мәхәлләдә 1917 елда 330 ир-ат һәм 336 хатын-кыз исәпләнә. Алдарак әйтеп үтелгән Гыйниятулла Габделлатыйпов (45 яшь) элеккечә үз вазифасын башкара. Икенче имам булып Шәкүрҗан Ахунҗанов тора. Ул 1872 елда туган, Шарлама авылында Әхмәтсафа хәзрәттә укып, 1913 елның 13 ноябрендә указ алган. Мөәзин хезмәтен Мөхәммәткашшаф мулла Габделҗәмил улы Күчемов башкара. Ул үз нәселдәшендә, Мөхәммәтзариф хәзрәт мәдрәсәсендә укый, 1911 елның 25 ноябрендә указ ала.

2 нче мәхәлләдә, шул ук 1917 елгы метрикә кенәгәсе мәгълүматларына караганда, имам-хатыйп һәм мөгаллим вазифасында Мөхәммәтнасыйх Габделҗәмил улы Күчемов күрсәтелә. Ул 1883 елның 10 февралендә туган, Каръяуды олысына кергән Базыбаш-Каран авылында мулла Фәтхелбаян Сәлимов хәзрәттә укып, 1914 елның 31 мартында указ алган. Икенче имам хезмәтен Мөхәммәтзакир Фәттахетдин улы Азаматов башкара. Мөәзин вазифасы 64 яшьлек Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗановка йөкләнгән. Ул Дөмәй авылында Садыйк хәзрәттә укыган, 1896 елның 13 апрелендә указ алган.

1917 елгы хуҗалыклар исәбен алу мәгълүматларына караганда, бу мәхәлләдә 47 яшьлек Габделгамил Җәмилев тә муллалык итә. Габделгамил хәзрәтнең Мөхәммәтнасыйх исемле 30 яшьлек туганы да бу мәчеттә мөәзин булып хезмәт итә.

3 нче мәхәлләдә 1917 елга үзгәрешләр юк диярлек. Монда Мөхәммәтгариф Мөхәммәтзариф улы Күчемов (31 яшь) муллалык итә. Мөәзиннәргә аерым тукталып тормыйбыз. Күпчелек муллалар Күчемовлардан булган кебек, монда да алар әлеге нәселгә карый.

Совет чорына күчеп, җитди каршылыклар туганчы мәчетләр элеккечә эшли. Егерменче еллар башында Яңа Катайдан 50 хуҗалык Чүмәлә Катай авылын нигезләгәч, 1922 елның 22 февралендә Мөхәммәтзакир Җамалетдинов – имам, Сабирҗан Ахунҗанов мөәзин итеп раслана.

Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтҗан улы Кылчымовның Мөхәммәтназиф исемле улы 1920 елның июленнән Яңа Катайның икенче мәхәлләсендә имам вазифасын башкара. Бу вакытта аңа утыз өч яшь була. Өченче мәхәлләдә Габ-

делгалим Ибнеәминов 1924 елның көзендә үз теләге белән имамлыктан китә. Мөәзин Габделкаюм Габделлатыйпов 1920 елда дөнья куя. 1921 елның декабрендә алтмыш яшьлек Нурлыгаян Хөснетдинов мөәзин итеп билгеләнә, әмма сигез айдан ул да вафат була. Аның урынына 1896 елгы Афзалетдин Галләметдиновны (Арсланбәк нәселе) куялар. (Афзал мөәзин икенче бөтендөнья сугышында катнаша. «Чигенгәндә күпер шартлатырга калдырдылар. Нимесләр килеп җиткәч кенә шартлаттым», дип сөйләгән бервакыт клубта. Әлеге батырлыгы өчен аны «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләклиләр. Сугыштан соң умартачылыкта эшли.) Иске Катай имамы Мөхәммәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев 1920 елның көзендә дөнья куя.

Катай кешеләре башка авылларда да динебезгә хезмәт иткәннәр. Хәсән абый сөйләве буенча, Азамат нәселеннән Куянда, Иске Балыклыда һәм Яңа Корычта муллалар була. Күчем нәселеннән Габдрахман Әхмәтҗан улы Күчемовның беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Тыпыйның икенче мәхәлләсендә хатыйп вазифасын башкаруы мәгълүм. Монда мәдрәсә тоткан, әфәнде дип йөрткәннәр, дип искә алалар аны. Күчемовларның тагын берсе — Нәҗменгариф Мөхәммәтзариф улы — Камышлыда мулла була. Зәйнәгыл хаҗи Күчемов Сәкәшкә мулла булып китә. Шаранбаш Кенәздә бер улы муллалык итә. Шаранбаш Кенәздә тагын Әхмәтзәки мулла Әхмәтхарис улы Күчемов (1878 елда туган) 1908 елның 2 маеннан имам хезмәтен башкара (аңарчы Тымытык авылында Әхмәтлатыйф хәзрәттә гыйлем тәхсил кылган). Күчемовлардан тагын берәү Бәйрәкә мәдрәсәсендә мөгаллим була. Хафиз мулла, Килкабызда мулла булган чакта, никах канунын боза (16 яшьлек кыз белән 18 яшьлек егетне кавыштыра), шуның өчен сөргенгә җибәрелә.

Габденнасыйр Кылчымовның оныгы Мөхәммәтлатыйф Әхмәтов 1884 елның 22 июнендә Иштерәк авылы мәчетенә мөәзин итеп билгеләнә[1].

Чыгышы буенча типтәр сословиесенә караган Габделгани Габденнасыйров Бөгелмә өязе Тәйсуган авылында икенче имам булып хезмәт итә[2].

20 нче гасыр башында авылыбыздан Корыч авылы мәдрәсәсендә, Бәдретдин хәзрәттә укучылар була.

Утызынчы елларда мәчетләребезнең манаралары киселде, ә дин әһелләребез эзәрлекләнде. Дистәләрчә еллар атеизм, алласызлык хакимлек иткән чор башланды. Динлелек кимү нәрсәгә китергәнен хәзер яхшы аңлыйбыз, әмма күпме нәрсәне югалттык! Соң булса да, яңадан асылыбызга кайту кирәклеген аңлап, мәчетләр сала башладык. Кайчандыр биш мәчете, дистәдән артык дин әһелләре булган Катайда да халык дин юлына кайта башлады. Беренче указлы муллабыз — Шәяхмәтов Зиннур Госман улы. Ул 1993 елның 1 июнендә имамхатыйплыкка имтихан тапшыра, ә 1997 елның 17 февралендә әлеге дәрәҗәне раслаучы документ ала. 1993 елның 1 июнендә Катай мәхәлләсе Диния нәзарәтендә Башкортостан буенча 1039 нчы сан белән теркәлә.

[1] БҮДТА, И-295 ф., 4 тасв., 13625 сакл. бер.

[2] Самара өлкәсе дәүләт архивы, 1 ф., 10 тасв., 354 сакл. бер.



Зиннур Госман улы Шәяхмәтов

...Мәчет төзергә авыл аксакаллары 1989 елда карар итәләр. Ул чактагы совхоз директоры Ахунов Вәис Галимҗан улы авылдашларының ниятен хуплый, нигез ташы, кирпеч кебек төзелеш кирәк-яраклары белән ярдәм итә. Төп төзүче һәм рухландыручы Зиннур мулла була, мондагы күп нәрсәне ул үз куллары белән башкара. Төзелештә җиң сызганып Бәдретдинов Фәнис Афзалетдин улы, Мансуров Мәгънәви Хаҗгали улы, Миңлеханов Зәкәрия, Кәлимуллин Әсгатьләр дә шактый вакыт эшлиләр. Ярымай белән манараның очын – сыр заводы директоры Р. М. Нәбиев, манараның үзен Чакмагыштан Ф. М. Нәбиев үз исәпләренә эшләттереп алып кайталар. Авылдашыбыз Г. Н. Харисов пар белән җылыту системасын көйләп бирә, С. М. Нәбиев электр үткәргечләрен урнаштыра.

1999 елның 4 июнендә Яңа Катайда тантаналы рәвештә мәчет ачылды. Кайдан гына кунаклар кайтмаган-җыелмаган иде бу көнне! Бәйрәм тантанасына район җитәкчеләре һәм Уфадан мөфти Тәлгать Таҗетдин килде. Тәбрикләү сүзләре, ал тасманы кисү, җомга намазы... Мондый изге бәйрәм соңгысы бул-





масын, яңадан-яңа мәчетләребез салынсын, гыйбадәтханәләргә беркайчан да халык эзе суынмасын дигән теләкләр чыгышларда да яңгырады, күпләребезнең күңелендә дә булды ул көнне.

Зиннур мулла 2007 елның 12 февралендә мәрхүм булды. Шул елның җәендә халык теләген үтәп Яңа Катай мәчетенә аның исеме бирелде, истәлек тактасы эленде.



Рухилык

# Мәчеткә аның исеме бирелде

Вакытлар үзгәрде, кешеләрнең рухилыкка ихтыяҗы, дин кануннары буенча яшәү омтылышы артты. Мәчеткә йөрүчеләр һәм иганәчеләр акчаларына Катай авылында районда беренчеләрдән булып мәчет төзелде. Аллаһы йорты Зиннур Усманович Шәяхмәтов җитәкчелегендә төзелде. Мөселманнар берләшмәсе ачылу белән, авылда имам-хатиб З. Шәяхмәтов җомга намазлары, дини бәйрәмнәр үткәрә башлады, алар рухи байлыкларның торгызылуына булышлык итә.

Катай авылында мәчет төзүгә һәм ачуга, үсеп килүче буынны әхлакый тәрбияләүгә керткән зур өлешен исәпкә алып, мөфти хәзрәт шәйх-уль-ислам Тәлгать Таҗетдин мәчеткә «Зиннур» исемен бирү турында халыкның теләген канәгатьләндерде. Мәчетнең тыйнак, эшлекле һәм гадел хезмәтчесе Зиннур Усманович Шәяхмәтовның керткән өлеше лаеклы бәяләнде, истәлекле тактада аның исеме мәңгеләштерелде.

Ф. ДӘҮЛӘТШИН,
Бакалы авылы мәчете имам-хатиб-мөхтәсибе.

Бу юллар язылып, берничә ел үткәч, авылыма бер кайтуымда үзем дөньяга килгән, балачагым узган Иске Катайда да 2011 елда мәчет салганнарын ишетеп-күреп килдем (төзелеш эшләре 2010 елның 23 апрелендә башлана, 2011 елның 27 маенда мәчет тантаналы рәвештә ачыла). Әлеге эштә башлап йөрүче, үзеннән саллы өлеш кертүче, Татарстанда гомер итүче авылдашым Рәзиф Зәкиҗан улы Латыйпов булып чыкты. Дин юлына баскан хөрмәтле авылдашым эшмәкәрлек белән дә шөгыльләнә, әнә шундый изге эшләр дә башкара икән. Шунысы тагын куанычлы, Рәзиф белән без бер нәселдән, димәк, икебез дә авылыбызның үткәнен уйлап-бүгенгесен кайгыртып, кулыбыздан килгәнчә аның тарихын-йөзен саклау артыннан йөрибез.

Бүгенге көндә авылыбызның указлы мулласы – Вил Шәкүр улы Мофаздалов. Ул яшь буын белән эшләүгә зур игътибар итеп, мәчет каршында дини мәктәп ачып җибәрде. Монда башлангыч белем алган балаларның кайберләре киләчәктә мәдрәсә ишекләрен ачып кереп, гыйлем туплап, хөрмәтле Зиннур һәм Вил хәзрәтләребез кебек армый-талмый авылдашларына хезмәт итәрләр әле, иншалла.

...Без хәзер, тарихка кире кайтып, динебезне, телебезне үстерүгә, гореф-гадәтләребезне саклауга зур өлеш кертеп яшәгән затларны олылыйбыз, хөрмәт белән телгә алабыз. Киләчәктә дә шулай булачак. Алдагы гасырларда әле генә саналып үтелгән шәхесләргә изге итеп караячаклар. Бер нәрсә дә мәңгелек түгел – барысы да туза, чери, тузанга әйләнә... Бары тик игелекле гамәлләр кала, шул гамәлләрне кылучы адәмнәрнең кадерле исемнәре, якты рухлары кала!



**Коръән өйрәнү мәктәбендә Вил хәзрәт Мофаздалов дәрес бирә**



**Мәчеттә Мәүлид бәйрәме**

# Һәркемнең үз һөнәре бар

Халкыбызның тормыш рәвешен, зәвыгын чагылдыручы традицияләре бик күп. Һөнәрчелек – шуларның берсе. Иген иккән, терлек асраган, шул ук вакытта һөнәре дә булган кешеләр элек-электән зур хөрмәт казанганнар. «Тырыш, эшчән», дигәннәр алар хакында, башкаларга үрнәк итеп күрсәткәннәр. «Һөнәрле кеше беркайчан да югалмас, һөнәрле – үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс», дип тә өстәгәннәр, бу хакта сүз чыкса.

Иген игеп, терлек асрап гомер иткән авыл кешесе өчен һөнәрчелек даими шөгыль булмаган. Кыр эшләре тукталып торган айларда, бигрәк тә кышын, хатын-кызлар киндер сукканнар, җеп эрләгәннәр. Ир-атларның бер өлеше чабата үргән, туннар, бүрекләр теккән, башкалары да шөгыльсез тормаган.

Авылыбыз аша Маты һәм Казыяр елгалары акканлыктан, бабаларыбызның элек-электән килгән бер шөгыле тегермәнчелек булган. Әлеге елгаларны тегермән тоту өчен җайлаганнар. Маты елгасының Габҗәлил буасы дип аталган урыны нәкъ әнә шул эшчәнлекне чагылдырган. Старшина Габҗәлил Күчемов корган тегермән буасы шулай аталган.

Тегермәннәрнең тагын берсе 1842 елда авылдан ерак түгел Казыяр елгасында Мөхетдин Бикташев һәм Мөхтәрулла Нигъмәтуллиннар тарафыннан төзелгән. 1853 елга кадәр ул бер ташлы он тарту тегермәне дип хисаплана. Шул елны Мөхтәрулла тегермәнне тотудан баш тарта, хуҗа булып Мөхетдин кала. Ул аны үзгәртеп төзи, ярма ярдыру өчен дә яраклы итә. Яңа җиһазларга 300 сумнан артыграк көмеш акча тота. Әмма Бикташевның чыгымнары юкка була, Бәләбәй өяз суды карары белән 1854 елда тегермән ябыла[1].

Сәбәбе – тукбирделеләр белән җир бәхәсе, бу тегермән алар белән килешеп төзелмәгән, янәсе.

Мул сулы елгалар булганда, тегермәннәрнең берсе юкка чыкса, яңа урында икенчесе төзелгән. Буадан өстәрәк Җәмил тегермәне була. Аннары Җәмилев Галим үз тегермәнен төзи. Ул зур түгел, урман эчендә (Кирәмәтне төшеп, басудан 400 метр барып) урнашкан була. «Нурулла Нәбиуллинның (Гобәй нәселе) суыргычы, Казыярда тегермәне булган», дип искә алган иде бервакыт элеккеге укытучым Кыям Кадермөхәммәт улы Ситдыйков.

Башка шөгыльләргә тукталып үтик. Хәмит Габдерәхим улы Маликов сөйли: «Чабатачылар урман очында яшәде. Болар – Хәбир, Габдрахман Йосыповлар иде. Заман карт, Урыс Абдулласы (укымышлы булса да, дин тотмаган, шуңа «урыс» дигән кушамат такканнар), Шакир карт, синең бабаң Кәримов Шәй-

[1] БҮДТА, И-2 ф., 1 тасв., 3866 сакл. бер., 179–182 бб.

мөхәммәт кәлүшчеләр булды. Абдулла дегет куу белән шөгыльләнде. Нәбиев Хаҗиәхмәт баштарак кибет тотты, аннары дегеткә күчте».

Урман очы дип Килкабыз ягына сузылучы урамны атаганнар. Авылның бу очы катнаш (нигездә, имән, юкә, сөян агачлары) урманнан торган булган. Агач эше белән бәйле төрле һөнәр ияләре (балта осталары, чабатачылар, мичкә, тәгәрмәч ясаучылар һ.б.), нигездә, бу урамда яшәгән.

Тире иләү, күннән аяк киеме тегү Катайда киң үсеш алган, хәтта бу хакта статистик әдәбиятта да махсус әйтелә: «Иске Катайда 28 хуҗалыкта күн аяк киеме тегү белән 34 һөнәрче һәм 5 ялчы шөгыльләнә. 23 хуҗалыкта бары тик кәлүшләр генә тегәләр. Ел саен 7364 парга кадәр җитештереп, аны Бәләбәй өязенең зур базарларында, еш кына авылдан дистәләрчә чакрым ераклыкта урнашканнарында ваклап саталар»[1].

Бу мәгълүматларга кечкенә генә бер истәлек өстик. Аны авылдашым Закиров Әшрафҗан Шакирҗан улының бүгенге көндә Златоуста яшәүче кызы Лира Аллахколыева сөйләде. Ул үзенең бабасы Закирның итекләр тегүче, ярдәмчеләре-өйрәнчекләре булуын белә икән. Һөнәрченең бер истәлеге булып өй урынында ул утырткан агач, Закир өянкесе үсә. Закирның улы Шакирҗан да һөнәрле була, тегү эше остасын Бөек Ватан сугышы елларында фронтка киемнәр тегәргә тылда калдыралар.

Хәмит абый үз истәлекләрендә берничә кәлүшченең исемен әйткән иде. Башкалары хакында 1917 елгы хуҗалыклар исәбен алу документларыннан беләбез. Иске Катайда – Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәев, Гайфетдин Шәмсетдинов, Шәйхезаман Вәлиәхмәтов, Әхмәтзариф Фазлыйәхмәтов, Мөсәлимвәли Әхмәтов, Фәхретдин Җәләлетдинов һәм Әхәзулла Шаһиәхмәтовлар, Яңа Катайда Муллаян Имамәтуллин кәлүш тегү белән шөгыльләнгән.

Яңа Катайда бур җитештерү үсеш ала. Моның белән, нигездә, Арсланбәк нәселе шөгыльләнгән. Моның өчен бур чыгарасы урынны көздән (чокырын казып) әзерләп куйганнар. Чана юлы төшү белән утын ташыганнар, чималны, утын сыярлык итеп куышлап, түгәрәк чокырга өйгәннәр, аннары унике сәгатьләп яндырганнар. Ташны чүкеч белән ватып, иләк аша үткәргәннәр. Әзер бурны капчыкларга тутырып, базарларга алып чыгып сатканнар. Хәтта шактый ерактагы Минзәлә ярминкәсендә дә Катай буры сатыла торган булган.

Бур чыгару белән бәйле бер истәлекне Мөнир Габбәс улы Гомәров сөйләде. Матының Екатеринински 4 нче санлы спирт заводына (Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан аның хуҗалары булып В. И. Видинеевның варислары тора) дөяләр белән ераклардан икмәк китерә торган булганнар. Буш кайтасы итмәгәннәр, Катай аша юл тотып, моннан бур төяп киткәннәр. Алар шул кадәрле күп булганнар, күрәмсең, Маты елгасы аша чыгышлый су эчәргә тукталгач, елганың аскы өлешендә хәтта су бетеп торган, имеш...

«Катай авылы – зур авыл, бур авыл», дип әйткәннәрен ишеткәнегез бардыр, мөгаен. Караклык (бурлар) һәр җирдә бар, ә менә бур чыгару урыннары

[1] Кустарные промыслы Уфимской губернии.– Уфа, 1912, б.13, 16.

сирәк авылларда гына. Халык шаяртып, бурлы авыл димәгән, «бур авыл» дип әйткән, имеш.

Китаптагы фоторәсемдә бур чыгаручыларның берсе — Мәннапов Исламгалине (1889—1964) күрәсез. Аның оныгы Рәсимә Шәйдуллина искә алганча, Исламгали бурны базарга алып барып та саткан, умарта да тоткан. Өч сугышта катнашкан (Беренче бөтендөнья сугышы, гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы; егерменче елларда сәнәкчеләр белән бәйле вакыйгаларда да катнашып алган).



**Мәннапов Исламгали**

Яңа Катайда чабата үрү дә киң таралган була. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан 20 хуҗалыкта чабатачылар яшәгән. Әлеге мәгълүматлар махсус әдәбиятта китерелә[1].

Яңа Катайдагы кайбер чабатачыларның исемнәре 1917 елгы исемлектә дә китерелә. Болар — Мөслихетдин Галләметдинов, Хөснулла Хисмәтуллин һәм Лотфулла Сафиуллин. Хөснулла карт пожар каланчасында карауылда да торган. Иске Катайдан Миңлегалим Җәмилев, Шәрәфетдин Шатбәһаровлар да чабата үрү белән шөгыльләнгән.

Авылның бу ягында җитештерелгән балталар җирле ихтыяҗны гына канәгатьләндереп калмаган, базарларда да сатылган[2].

Тегүчеләр, нигездә, Яңа Катайда яшәгән. Болар — Фатыйма Мөхәммәтшина, Фәтхетдин Нуретдинов, Дәүләтбай Шәрәфетдинов, Әхмәтгәрәй Күчемов.

Иске Катайда агач яручылар күп була. Әлеге исемлеккә Вәлиулла Сафиуллин, Нәдергол Шәмиголов, Насыйфулла Фәрхетдинов, Сираҗетдин Яхшыголов, Габделкадыйр Габделхаликов, Төхвәтулла Хөснетдинов, Мөхәммәтдин Камалетдинов, Кадермөхәммәт Мөхәммәтситдыйков, Гаязетдин Насыйров, Әхмәтвәли Җәләлетдиновның 2 улы, Исхак Ибраһимов, Мөхәммәтназыйф Шәфиков (үзе һәм улы), Мөхәммәтша Шәрәфетдинов, Кәраметдин Кашшафетдинов, Госмангали Мөхәммәтшәрипов, Мөхәммәтнәби Вәлиәхмәтов, Габдулла Фәрхетдинов, Шәех Дәүләтбаев һәм Дәүләтгир Дәүләтбаевлар керә. Солтан Гәрәев, Фәрислам белән Нурислам Габделихсановлар, Шәйхенур Шәйхелисламовлар агач эше осталары буларак билгеле. 1917 елгы документта, ни сәбәпледер, Яңа Катайдан бары бер генә балта остасы (Галләметдин Сәйфетдинов) күрсәтелә.

Документта бер генә дегет җитештерүче — Фәррахетдин Мифтахетдинов теркәлгән. Әмма, картлар сөйләвенә караганда, Иске Катайдан Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәбиев, Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәтовлар да дегет куганнар.

[1] Кустарные промыслы Уфимской губернии.— Уфа, 1912, б.64.
[2] Кустарные промыслы Уфимской губернии.— Уфа, 1912, б.101.

Сүз уңаеннан әйтик, әлеге һөнәр авылыбыз янындагы берничә урынның дегет базы дип аталуына сәбәпче булган. Кайчандыр каенлыклар булган ул җирләрдә, каен тузын яндырып, дегет куып ята торган булганнар.

Иске Катайдан Әбелфатыйх Гатиятуллин слесарь, тимерче буларак билгеле, аның Маты буенда алачыгы булган. Үзе кебекләрдән зур осталыгы белән аерылып торган, ат кадагына чаклы ясаган, заказга да эшләгән. Әсләм абый Күчемов сөйләве буенча, Әбелфатыйхның алты улы (Фоат, Мигзам, Локман, Гыйльван, Кыйбан, Габделәхәт) була. Ул гаиләсе белән Чүмәлә Катайга күчә. Бертуганы Шәрифулла исемле, аның уллары Салих һәм Даһид була.

Иске Катайдан Мөхәммәтсолтан Сафин, Габдулла Галләмов сәүдә иткән. Гомәр Йосыпов ит сәүдәсе белән даими шөгыльләнгән. Яңа Катайда Петр Урысов, Шәяхмәт Дәүләтшин, Мөхәммәтзариф Яруллиннар кибет тота – сәүдә итәләр. Иске Катайдан Фәррахетдин Шәйхетдинов сирәк һөнәр иясе – айгыр печүче.

Умартачылар, нигездә, Яңа Катайда күрсәтелә. Болар – Мөхәммәтсафи Габсаттаров (15 баш умартасы бар), Дәүләтгәрәй Миңлегәрәев (8), Шакир Латыйпов (7), Вәлиәхмәт Мөхәммәтгалин (2), Мөхәммәтнасыйх Җәмилев (1). Авылның урман-яланнарга якын утыруы умартачылык өчен гаять уңай шартлар тудырган. Иске Катайда исә бу шөгыль өчен мондый ук уңайлыклар булмый. Шуңадыр, бары тик Әхмәтлатыйф Мөхәммәтнәбиев кенә 2 баш умарта тота.

Дөньялар ничек кенә, кайсы якка үзгәрмәсен, һөнәр һәрвакыт кешенең таянычы булган һәм булачак та. 1917 елдан соңгы чорга күз салыйк. Алдарак телгә алынган Заман карт егерменче-утызынчы елларда да итек теккән, умарта тоткан. Мулла булып та торган. Шәймөхәммәт Кәримов (әтиемнең атасы) сугышка чаклы пычак, урак кебек тимер әйберләре ясау белән шөгыльләнгән, аны Бакалы базарына да алып чыгып сата торган булган (ул, алдарак әйтелгәнчә, берара итек, кәлүш тә теккән бит әле). Сакатта гомер иткән кардәшебез Нәҗип абый Мәҗитов аның өйрәнчеге булып йөргән, аннан шул авылның колхоз тимерчелегендә мөстәкыйль эшли башлаган. Җәмгыйтдин Күчемов, Гата Хафизовлар оста мебель ясаучылар булдылар. Җәмгыйтдин абый ясаган сандыклар әле дә шактый гына кешеләрдә бардыр. Хәсән абый Шакиров теккән туннар кышларын кемнәрне генә ачы салкыннардан сакламагандыр. Тегүчеләр дигәннән, Кәшбел абый Әхмәтовны да күрсәтеп үтәргә кирәктер. Сырма, пәлтә ише кием-салым тектерергә аңа ярты авыл йөргән. Гариф мулла һәм аның уллары Гавис, Әсләм, Мөстәкыйм Күчемовлар мич чыгаручы буларак дан тотканнар. Гавис абый, өстәвенә, сәгать тә төзәткән. Балта остасы Рим абый Нәбиев салган йортлар Катайда гына берничә дистәдер. Ат арбалары, тарантаслар, чаналар, тәгәрмәчләрне гел диярлек урман очы осталары (Шәйхеразыевлар һәм башкалар) ясый торган булган. Сугыштан соңгы елларда Әнгам Исмәгыйлов озак еллар такта яра.

«Минем карт әтием – Фәрвазов Авзалетдин, чабата үрә, орчыклар ясый, ул ясаган тәрәзә йөзлекләре (наличниклары) искиткеч матур иде. Аның энесе Әгъзам абый тәгәрмәчләр һәм ат арбасы ясый иде. Бабам Авзалетдин ясаган орчыкларны карт әнием Миңнеҗиян Маты һәм Бакалы базарларына алып барып сата иде. Без бала чакта базарлар Иске Матыда шимбә, Бакалыда якшәмбе көннәрне була иде», дип искә ала үз нәселдәшләрен Рузидә Мөдәррис кызы Әхтәмова (Фәрвазова).

Инде катайлыларның барлык һөнәрләре әйтелеп бетте дигәндә аучылар белән балыкчылар искә төште. Бу уңайдан күп нәрсәдән хәбәрдар авылдашым Фиркать Исламовка шылтыраттым. Ул беренче чиратта бабасы Исламов Ситдыйкны искә алды. Аның өч мылтыгы булган икән, куян-бурсык ише җәнлекләрне ауларга йөргән, балыкчылар өчен мордалар да ясаган. Мөстәкыйм абый лесник булып, урманда яшәп ятканда, мордалар куеп калдырып балык тотканын әле мин дә хәтерлим. Бурсыкны Рәхмәтулла Гарифуллин да аулаган, димәк, бурсык маеның кайбер чирләрдән дәва икәнлеген халык белгән һәм кулланган. Аучылык Наил Зариповның, аның энесе Вәзирнең дә яраткан шөгыленә әйләнде.

Һөнәрнең беркайчан да артык булганы юк. Шуңа күрә яшьләргә, вакытыгызны заяга үткәрмәгез, җитеш тормыш итәр өчен күбрәк һөнәрләргә өйрәнергә тырышыгыз, дип әйтәсе килә. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дип әйтә торган булган борынгылар. Һөнәрле булуның әһәмиятен чагылдыргандай, осталык – иң зур байлык дип тә әйткәннәр. Үз эшенең, төрле һөнәр осталары күбрәк булган саен җәмгыятебез дә алга китәчәк, тормыш итү шартлары да җиңеләячәк.

## Ниләр генә күрмәдек!..

Патшаны бәреп төшерү, Русия хакимиятенә Ленин җитәкчелегендәге большевиклар килү авылдагы тормыш агышына яңа төсмерләр кертә. Игенче түземлек белән вәгъдә ителгән җир реформасын көтә, илдә барган хәлләрне яхшылыкка юрарга тырыша, матбугат хәбәрләрен йотлыгып укый.

Шундый ихтыяҗ һәм өметләрне күздә тотыптыр, 1918 елда иске мәчет йортында беренче китапханә ачыла. Монда иллеләп татарча китап була, гәзитләр дә кайтарыла башлый. Мөдире Корыч авылыннан Һади исемле кеше була.

Ул вакытта авылда әле клуб булмый. Төрле тамашага, уен-көлкегә маһир яшьләрне тоткарлыймы соң бу! Әле бер йортта, әле икенчесендә кичәләр оештырылып тора, шунда ук пьесалар да уйныйлар. Үз араларыннан «артист»ларны барлап, Күчемов Кәнҗелләрнең күршесендәге мөәзин йортында 1918 елның 13 августында хәтта беренче тапкыр концерт та куялар.

Гражданнар сугышы бара – зар көтеп алган тынычлык һаман килми. Авыл аша аклар да, кызыллар да үтеп йөри. Алар Маликов Хәмит абыйларның биек, иркен өенә туктап, кунып та чыккалаганнар. Гавис абыйлар урыны янындарак урнашкан мәчет манарасына да, Кирәмәт башына да пулемёт куела, әмма хәлләр атышларга чаклы барып җитми.

Шулай да аклар узып йөрүе эзсез калмый: Мөхәммәтхарис Мөхәммәтшин белән Мөхәммәтдин Камалетдинов (Рабитның бабасы) атып үтерелә. «Аклары да талады, кызыллары да», дип искә алалар иде картлар.

Хронологик тәртиптә карасак, 1918 елның июль ахырыннан алып, ноябрьнең соңгы көннәренә кадәр хәзерге Бакалы районы территориясе Колчак гаскәрләре кулында була, декабрьдә Кызыл армия килә, ә инде 1919 ел башында тагын аклар җиңү яулый.

Апрель аенда кызыллар килеп, акларны куа китәләр. Май аенда чапаевчыларның 41 нче Курский полкы авыл аша уза. Аның сафларында Ахунов Галимҗан, Харисов Кәнҗел, Нурисламов Зиннәтләр була. Катайдан башка бик күп ир-егетләр дә Кызыл армия сафларына алынып, акларны кууда катнашалар, бары егерменче еллар башында гына әйләнеп кайталар.

Аклар тәмам куылгач кына чын-чыннан совет хакимияте урнаша, Катайда 2 авыл советы төзелә. Иске Катай авыл советының беренче рәисе Әхмәтхан Дәүләтов, секретаре Фәез Газизов була. Авыл советының үз бинасы булмый, ул Исламгали Әхмәтов йортының бер башына урнаша. Яңа Катай авыл советының беренче рәисе Мөхәммәтгали Нигъмәтуллин, секретаре Галикарый Күчемов була.

Большевиклар хакимияте авыл җирендә яңа тәртипләр урнаштыра башлый. Шуларның берсе «хәрби коммунизм» була. Барысы да бушлай, һәр нәрсә уртак, янәсе. Игенче үзеннән арткан икмәкне юк кына бәягә хөкүмәткә тапшырырга тиеш була. Әмма авыл кешесенең моның белән ризалашасы килми. Менә шуны аңлап, большевиклар 1919 елны кораллы отрядлар («продотряд»лар) төзеп, ашлык җыю өчен авылларга җибәрәләр. Йорттан-йортка йөреп, кешеләрнең хәтта симәнәгә дигән икмәгенә чаклы тартып алып, аны олауларга төяп, бүтән тарафларга алып киткәннәр...

Продотрядлар казасыннан бик сирәк кешеләр генә саклап кала алган икмәкләрен. Шуларның берсе – Габдерәхим Маликов. Ул үз ихатасындагы атларны елгага су эчәргә алып төшә торган сукмакка чокыр казып, шунда яшергән симәнәгә дигән капчык-капчык икмәкне. «Аның белән җәфаланулар сөйләп бетергесез», дип искә ала аның улы Хәмит абый. Чөнки икмәкне черемәсен дип әледән-әле кеше-фәләнгә сиздертмичә казып алырга, аннары, аулак урынга алып чыгып, җилләтергә кирәк булган.

Туктаусыз сугыштан, талаулардан, салымнардан йончыган халык үз икмәген бушка бирергә теләми. Сәнәк, ау мылтыклары, обрезлар, балта һәм ломнар белән коралланып, «Кара бөркет» восстаниесенә кушыла. Баш күтәрүчеләрнең штабы Кәчти авылында урнашкан була. Катайдан да Кәчти ягына өере-өере белән китәләр: тимерче Әбелфатыйхтан штыклар ясаттырып, үзләренчә коралланып.

Билгеле булганча, 1920 елның февраль-март айларында халык фетнәсе кораллы көч ярдәмендә бастырыла. Ил башына нинди рәхимсез хакимият килгәнлеген күпләр шунда аңлый да.

1920 елгы халык санын алу вакытында Иске Катайда 272 хуҗалыкта 650 ир-ат һәм 643 хатын-кыз яши. Яңа Катайда 388 йортта 922 ир-ат һәм 966 хатын-кыз теркәлә[1].

Ул елның җәе чиктән тыш эссе була, үләт чире таралып, шактый халыкны аяктан ега.

Шул елның җәендә Иске Катай халкының бер өлеше «Үрнәк II» (мондый исемле колхоз Кыргыз-Миякә олысында да була, шуңа күрә безнең авылныкына шундый сан бирелә) күмәк хуҗалыгын оештырып, аны Бәләбәй өязенең җир бүлегендә (земотдел) 13 августында теркәтә. Менә шул гаиләләрдән Бикләндедә, Чайковская хуторы урынында бер урамлы Үрнәк авылы барлыкка килә (сез аны тексттагы 1926 елгы картада күрәсез, анда «Урняк (б. Узунбурун)» дип язылган).

Яңа катайлылар да «Чүмәлә» күмәк хуҗалыгы оештырып, аны 2 августта шулай ук теркәттерәләр[2].

«Үрнәк» озын гомерле булмый, утызынчы еллар башында ук таркала, ә менә «Чүмәлә» кала, шуңа авыл да Чүмәлә Катай дип атала башлый.

[1] Список населенных пунктов Башреспублики, б. 32.

[2] БҮДТА, Р-161 ф., 1 тасв., 803 сакл. бер., 2, 3 бб.



**1926 елгы карта фрагменты**

1921 елны игеннәр уңмый, ачлык башлана. Болай да икмәк запасы калмаган халык бик авыр кичерә ачлык афәтен. Кешеләр моңарчы ризык саналмаган агач кайрыларын һәм тамырларын, төрле үләннәрне ашыйлар.

«Элмә агачының нечкә ботакларын – сарыклар, юанракларын атлар кимерә иде. Ул агачның кайрыларын каерып, төеп, киптереп, тегермәндә тарттыра иде әтәйләр, сап-сары он чыга иде. Кычыткан, ачы кукы, аннан соң үлән тамырлары ашый идек. Язга чыккач атларны Бөгә буена ашатырга алып чыктык. Кар эреп бара, ямь-яшел үлән чыгып бара. Атлар язгы чәчүгә симерделәр, көрәйделәр»,– дип сөйләгән иде шул елларның шаһиты Хәмит абый Маликов (1912 елгы).

Ачлыктан ярты авыл кырыла. Балаларга өләшенгән Америка паекларын исәпләмәгәндә, читтән ярдәм булмый диярлек. Күп очракта гаиләләр бөтенләй бетә яисә өй башына бер-ике кеше генә кала. Мәсәлән, Әхмәтгәрәй Күчемовның хатыны, 4 улы һәм 2 кызы булса, 1921 елда берүзе генә торып кала.

1922 елда «Җир секциясе» төзелә, аның рәисе Сафакай Гәрәев, секретаре Нәгыйм Сафин була. Алар җан башына җир бүлүне оештыра, хатын-кызларны да исәпкә кертәләр.

Хәмит Маликов әйтүенчә, бу чорларда авыл советы рәисе вазифасын Әхмәдулла Габдуллин башкарган. Аның хуҗалыгы хәзерге мәктәп йорты урынында була. 1921 елны күршесе ут төртеп, бөтен хуҗалыгы янып бетә, үзе гаиләсе белән 1922 елны читкә чыгып китә.

1924 елда беренче комсомол оешмасы төзелә, аның секретаре Сөләйман Габдуллин була. Оешма 5 кешедән тора. Садрелиман Вәлиәхмәтов, Фазлый Шәяхмәтов, Мифтаховлар беренче комсомоллар булалар.

1925 елда авыл советлары берләштерелеп, Яңа Катай авыл советы исемендә һәм штатында кала.

Егерменче елларның башы яңача укыту оештырылу белән истәлекле. Архив документларына күз салсак, Иске Катайда мәктәп 1920 елның сентябреннән эшли башлый. Ул урысча «Старокатаевская школа 1-ой ступени» дип атала. Мәктәптә урыс (атнага 12 сәгать) һәм татар (18 сәгать) телләре, арифметика (6) һәм хисап (6) укытыла. Укытучылар Тихонов Юзей (18 яшь) һәм Нәбиев Гыйлембаян (24 яшь) була. Мәктәпкә 45 ир һәм 5 кыз бала укырга йөри башлый. Уку иртәнге 8 дән көндезге 12 гә чаклы дәвам итә, 50 шәр минутлык 4 дәрес, алар арасында 10 шар минутлык 3 тәнәфес була. Мәктәп салам түбәле, биш тәрәзәле арендага алынган агач йортта урнашкан, парталар булмый[1].

Яңа Катайда мәктәп бер ел алдарак, 1919 елның сентябрендә ачыла. Анда укытучылар булып Илларионов Алексей (33 яшь; 1919 елдан) һәм Нәбиева Гания (22 яшь; 1920 елдан) эшли. 1920 елның сентябрендә мәктәпкә 65 укучы килә. Барлык балаларга нибары 48 бит кәгазь, 20 штук дәфтәр, 37 китап (букварь) була[2].

Катай мәктәпләренең ничек эшли башлавы һәм беренче адымнары турында авылыбыз тарихына багышланган альбомда да әйтелә: «1920 елда ук Вәлиева Камилә белән Булатова Гания һәм Сания Шәмсемөхәммәт кызлары аерым йортларда балаларны татар һәм урыс телләрендә укырга-язарга өйрәтә башлыйлар. Алар Камай авылыннан, Бәләбәй шәһәрендә педагогик курслар бетергән булалар. Нәбиев Гыйлембаян Әхмәтлатыйф улы да берара укытып ала. Бу чорда авылда 97 кеше укый. 1924 елдан Маликова Бану, Хафизов Гата, Вәлиев Фәвәрис Хан улы йортларында Маня Ишембаева (Иске Матыдан), Алексеев (Балыклыдан), Тимергали Госмановлар укыталар.

Мофаздалова Галимә истәлекләренә караганда, 1924–25 уку елына балаларны 1–2 классларга кабул итәләр. Корыч олысыннан укытучы итеп Борһанова Хәнифәне җибәрәләр. Урыс телен Егорова Люба исемле Катай алпавыты кызы укыта. Совет мәктәбенең 4 классын тәмамлаучы иң беренче укучылар Мофаздалова Галимә, Хәсәнова Рәйфә, Шәрифуллин Заһит, Гәрәева Сәхипзадә, Ихсанова Сәкинә, Хәбирова Һәдияләр була. Уку бер бинада алып барыла, барлыгы 15 укучы исәпләнә.

Егерменче елларның икенче яртысында Яңа һәм Иске Катайда берәр мәктәп була. Яңа Катайда башта Исмәгыйль өендә укыталар. Аннары мәктәпне киңәйтәләр. Кәчтидән бер кулакның өен сүтеп алып кайтып, аны мәктәп бинасы итәләр. Ул дүрт-биш бүлмәле була. Соңрак өченче мәхәлләнең өлкән мулласы Галимулланың малайлары Кәбир белән Хәмитнең өйләре мәктәп өчен файдаланыла. Мәктәптә берара Корычтан да (бер хатын-кыз), Сеңрәннән дә (Тимергали исемле кеше) укытырга килүчеләр була».

1926 елда кабат халык санын алалар. Статистик басма мәгълүматларына караганда, бу юлы Иске Катайда – 247, Яңа Катайда исә 297 хуҗалык теркәлә. Архив чыганаклары да шул чама хуҗалыклар санын күрсәтә. Иске Катай 246

[1] БҮДТА, Р-473 ф., 2 тасв., 574 сакл. бер.

[2] БҮДТА, Р-473 ф., 2 тасв., 572 сакл. бер.

хуҗалыктан, 512 ир-аттан һәм 533 хатын-кыздан тора. Яңа Катайга 314 хуҗалык, 641 ир-ат һәм 738 хатын-кыз туры килә[1].

1920 елгы мәгълүматлар белән чагыштырсак, алты ел эчендә хуҗалыклар һәм халык саны шактый кимегәнен күрәбез (Чүмәлә Катайга күчкәннәрне исәпләп тә әле). 1921 елгы ачлык афәте статистикага әнә шундый тискәре үзгәрешләр керткән.

Егерменче еллар — НЭП (яңа икътисади сәясәт) чоры. Игенче иркен сулыш ала. Үз җирендә тир түгеп җитештергән икмәкне ул, патша заманындагы кебек, базар бәясенә, теләсә кайда сата алган. Ашлык амбарларында һәрвакыт икмәге булгач, халыкның да бу чорда күңеле көр була.

Документлардан күренгәнчә, Иске Катайда сельпо карамагындагы кибет була. 1927–1929 елларда монда сатучы булып Сәмигулла Хафизов эшли. Аннары ул дүрт ел чамасы (1929–1932) Яңа Катай сельпосы рәисе вазифасын башкара[2].

Бу чорда Катай мәктәпләрендә элеккеге укытучылар киткән, яңалары килгән була. Иске Катайда мәктәп «Старо-Катаевская единая трудовая школа 1-ой ступени» дип атала. Аның җитәкчесе һәм укытучысы Госманов Рухылбаян (1888 елның 14 августында туган) була. Аңа айга 48 сум 50 тиен хезмәт хакы билгеләнгән. Монда 1928 елда 40 ир һәм 30 кыз бала укый. Әмма мәктәп бинасы кечкенә булу сәбәпле, 54 баланы укырга алмыйлар. Яңа Катайның шундый ук мәктәбенә Сөбханкулов Латыйп Ситдыйк улы (1902 елның 28 сентябрендә туган) җитәкчелек итә, укыта да (хезмәт хакы 51 сум). Ул 1927–28 елларда Уфадагы рабфакта өч курс укыган, мулла малае (атасы 1912 елда мәрхүм булган). Бу мәктәптә аннан башка тагын 9 класс белеме булган керәшен кызы Асанбаева Вера Иван кызы (1908 елның 25 сентябрендә туган) укыта, аның айлык хезмәт хакы 46 сум була. Мәктәпкә 1928 елда 35 ир һәм 25 кыз бала укырга йөри, 55 баланың андый мөмкинчелеге булмый, чөнки бина кечкенә[3].

Ул чорның якты хатирәсе булып өлкән буын кешеләре күңелендә, күпләре әле ул чакта бала-чага гына була, җыеннар истә калган. Алар июнь аенда, авыл саен өчәр-дүртәр көн үткәрелгән. Иң башта Сеңрән җыены, аннары Катайныкы, аннары Сакатныкы. Катай җыенына тирә-як авыллардан килгәннәр, катайлылар үзләре дә башка авылларга бара торган булганнар. 1924 елдан Катай җыенын Гыйният дигән кеше алып барган, туган авылы Рапаттан өч-дүрт ат белән килә торган булган. Ул көчле, нык, таза булган, тарантаска утырганда үзе янына кеше сыярлык булмаган, ди. Килкабызны чыккач та уйнатып җибәрә икән гармунын, шул мизгелдән авылда берничә көн зур бәйрәм рухы хөкем сөргән. Җыен бизәлгән тарантаслар белән мәйданны әйләнеп чыгудан башланган, көч сынашулар, кичләрен уеннар үткәрелгән. Гыйниятнең

[1] БҮДТА, Р-472 ф., 1 тасв., 545 сакл. бер.

[2] Башкортстан җәмгыять оешмалары үзәк дәүләт архивы (БҖОҮДА), П-638 ф., 2 тасв., 1564 сакл. бер., 163–165 бб.

[3] БҮДТА, Р-472 ф., 1 тасв., 632 һәм 678 сакл. бер.

аю-курчаклары янында бала-чага мәш килгән, шунда ук төрле тәм-том сатып алырга мөмкин булган. Зур бәйрәмнән беркемнең читтә каласы килмәгән: уҗым җирен сату исәбенә булса да акча юнәтеп барганнар.

НЭП чорындагы иркенлек озакка бармый, авыл өчен тагын авыр көннәр башлана. Илне индустрияләштерү планын тормышка ашыру авыр йөк булып игенче җилкәсенә ята. Авылдан күбрәк һәм арзан хакка икмәк алып, аны чит илләргә сатып, кергән акчага яңа завод-фабрикалар төзү юлын сайлый большевиклар. Игенче тир түгеп үстергән икмәген юк кына бәягә бирмәс, ә менә күмәк хуҗалыклар (колхозлар) оештырганда, алардан теләсә күпме, кирәк икән бушка да алырга була түгелме? Менә шулай 1929 елда илдә колхозлаштыру хәрәкәте җәелдереп җибәрелә.

Ирекле булуның тәмен татыган игенченең күңеле сүрелә башлый. Аның бер дә мал-туарыннан, күпме тир түккән, өметләр баглаган җир кишәрлекләреннән аерыласы килми. Колхозга кермәс иде дә, яныйлар, куркыталар, кулаклар, совет хакимиятенең дошманы дип төртеп күрсәтәләр, төрмәләргә ябалар. Илдә авыр сәяси атмосфера хөкемлек сөргәндә, халык «дошманнарын» эзәрлекләү барганда кая инде элеккеге кебек күңел ачу кайгысы! Моңарчы үткәрелеп килгән җыеннар да соңгы тапкыр 1931 елда була да бетә. Аннан алдарак кына ярминкәләр туктала. Гыйният тә 1929 елны килә дә, юкка чыга, дистәләрчә еллар үткәч кенә, Урта Азия якларында аны күргәннәр (1968 елда әле исән була).

...Тарих җебе әллә нинди афәтләр, матавыклар аша, гасырлар аша сузылганда иркен сулыш алырдай чорларга да тоташып-тоташып үтә. Заманасына карап, кешеләрнең генә түгел, буыннарның да елаган, сөенгән чаклары була. Ни хикмәттер, тормыш дигәнең никадәр генә рәхимсез, ачы тоелмасын, барыбер яшисе килә! Без, үзебез дә сизмәстән, табигый сайланмыш дигән мохиттә яшибез: көчсезләр, хәлсез рухлы кешеләр күбрәк кырыла, өметен өзмәгән, тормышка теш-тырнагы белән ябышкан затлар яши, тернәкләнә, үрчи, һәр гасырда тамыр ныгыта. Шулар хакында уйга бирелә белсәң, бер нәрсәне аңлый башлыйсың: Ходай безне бу дөньяга күңел ачу, сөенү өчен генә бар итмәгән, бәлки, зур сынаулар үтү өчен дә яраткан. Күренә ки, авылым халкы да бу сынауны сабырлык һәм түземлек белән уза. Алда да булмый калмас әле ул көтелмәгән, исәп ителмәгән хәлләр. Тик ахыры хәерле булсын!

## Болганчык еллар

Иң беренчеләрдән булып 1929 елда «Яңа тормыш» колхозы төзелә. Аны оештыруда Иске Корыч авылы егете Миргасыйм Каюмов зур ярдәм итә. Озак та үтми бу колхоз тарала башлый. Бары тик 13 хуҗалык кына (Шәех Галләмов, Хуҗагали Гомәров, Исмәгыйль Ибраһимов, Галикарый Күчемов, Шәйхелислам Күчемов, Кәнҗел Күчемов, Насыйп Нәбиев, Әнвәр Сәлахов, Сәйфулла Шәйхетдинов, Әслах Шәрәфетдинов һәм башкалар) торып кала. Беренче рәис — Сәйфулла Шәйхетдинов, хисапчы исә Галикарый Күчемов була. Аннары колхозга Мәҗит Хәсәнов җитәкчелек итә. 1933 елда колхозның 150 гектар җире була.

Иске Катайда беренче күмәк хуҗалык 1930 елда оеша, рәисе — Габдуллин Рәхмәтулла (Фәритнең атасы), секретаре Заһир дигән кеше була. Әмма бу колхоз да озакламый тарала. Анда унбиш кеше (Нәбиев Хаҗи, Котдус, Фазлыйәхмәтов Габдулла (Урыс Абдулласы), Борһанов Хәйдәр (Әүһадинең атасы), Ситдыйков Нурулла, Дәүләтов Әхмәтхан, Сафин Нәгыйм һәм башкалар), алары да мәҗбүриләп кертелгән була. «Байкал» исеме белән яңадан оешканда беренче рәис Ситдыйков Нурулла, хисапчы Сафин Нәгыйм, бригадир Нәбиев Хаҗи була. Аннары Фәррахов Мөхәммәтдин (1934 елның февралендә сайлана; истәлекләргә караганда, ул — Корычкаран кешесе), Газизов Фәез, Шәех Ханы һәм Үмердән Катайга пима басучы булып килгән бер кеше алты-җиде айлап рәис булып торалар. 1933 елда 33 хуҗалык берләшкән бу колхозның 70 гектар җире була.

Утызынчы еллар шул ук вакытта тоталитар хөкүмәт эзәрлекләвеннән шактый халык аянычлы язмышка дучар булган чор булып та тарихка керде. Документларга күз салсак, Катайдан гына күпме кеше бернинди гаепсез көе Сталин төрмәләренә ябылган яисә ерак тарафларга сөрелгән. Кеше язмышы сукыр бер тиенгә дә тормаган аяусыз заманалар...

1930 елның 26 августында Яңа Катайда аерым хуҗалыклы Дәүләтшин Шаһимөхәммәт кулга алынып, берьюлы өч статья (58–8, 58–10, 58–13) белән гаепләнеп, 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Ярты гасыр үткәч, ягъни 1989 елның 11 маенда, бу кешене реабилитацияләү турында карар чыгаралар, әмма ни файда? Үзе исән чакта ук моны эшләсәләр, ул, бәлки, сөенгән дә булыр иде.

1931 елның апрель-май айлары — күп кенә катайлыларны тетрәндергән чор. Иң башта, 14 апрель көнне, Яңа Катайдан Нурмөхәммәтов Сафуан (1899 елда туган), Сәлахов Әнвәр (1901), Госманов Шәйхенур (1904) һәм Нурлыгаянов Кәшфел Мәган улын (1901) өйләреннән алып чыгып китәләр, беренчесен — 3 (58–7 статья буенча), калганнарын (Шәйхенурның срогы күрсәтелмәгән) 5 елга (58–7, 58–10 статьялары) төрмәгә ябалар. Икенче көнне аерым хуҗалык-

лы Хафизов Фатыйх Хафиз улын (1898) да алып чыгып китәләр, аны да шул ук статьяларга (58–7, 58–10) нигезләнеп гаеплиләр. 24 апрельдә колхозчы Хөснетдинов Насыйпны (1877) кулга алалар, хөкемдарлар аның ике статьялык (58–9, 58–10) «гаеп»ләрен тапкан булып чыга. Бу кешеләрнең «эше» бары 1989 елда яңадан каралып, гаепсез табылалар. Билгеле, бу чорда аларның берсе дә исән булмый. Хөснетдиновны Урта Азиягә качып котылган, дип сөйлиләр картлар.

Май аенда да Яңа Катайда эзәрлекләүләр дәвам итә. Колхозчылар Саяфетдинов Шәрәфетдин (1870) һәм Яруллин Зарифны (1870), 22 се көнне кулга алып, (58–9, 58–10 статьялар), беренчесен – 3, икенчесен 5 елга сөргенгә җибәрәләр (икесе дә 1989 елны аклана). 23–24 майларда хакимият вәкилләре колхозчылар Яруллин Сабит (1903), Нурлыгаянов Кәшфулланың (1901) йортларына килеп, аларны да шул ук статьялар нигезендә алып китәләр, әмма 23 октябрьдә иреккә чыгаралар.

1931 елның 29 маенда Иске Катайдан мулла Галимуллин Галимулла (1860, «башкорт»), мөәзин Латыйпов Шакир (1860), колхозчылар Галләмов Шәех (1892), Галләмов Габдулла (1863), Гәрәев Сафа (1883), Кәримов Шакирҗан (1888), Нәбиев Хаҗилар (1871) кулга алыналар (58–9, 58–10 статьялары белән), әмма шул елның 23 октябрендә реабилитацияләнәләр. Яңа Катайдан шул ук язмышка колхозчылар Галләмов Шәех (1892), Галләметдинов Афзал (1896), Кәлимуллин Нәбиулла (1865), Күчемов Насыйх (1883), Күчемов Кәшиф мөәзин (1870), Латыйпов Әлтаф (1909), Күчемов Гариф мулла (1885), Күчемов Назиф мөәзин (1888), Муллаянов Нурлыгаян (1882), Фәйрушин Галиуллалар (1867) да дучар була.

Бу кешеләрнең бер өлеше (мәсәлән, Фәйрушин Галиулла, Назиф мөәзиннәр) төрмәгә утырмый, кайсы берсе утыра (Күчемов Насыйх) яисә качып китә (Латыйпов Әлтаф Гыйният улы). Гариф мулла 5 елга хөкем ителгән булса – ел ярым үткәч кайта. Инзир, Белорецк якларында агач кисеп йөргән, нормасын гел арттырып (өчәр тапкырга чаклы) үтәп барган, конвойсыз йөргән. Тырыш хезмәтен бәяләп аны срогыннан алда азат иткәннәр.

Бакалы педагогик кабинеты мөдире Гәрәев Гәрәй (1914 елда туган) үзенең 1940 елда язган автобиографиясендә абыйсы Сафаның 1932 елда кулаклыкта гаепләнеп Караидел районына сөрелүен, аннан 1933 елда гына кайтуын күрсәтеп үтә. Кайткач та ул «Байкал» колхозына эшкә урнашкан[1].

Әйтергә кирәк, Гәрәй Гәрәев – Башкорт педагогия институтында иң беренче (1931–1933 елларда) белем алган Иске Катай авылы кешесе. Яшьли ятим калып (ата-анасы 1920 елда үләт чиреннән вафат булган), ул абыйсы Сафа тәрбиясендә үскән.

Моннан соң илдәге аяусыз репрессияләр дулкыны бераз басыла төшә (төрмәләр дә тулган, сак астында удар төзелешләрдә бушка эшләүчеләр дә артыгы белән була), ә инде 1937 елдан тагын көчәеп китә. Мисалга Габдерәхим Маликовны (Хәмит абыйның атасы) алыйк. Ул чорда бар байлыгы ике ат, ике сыер

[1] БҖОҮДА, П-638 ф., 2 тасв., 1595 сакл. бер., 298 б.

һәм өй булган. Мондый гына мал-мөлкәтле хуҗалыклар, авыл кешесе күзлегеннән караганда, бай саналмаган. Габдерәхим карт (ул 1872 елгы) колхозга кермәгән, мөтәвәлли вазифасын башкарган була. 1937 елның 5 августында кулга алу турында карар чыгарылганда, бәлки, әлеге сәбәпләр төп роль уйнагандыр. Аны шул ук елның 29 сентябрендә аталар, ә гаиләсен Архангельскига сөрәләр. 1989 елның 5 маенда реабилитацияләү турында карар чыгарып, хакимият аның да нахакка рәнҗетелгәнен таный.

Сүз уңаеннан әйтик, репрессияләр сугыш елларында да әле дәвам итә. Яңа Катайдан мулла Күчемов Гыйздрахман Хәбибрахман улы (1892 елгы) 1941 елның 3 июлендә кулга алынып (бәләкәй арбаны «Сталин арбасы» дип әйткән, дип сөйлиләр), 58–10, 58–11 статьялары буенча 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә, 1955 елның 26 ноябрендә реабилитацияләнә.

Районыбыз архивында сакланучы «Ударчы» гәзитен ачып карасаң, шул заман рухын чагылдырган шактый язмаларга тап буласың. Мәсәлән, 1932 елның 6 апрелендәге санында Катай авылыннан Күчемов Галикарыйны судка тартуны таләп иткән бер аноним язма дөнья күрә. «Ыргак» имзалы автор «Яңа Катай советы «Яңа тормыш» колхозы председателе Күчемов Галикарый үзенең җаваплы кеше булуыннан файдаланып совет председателе Баяновлар катнашлыгы белән искелек шайкасы оештырып йөри» дип яза. Колхозчыларны колхоздан куу белән куркытып, алардан «взятка» алалар, шәхси хуҗалыкларындагы малларын суялар, берсе гел эчә һәм хатынын кыйный, дигән гаепләр тагыла. (Картлардан кызыксынып, чыннан да шулай булганмы, дип сораган идем, барысы да дөрес, дип әйттеләр.) Эчтәлеге Баяновка каршы аноним хат газетаның март санында да басылган була.

Мондый язмалар басылгач, билгеле, «гаепләнгән» кеше иректә озак йөри алмый инде. Күчемов Галикарый Миркадый улы (1896) 1933 елның 14 апрелендә кулга алына, суд аны 58–7, 58–10 статьялары буенча 5 елга ирегеннән мәхрүм итә. Бары 1989 елның 15 маенда гына бу «эш» яңадан каралып, реабилитацияләү турында карар чыгарыла.

Икенче бер язма характерлы. Ул «Кулак агенты колхозны җимерү эшендә» дип атала. «Яңа Катай авыл гражданы Авзалов шул ук авыл «Яңа тормыш» колхозына өч ат сатып колхозда оялады. Авзаловның үзен атсыз калдырып колхозга оялавы колхозны ныгыту уе белән түгел, бәлки аның эшен йомшарту уе белән эшләнгән эшләре». Язма имзасыз килеш 1932 елның 10 июлендә бастырыла. Авзаловның колхозга явыз нияте булганмы-юкмы, гаеп ташланган.

Дин әһелләрен, таза тормышлы кешеләрне эзәрлекләү белән беррәттән, хакимият мәчетләрне ябу хәстәрен дә күрә. Хәмит Маликовның әйтүенә караганда, Иске Катайның икенче мәхәллә мәчете (ул хәзерге кибет урынында урнашкан була) 1927–1935 елларда клуб буларак файдаланыла. Беренче мәхәллә мәчетенең манарасын утызынчы елларда кисәләр.

Яңа Катайның беренче мәхәллә мәчете 1931 елгы көчле янгында көлгә әйләнгән була. Ә менә өченче мәхәллә мәчетенең манарасын 1935 елда кисәләр.

Бу хакта Әсләм абый Күчемов түбәндәгеләрне сөйләде: «Мәчетне кисәр алдыннан колхоз җыелыш оештыра. Анда чыгыш ясарга алдан Гали исемле кешене билгелиләр. Мәчеткә намазга барып гомер үткәрү эшне калдыра, аңа зыян итә, дип әйтергә кушыла аңа. Гали чыгып сөйли, аннары тавышка куеп, гомуми җыелышның карарын чыгаралар. Манараны кисүчеләргә бишәр метр ситсы бирәләр. Бинасының бер башын – ясле, икенчесен суган саклагыч итәләр. Сугыш вакытларында һәм аннан соңгы чорда да ясле итеп файдаланыла. Аннары бинаны сүтеп сарык фермасына бәрән йорты итеп салалар. Фермада янгын чыгып, бу йорт та яна».

Утызынчы еллар башында-урталарында авыл советы рәисләре булып Галиев Әхмәтгали, Дәүләтов Әхмәтхан, Күчемов Галикарый, Нурисламов Фәхрелислам, Баянов Габдерәхим (аны «Әптерәй» дип йөрткәннәр), Тыпыйдан бер кеше һәм Рамазанов Җиһанша Хәким улы (Куяннан) тора.

Күмәк хуҗалыклар тора-бара авыл тормышында зур урын ала. Яңа Катайда ярты авылның януы «Яңа тормыш» колхозчылары санын тиз арада арттыра. Ялгыз хуҗалыкларга әледән-әле яңа налоглар салу да колхозларга керүчеләр санын ишәйтә.

...Авыл советында сугыш елларына караган Катай авылы хуҗалыклары кенәгәсе саклана иде (аны Башкортостан үзәк дәүләт тарих архивына илтеп тапшырдым, югыйсә, кайчан да булса юкка чыгачак, таушалган, битләре ертыла башлаган иде). Анкета формасындагы бу кенәгәдә колхозга керү елын да теркәп куйганнар. Менә аннан кайбер мәгълүматлар. Нургалиев Хәйдәр (1896 елгы), Шәйхуллина Фәрхенисалар (1878) колхозга беренчеләрдән, ягъни 1930 елда ук керәләр. Нәбиев Мирзаәхмәт колхозга 1934 ел тирәсендә керә. Кәримов Шәймөхәммәт, минем бабам, 1936 елда гариза бирә.

Ул елларда һәр гектардан 10–11 центнер иген алынган. 1935 елда, Корыч машина-трактор станциясе (МТС) оештырылу белән, колхозларга беренче трактор килә. Галиев (Корычтан), Әфлах Фәтхиев, Җәмигънур Хәсәнов, Тангаев, Горностаевлар (икесе дә Матыдан) беренчеләрдән булып тракторга утыралар. Сугыш алды елларында «Байкал» колхозын – 4, «Яңа тормыш» колхозын 6 трактор хезмәтләндергән.

1936 елда авылга 3 комбайн кайта. Икесе – «Яңа тормыш», берсе «Байкал» колхозларына бирелә. Комбайннарда Фәтхелбәян Фәрхетдинов, Фәрвазетдин Гаязов, Горностаевлар эшли башлый. Бер ел да үтми, ике «ГАЗ» машинасы сатып алына. Беренче шофер Камил Нәбиев була.

Билгеле, колхозлар өчен бу техника бик аз, әле аның куәте дә чамалы гына була. Шуңа күрә аны зур нәтиҗәле файдалану игътибар үзәгендә тора. Бу уңайдан район газетасында басылган «Стахановчы Күчемов» язмасы игътибарга лаек: «Тракторист Күчемов Фәхри (Корыч МТСы) »Байкал» колхозында көзге чәчүдә һәм ашлык сугуда үрнәк булырлык эшли. Ул 20 августта көндез тракторда чәчү машинасы тагып 15 гектар урынына 22 гектар җиргә яхшы сыйфатлы итеп арыш чәчә. Шул ук көннең төнендә ашлык суктыра. 10 тонна сугу норма-

сын 20 тонна итеп үти. Күчемов стахановчы эше белән барлык тракторчыларга үрнәк күрсәтә»[1].

Күпчелек эшләр ат көче белән, кулдан башкарылган. «Байкал» колхозы – 4, «Яңа тормыш» 6 бригададан торган. Бригада саен 80 шәр ат була.

«Яңа тормыш» колхозы рәисе булып бу чорда Мирзагалим Нургалимов (1934 елның февраленнән), Мияссәр Гаделшин (1934–1935) һәм Салихҗан Сарьяновлар эшли. «Байкал» колхозына 1935 елны яңа җитәкче – утыз яшьлек Хәбиб Солтан улы Солтанов (Куштирәктән) килә.

Әйтергә кирәк, колхоз җитәкчеләрен билгеләү-эшләреннән алу МТСларның сәяси бүлеге карамагында була. Менә бер документ: «7 февраля 1934 года. Путевка. Тов. Нургалимов Мирзагалим направляется председателем колхоза «Яна Турмуш». Проведите общим собранием, решение собрания сообщите нам. Зам. нач. политотдела Янборисов»[2].

Солтанов вакытында «Байкал» колхозы ныклап аякка баса. Рәис төзү эшләренә зур игътибар бирә. Хәзерге мәктәп котельные янындарак утыз алтынчы елларда мәктәп өчен бина салына. Күбрәк халыктан таланган йорт исәбенә төзелә ул. Сугыш вакытында монда балалар йорты урнаша.

Икмәк саклый торган амбарлар («глубинный пункт» яисә кыскартылып «глубинка» дип аталган), зур ат абзары («конный двор»), пекарня, колхоз идарәсе йорты, колхоз рәисе өчен йорт төзелә. 4 бригада, аларның дүртәр бричкасы була. Ике ат җигелгән бричка унышар центнер йөк тарта алган. Сугыш вакытында атлар фронт ихтыяҗлары өчен алына, бричкалар бетә.

Колхозның сарык, дуңгыз фермалары була. Алар Бикләндедән ерак түгел, хәзерге сыер фермасы урынында була.

Солтанов эшләгән 1937 елны игеннәр аеруча уңа. Бу турыда колхоз рәисе 1938 елның февралендә болай дип язып чыга: «Дәүләт тарафыннан бирелгән барлык йөкләмәләрне тулысынча үтәп, колхозда тиешле фондларны бүлгәннән соң, колхозчыларның эшләгән хезмәт көннәренә карап доход бүлдек. Һәр хезмәт көненә 14,4 килограмм бөртекле иген, 2,5 килограмм бәрәңге, 3 килограмм яшелчә һәм һәр хезмәт көненә 20 тиен акча бүленде. Колхозчы Фәхертдинов 900 хезмәт көне эшләп 810 пот иген, 145 пот бәрәңге һәм 162 пот яшелчә алды, ә колхозчы Авзалов гаиләсе белән 1160 хезмәт көне эшләп 1009 пот иген һәм күп санда бәрәңге, яшелчә доходлары алды. Колхозчылар артык игеннәрен сатып йорт кирәк-яраклары һәм культуралы товарлар алалар»[3].

Әлеге язмадан аңлашылганча, колхоз җирләрендә бәрәңге һәм яшелчә дә үстерелгән. Истәлекләргә караганда, «Байкал»да яшелчә бакчасы хәзерге мәктәп территориясенә якынрак урында, «Яңа тормыш»та Кирәмәт тавы итәгендә урнашкан була. Кирәмәт янындагы бакчага 1936 елда нигез салына, бригадиры Насыйбулла Кәлимуллин була.

[1] «Ударчы» Бакалы район гәзите, 1937 ел, 23 август.

[2] БҖОҮДА, П-638 ф., 2 тасв., 160 сакл. бер., 31 б.

[3] «Ударчы», 1938 ел, 6 февраль

Сүз уңаеннан әйтик, Насыйбулла карт бакча белән 1953 елга чаклы җитәкчелек итә, аннары аны Әхмәтшәриф Күчемов алыштыра, ә 1966 елда бакча эше Хәтиф Латыйп улы Шәфыйковка күчә. Иске Катайдагы бакчаның кирәге калмый, аны шул колхозлар берләштерелгән 1951 елдан соң бетерәләр, ә бакча урынын яшь гаиләләргә йортлар салырга бүлеп бирәләр.

Иген уңган елларны колхозчыларга хезмәт көннәренә («трудодень»га) унбишәр-уналтышар килограмм икмәк языла торган булган. Ел буена хезмәт көннәре (нормасын арттырып үтәгән колхозчы көненә бер ярым яисә аннан артыграк «трудодень» ала торган булган) шактый җыелган, шуңа күрә икмәк тә күп бүленгән. Аны ихаталарга китереп аударганнар, кая куярга белмәгәннәр.

Кызу кыр эшләре чорында колхозчылар арасында социалистик ярыш оештырылган, аның нәтиҗәләре еш кына район газетасы битләрендә яктыртылган. 1938 елның августында басылган бер язмада «Яңа тормыш» колхозчылары турында сүз бара: «Бәдертдинова, Дәүләтбаева Нәкыя һәм Сафуановалар 300 данә көлтә урынына 540 ны бәйләп норманы арттырып үтиләр. Машина белән уруда 4 гектар норма урынына Бәдертдинов һәм Госманов иптәшләр 6 гектар итеп үтиләр. Алар хәзер норманы 200 процентка үтәргә йөкләмә алдылар»[1].

Солтановтан соң (1938 ел башларында эшли әле ул), сугыш башланганчыга чаклы, «Байкал» колхозында Шәмсулла Лотфулла улы Шәрифуллин (ул да Куштирәктән) рәис булып тора. Ул эшләгән чорда коммунистлар фиркасенең башлангыч оешмасы төзелә. Аңа Шәрифуллиннан башка, Җиһанша Рамазанов, Мәҗит Хәсәнов һәм авылның беренче коммунисты Салихҗан Сарьянов керә. Мәҗит Хәсәнов секретарь вазифасын башкара.

Документларга караганда, утызынчы еллар ахырында Яңа Катай авыл советы рәисләре булып Заһит Гарифулла улы Шәрифуллин (1939 елның 24 декабреннән), Муллагаян Нурислам улы Ихсановлар (1940 елның 13 августыннан) эшли[2].

1938 елда Катайда бер уку йорты, ике колхоз клубы була. Уку йорты мөдире булып Заманова Тәзкирә эшли.

1937–1938 уку елында Яңа Катай башлангыч мәктәбе директоры булып Даян Баян улы Мурзин (Балыклыдан) эшли (сугыш елларында батырлыклар күрсәткән, Чехословакия Герое исемен алган шәхес). Мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә.

Даян Мурзиннан соң мәктәп директоры итеп Шәймәт Солтан улы Мулдакаев (истәлекләргә караганда, Сасыкүл авылы кешесе) билгеләнә. Ул 1919 елда туган, Дәүләкән педагогия техникумын тәмамлаган, монда килгәнче Камышлы мәктәбендә директор булып эшләгән. Шәймәт Солтан улы Катайда 1946 елның августына чаклы эшли, аннары Иске Әҗми мәктәбенә күчерелә[3].

[1] «Ударчы», 1938 ел, 14 август.

[2] БҖОУДА, П-638 ф., 2 тасв., 1564 сакл. бер., 55 б., 1595 сакл. бер., 265 б.

[3] БҖОУДА, П-638 ф., 9 тасв., 16 сакл. бер., 40 б.а.– 46 бб.

Ул чорларда мәктәптә чыгарылыш елга 10—12 кеше була. Класслар җитми, ике смена укыйлар. Кичке мәктәп тә ачылгач, уку өч сменага бүленә. Электр әле Катайга килеп җитмәгән, керосин лампалары яктысында укыганнар. Керосины да разнарядка буенча гына тәтегән, аны Бакалыдан барып алганнар.

Ул чорда урта мәктәпләр районга берничә генә була. Катайдан Күчемов Искәндәр белән Садыйков Хәбир, иң беренчеләр буларак, Корычка барып унны бетерәләр (ул чорда унъеллык мәктәпләр районда нибары өчәү, тагын Бакалы белән Мостафада гына була). Хәбир авыл советында секретарь булып эшли, сугышка алынып, 1943 елның февралендә хәбәрсез югала.

Күчемов Нәҗип (1921 елгы) истәлекләренә караганда, утызынчы елларда Заһир Фатыйх улы Күчемов (1893 елгы) та укыткан. Ул Каран мәдрәсәсендә белем алган, күпмедер вакыт Корычта укыткан, ә инде латин алфавиты чыккач Катайга кайткан. Аерым алганда, Нәбиев Мирзаәхмәт шул кешедә укыган.

Сугыш башланырга бер ел кала авыл советы катайлыларны хуҗалыклар кенәгәсенә теркәп чыга. Менә шуннан кайбер мәгълүматлар. «Байкал» колхозында Закиров Газизҗан — колхоз рәисе урынбасары, Кашапов Кәрәм, Фәррахов Сәлах, Хәбиров Кәбир — бригадир, Бәдретдинов Нигъмәт, Заманов Әхнәф — хисапчы, Нәбиев Мирзааәхмәт агротехник вазифаларын башкаралар. Гыйндуллин Нурулла, Дәүләтов Камил, Ихсанов Муллагаян, Хәсәнов Җәмигънур — тракторчы, Сайранов Сәгъди — тимерче, Ихсанов Нурлыгаян, Нургалиев Хәйдәрләр балта остасы булып эшлиләр. «Яңа тормыш»та Сарьянов Салихҗан — колхоз рәисе, Камаев Җамали — завхоз, Камаев Җәмгыйтдин, Харисов Нәҗип — бригадир, Җиһаншин Мәрдәнша — агротехник, Ахунҗанов Миргазиян, Әхмәтнәбиев Әхмәтнәгыйм, Дәүләтов Миркасыйм, Фәтхиев Әфлах — тракторчы, Гатиятов Шәрхам (аның улы Гафур сугыш вакытында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә (бу хакта алдагы бүлектән кара). — *Т.К.*), Гомәров Әхмәтгали, Нургалиев Хаҗгалиләр балта остасы буларак билгеле. Хафизов Гата кибет мөдире булып торган. Заманова Тәзкирә Шәйхезаман кызы китапханәче булып эшли.

Бу елларда авылда 699 хуҗалык исәпләнә. Катайлылар беренче тапкыр телефон аппаратыннан (ул МБ, ягъни «местно-батарейный» дип аталган) файдалана башлыйлар. Ул бөтен авылга бер генә булып, Яруллин Хафиз өендә куелган. 1941 елда телефон авылның икенче ягына да куела.

Коточкыч ялгышлар һәм язмышлар турында мәгълүматлар биргән бу бүлек әзме-күпме яктылык һәм өмет белән тәмамланды. Шулай тиештер дә... Чөнки, нинди генә тоткарлыклар, авырлыклар булмасын, тормыш үзе дә алга бара, бер акыл иясе әйтмешли, Җир барыбер әйләнә! Тик шунысы борчый: кешелек үзенең бихисап хаталарыннан гыйбрәт ала һәм тәүбә итә белерме? Халыкның төп бәхете уйлап табылган телефоннарда, телевизорларда, галәм корабларында түгел, беренче чиратта, бәлки, табигый сафлыкта, үзара ихтирам итешүдә, Кеше Җанының кадерен белүдә!

# Без сугышта арысландай көчлебез…

Сугыш башлану авылны хафага сала, тормышның табигый агымын үзгәртә. Моңарчы тыныч хезмәт белән көн күргән халыкның асыл ир-егетләре, корал тотып, Ватан бәйсезлеге өчен көрәшкә күтәрелә.

Икенче бөтендөнья сугышына Катайдан, рәсми булмаган мәгълүматларга караганда, 600 гә якын кеше алына.

«1923 елгылар – 37 кеше, бер көнне сугышка китттек. Үземне дә исәпләп, бары җиде кеше – Гомәров Хәмидулла, Бәдретдинов Тәкыйулла, Гарифуллин Рәхмәтулла, Гаязов Тимергаян, Дәүләтов Тимерҗан, Шагалиев Миргазыяннар исән кайттык»,– дип искә ала торган иде сугыш ветераны Кыям Кадыйр улы Ситдыйков.

Шул ук рәсми булмаган, авыл тарихына багышланган альбомда теркәлгән мәгълүматлар күрсәтүенчә, 338 авылдашыбыз сугыш яланнарында башын салган. Шуларның 169 ы турында хәбәрсез югалды дигән язу килгән. Нибары 261 кешегә исән кайту насыйп булган. Мәңгелек дан сезгә, авылдашлар!

Ни кызганыч, яугирларның исемлекләре сакланмаган, шуңа төрле чыганакларга таянып исемнәрен тулысынча диярлек үземә ачыкларга туры килде. Бөртекләп диярлек җыйган тулы булмаган мәгълүматлар буенча, яу кырларына 655 тән артык авылдашым киткән, шуларның 270 е (шулар арасында минем әтиемнең абыйсы Ярмөхәммәт Кәримов хатыны Нәкыя белән төшкән фоторәсемен текстта күрәсез) рәсми рәвештә һәлак булган яисә хәбәрсез югалды дип теркәлгән, 120 сенең язмышы билгесез (сугыштан кайтканмы, ятып калганмы – боларны белеп булмый, чөнки авылда туганнары-якыннары калмаган диярлек), 265 е исән кайткан.

Ватаныбыз азатлыгы өчен көрәштә батырлыклар күрсәтеп, дәүләт бүләкләренә лаек булып сугышта башын салган авылдашларыбызның исемнәрен атап үтик. Болар:

1. Вәлиев Хәниф Вәли улы, 1904–1943 (хәбәрсез югалган). Өлкән сержант. «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (27.08.1943);



**Ярмөхәммәт Кәримов хатыны Нәкыя белән**

2. Гарифуллин Әхмәткарам, 1918 (Яңа Катай) – 1944 (хәбәрсез югалган). Кече лейтенант. «Кызыл Йолдыз» ордены (17.01.1943);

3. Күчемов Әбүзәр Кәнҗел улы, 1918–05.02.43. Лейтенант, взвод командиры. «Батырлык өчен» медале (17.03.1942);

4. Нәбиев Гыйлембаян Әхмәтлатыйф улы, 1896 (Иске Катай) – 25.04.1945. «Батырлык өчен» медале (15.05.1945);

5. Сарьянов Салихҗан Сарьян улы (1902 (Иске Катай) – февраль, 1945 (хәбәрсез югалган). «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (02.10.1943);

6. Сираев Әмир Сәлах улы, 1924 (Иске Катай) – 09.1943 (хәбәрсез югалган). Сержант. «Дан ордены» (3 нче дәрәҗә) (03.03.1944);

7. Ситдыйков Мәрхәм Вәлиәхмәт улы, 1921 (Яңа Катай) – 1945 (хәбәрсез югалган). Ефрейтор. «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (29.08.1945);

8. Харисов Әнвәр Харис улы, 1918 (Иске Катай) – 22.08.1943. Лейтенант, взвод командиры. «Ватан сугышы» (1 нче дәрәҗә) ордены (30.09.1943);

9. Шаригин Гыйният Ибраһим улы, 1905 (Иске Катай) – 18.07.1944. Кече сержант. «Сугышчан хезмәтләре өчен» медале (15.06.1944);

10. Шәрхемуллин Гафурҗан Шәрхемулла улы, 1924 (Яңа Катай) – ноябрь, 1944 (хәбәрсез югалган). Өлкән сержант. «Сугышчан Кызыл Байрак» ордены (30.08.1944).

Боларның һәрберсенең батырлыкларын тасвирлап үтү бурычын куймыйбыз, теләгән кеше интернеттан «Халык хәтере» («Память народа») сайтыннан карый ала. Әмма Шәрхемуллин Гафурҗан Шәрхемулла улының тиңдәшсез кыюлыгына аерым тукталып үтмичә мөмкин түгел. Көнбатыш Двина елгасын кичкәндә күрсәткән батырлыклары өчен ул хезмәт иткән 201 нче полк командиры Георгий Александр улы Иноземцев (исеме «Википедия»дә бар) 1944 елның 8 июлендә аны Советлар Союзы Герое исеме белән бүләкләргә тәкъдим итә, әмма югарыдагылар «Сугышчан Кызыл Байрак» ордены бирү белән чикләнәләр. 22 июльдә Советлар Союзы Герое исеме белән Иноземцев үзе бүләкләнә, анкетасында татар дип язылган авылдашым шул бүләккә аннан лаеклырак булып та, исемлектән сызып атыла. Полк командиры Иноземцев Гафурҗан Шәрхемуллинның батырлыгына сокланып, бүләкләү документында түбәндәгеләрне яза:

«22.6.44 года в боевой операции при прорыве обороны пр-ка (противника.– *Т.К.*) в районе Радьково-Орехи показал образцы отваги и геройства. Под ураганным огнем пр-ка, рискуя жизнью, в стремительной атаке первым со своим отделением ворвался в оборону пр-ка, где в рукопашной схватке лично уничтожил пулеметный расчет пр-ка. Под мощным ударом наших подразделений враг дрогнул и в беспорядке отступал.

В ходе наступательного продвижения части вперед, входя в состав ударной группы по форсированию реки Западная Двина, 24.6.44 года в числе первых под сильным пулеметным и минометно-артиллерийским огнем пр-ка с оружием вплавь переправился на левый берег реки и сходу вступил в бои по расши-



КРАТКОЕ, КОНКРЕТНОЕ ИЗЛОЖЕНИЕ ЛИЧНОГО БОЕВОГО ПОДВИГА ИЛИ ЗАСЛУГ:

22.6.44 года в боевой операции при прорыве обороны пр-ка в районе Радьково Срежи показал образцы отваги и героизма. Под ураганным огнем пр-ка, рискуя жизнью, в стремительной атаке первым со своим отделением ворвался в оборону пр-ка, где в рукопашной схватке лично уничтожил пулеметный расчет пр-ка. Под мощным ударом наших подразделений враг дрогнул и в беспорядке отступал.

В ходе наступательного продвижения части вперед, входя в состав ударной группы по форсированию реки Западная Двина, 24.6.44 года в числе первых под сильным пулеметным и минометно-артиллерийским огнем пр-ка с оружием вплавь переправился на левый берег реки и сходу вступил в бой по расширению плацдарма на левом берегу. В бою за населенный пункт ГОЛЫЙ первым ворвался в населенный пункт и захватил в плен 2 немцев. Выбитый из траншей пр-к бежал, оставляя на поле боя трупы.

Охваченный наступательным порывом герой ШАРХАМУЛЛИН со своим отделением преследуя пр-ка автоматным огнем уничтожал его живую силу.

За подлинный героизм проявленный при прорыве обороны пр-ка и за смелое форсирование реки Западная Двина тов.ШАРХАМУЛЛИН достоин присвоения звания "ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА".

КОМАНДИР 201 ГВАРДЕЙСКОГО
СТРЕЛКОВОГО ПОЛКА
ГВАРДИИ ПОДПОЛКОВНИК /ИНОЗЕМЦЕВ/

"7" июля 1944 года.

**Документ күчермәсе**

рению плацдарма на левом берегу. В бою за населенный пункт Голый первым ворвался в населенный пункт и захватил в плен 2 немцев. Выбитый из траншеи прк бежал, оставляя на поле боя трупы.

Охваченный наступательным порывом герой ШАРХАМУЛЛИН со своим отделением преследуя пр-ка автоматным огнем уничтожал его живую силу.

За подлинный героизм проявленный при прорыве обороны пр-ка и за смелое форсирование реки Западная Двина тов. ШАРХАМУЛЛИН достоин присвоения звания «ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА»

Командир 201 гвардейского
стрелкового полка
гвардии подполковник [......] /Иноземцев/
7 июля 1944 года.»

Гафурҗан Шәрхемуллинны бүләкләү документындагы башка мәгълүматларга тукталып үтик. Бакалы район хәрби комиссариатыннан аны хәрби хезмәткә 1943 елның 31 маенда чакыралар, июль аенда беренче тапкыр сугышка керә, 7 октябрьдә яралана. 1944 елның июнь-июль сугышларында сержант, отделение командиры буларак катнаша, аңарчы сугышчан бүләкләре булмый. Әллә моңарчы сугышчан бүләкләре булмагангамы, әллә татарлыгы «мишәйт» иткәнме шунда, 20 яшьлек Гафурҗан Советлар Союзы Герое исемен алу урынына, «Сугышчан Кызыл Байрак» ордены белән канәгатьләнергә мәҗбүр була. Орденын тагып туган ягына исән кайтса, иң зур бәхет-шат-



| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шарихмуллин Гафур Шарихмуллинович | Стар. сержант | Стрелк. | б/п | 1924 | „ — „ | Бакалин. окм. РВК 1943 г. | Мож. счит. проп. без вести 25.08.1944 | | Отец [illegible] | „ — „ | 1944.25.VIII пр. связь адреса нет | Пропал б/в XI-44 |

**Документ күчермәсе**

лык шул буласы иде дә бит, тик шул елның аяусыз сугышларының берсендә ул һәлак була. Шунысы гаҗәп, аның нинди шартларда, кайсы көнне һәлак булуын беркайда теркәмәгәннәр, шунлыктан ул хәбәрсез югалган санала. Ә аның командиры Иноземцев 1945 елда полковник дәрәҗәсендә хәрби хезмәттән китә, тарих буенча кандидатлык диссертациясен яклый, китаплар яза, Ростов дәүләт университетында тарих-филология факультеты деканы вазифасын башкара, 1957 елның 16 февралендә мәрхүм була. Орденлы сугышчының, полкташлары арасында шәхси батырлыгы белән аерылып торган командирның кайчан һәм нинди шартларда һәлак булуы теркәлмәгәнгә кем гаепле? Взвод һәм батальон командирлары белән беррәттән полк командиры Иноземцев та түгелме?

Шәрхемуллинның батырлыгы турындагы мәгълүматларга мин очраклы рәвештә әле күптән түгел генә юлыктым. «Мемориал» сайтында Бакалы район хәрби комиссариаты донесениеләрен карап утырганда хәбәрсез югалган авылдашларымның зур исемлеге килеп чыкты. 1947 ел башындарак хәрби комиссариат вәкиле авылларда булып сугышта хәбәрсез югалганнарны ачыклаган, бу хакта аларның ата-аналарыннан, туганнарыннан яисә хатыннарыннан мәгълүматлар язып алган булган икән. Шәрхемуллин турында түбәндәгечә теркәгән: «Шарихмуллин Гафур Шарихмуллинович. Стар. сержант. Стрелк. Б/п. Бакалинским РВК 1943 г. Мож. считать пропавшим без вести 25.08.1944. Отец Гатиятуллин Шархемулла. 1944.25.VIII пр. связь. Адреса нет. Пропал б/в XI-44». Атасы Шәрхемулла әйткән мәгълүматларга таянып, аның улы Гафур 1944 елның ноябрендә хәбәрсез югалган дигән нәтиҗәгә килгән комиссариат вәкиле.

Шәрхемуллинның сугышчан язмышын-бүләкләрен беләсе килеп «Халык хәтере» («Память народа») сайтын ачып карадым һәм исеме, туган елы, Бакалыдан хәрби хезмәткә алынуы буенча, фамилиясенең дөрес язылышын, орден белән бүләкләнүен ачыкладым. Башка чыганактан аның мулла кушкан исеме Гафурҗан булуын белдем.

Катайның сугыш чорына караган хуҗалыклар кенәгәсендә батыр туыпүскән гаилә турында түбәндәге мәгълүматлар бирелә: Гатиятов Шәрхем (1891 елгы, балта остасы), хатыны Кәшифә (1892 елгы), уллары Хәтмулла (1923 елгы, 7 марттан РККА га алынган), Гафур (1925 елгы, Иске Корычта 8 нче классны бетергән), Фәварис (1936) һәм кызы Сәрмәдия (1931). Әлеге кенәгәдә гаилә башлыгының исем-фамилиясе кыскартылып язылган (Гатиятуллин Шәрхемулла дип язасы урынга), ә Гафур (Гафурҗан) 1925 елда туган дип күрсәтелә. Элек-электән килгән традицияне дәвам итеп, Гафур (Гафурҗан) әтисе исемен фамилия итеп яздырган.

Шәрхемуллинга һәм йөзләрчә авылдашларыбызга исән кайтырга насыйп булмый. Туган якларына җиңүчеләр булып исән-имин кайтучылар арасында да Гафурҗан кебек батырларча сугышкан, орден-медальләр белән бүләкләнгән авылдашларыбыз шактый. Болар: Әхмәтов Кәбир, Әхмәтов Кәшбелгаян, Галләмов Афзал, Гарданов Хуҗәхмәт, Вахитов Зәкуан, Имамов (Фәрвазов) Хәләф, Хафизов Гата, Шәкүров Хәбиб, Шәмсетдинов Галимҗан, Шәяхмәтов Шәйхезаман һәм башкалар.

Катай ир-егетләре хезмәттә сынатмаган кебек, илбасарларга каршы сугышта да сер бирмиләр. Шуларның берсе – күп орден-медальләр белән бүләкләнгән Имамов Хәләф Имам улы легендар шәхес булып таныла.

Сугышка кадәр Хәләф танылган спортчы була. Йөгерү һәм велосипедта йөрү буенча республика ярышларында катнашып, чемпион исемен яулаган. Кайда гына ярышмасын, беренчелекне бирмәгән. Авылдашыбыз, Хәләфнең хезмәттәше Әюпов Мулламөхәммәт сөйләвенә караганда, бервакыт спортчы, бәхәсләшеп, ат белән ярыша. Бөтен кешене таң калдырып, тәки аттан алда килә бит бу. Солдат хезмәтеннән икенче эпизод та кызыклы. Бервакыт солдатлар тар гына елгадан басма аша чыкканда, үгез җигелгән, йөк төялгән арбаның батканын күрәләр. Арба янында карт белән карчык. Хәләф суга сикереп төшә дә, картка үгезне җитәкләргә куша, ә үзе йөкле арбаны елга ярына чыгарып куя.

Сугыш елларында Фәррахов Гариф Хәләф белән бергә була. Аның сөйләве буенча, алар разведчик булганнар. Хәләф дошман ягына китсә, иптәшләре: «Хәләф бүген разведкада, менә күрерсез, сыңарлап түгел, көянтәләп кайтыр», дигәннәр, чөнки ул бер урынына икешәр «тел» кулга төшергән. Исеме күп кенә газеталарда мактап язылган, хәтта ул газеталарның кайберләре авылыбызга кадәр кайтып, монда да аның батырлыклары турында укыганнар. Немецлар да бу газеталарны кулга төшереп, үзләрен әледән-әле югалтуларга дучар итүче солдатның исемен белгәннәр. Шуңа күрә микрофон аша Хәләф абыйга мөрәҗәгать итеп: «Халлэй, Һаллэй» дип кычкыра торган булганнар, беләбез, янәсе, сине.

Батыр сугышчы Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, әмма ниндидер кечкенә хата ясап, бу исемнән колак кага. Сугыштан соң Хәләф абый хатыны Бану апа һәм кызлары белән авылда яши, башлангыч партия оешмасы секретаре һәм бригадир булып эшли. Әмма авыруы (диабет) көчәеп, дөньядан бик яшьли китеп бара.

Хәләф авылдашыбыз турында югарыдагы юлларны язып, дистәдән артык еллар үткәч, 2013 елда интернетның «Халык батырлыгы» сайтын ачып карарга булдым. Максатым – батыр авылдашыбызның дәүләт бүләкләре турында мәгълүмат алу иде. Ни өчен, кайчан бүләкләнгән, хәрби званиесы нинди булган – бу сорауларга документаль чыганаклар таптым әлеге сайттан. Түбәндә батыр сугышчының хәрби биографиясенә һәм бүләкләренә тукталып үтәм.



Хәләф Имамов армия сафларына 1939 елда алына. Хәрби хезмәттә вакытта сугыш башлана һәм ул Көнбатыш фронт гаскәрләре сафында илбасарларга каршы көрәштә 1942 елның маенда беренче чыныгу ала. Шул чордан Хәләф разведчик буларак сугыша, дошман ягына чыгып «тел» алып кайту буенча хәрби бурычларны уңышлы үти. Бу хакта аның күпсанлы хәрби бүләкләре сөйли.

1943 елның 29 нчы гыйнварында разведчиклар отрядына Сафроново авылының төньягында бер исемсез калкулыкта урнашкан дошман ягыннан «тел» алып кайту бурычын куялар. Дошман уяу, шуңа күрә разведчиклар танклар ышыгында барып, ут ача-ача немесләрнең ныгытмаларына бәреп керәләр. Хәләф дошман траншеясына сикереп төшү белән иң беренче элемтә чыбыгын өзә, аннан траншея буйлап барып юлда очраган дошманнарына граната ыргыта, өчесен дөмектерә, берсен «тел» итеп, документлар һәм немес автоматын да кулга төшереп, частена алып кайта. Әлеге батырлыгы өчен сержант Имамовны, Көнбатыш фронтының 50 нче армия гаскәрләренең 1943 елның 11 февраль приказы нигезендә, «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләклиләр. Шундый ук бүләккә тагын ике разведка взводы командиры да лаек була.

Батыр сугышчының икенче бүләге – «Батырлык өчен» медале (1943 ел, 17 сентябрь). Бу юлы ул өлкән сержант, коммунистлар фиркасенә кандидат, взвод командиры ярдәмчесе буларак Морозовка авылы янындагы сугышларда үзен кыю командир итеп күрсәтә. Аның командалыгындагы разведчиклар группасы җитез хәрәкәт итеп, ут ачып, гранаталар ыргытып дошман траншеяларын яулап ала һәм разведчикларның башка группаларына дошман тылына үтәргә, аның ут нокталарын, көчен ачыкларга мөмкинчелек тудыра.

Аннары аның командалыгындагы разведчиклар 3 нче Белоруссия фронтының 33 нче армиясенә кергән 344 нче дивизиясе составында беренчеләрдән булып Днепр һәм Неман елгаларын кичәләр, дивизиянең алга таба һөҗүмен тәэмин итәләр. Июльнең 20 сеннән 21 енә каршы төндә хәрби бурычын үтәгәндә батыр разведчик шәхсән үзе дошманның 15 солдатын дөмектерә, аннары сугышчан иптәшләре белән немесләрнең 3 җиңел пушкасын, рациясен трофей, ике солдатын «тел» итеп алып кайта. Әлеге батырлыгы өчен аны «II нче дәрәҗә Ватан сугышы» ордены белән бүләклиләр, аннары бераздан коммунистлар фиркасенә әгъза итеп алалар, взвод белән командалык итүне ышанып тапшыралар.

Геройның соңгы бүләге – «Кызыл байрак» ордены. Әлеге бүләккә приказ 1945 елның 5 гыйнварында була. Бу вакытта өлкән сержант Хәләф Имамов аерым разведка ротасында взвод командиры вазифасын башкара. Рота турыдан-туры 1 нче Балтыйк фронты составындагы 43 нче армиянең 344 нче


ст. сержант Имамов на фронтах отечественной войны с 1941 года с первых дней и все время участвовал в боях с немецкими захватчиками.
Находясь в Развед роте с 1942 года много раз участвовал в ночных поисках за „Языком" и имел в них успех. За проявленные мужество и отвагу командование высоко оценило действия т. Имамова и наградило его медалью „За Отвагу" и орденом „Красная Звезда".
т. Имамов участвовал первым в форсировании рек Днепра и Немана чем обеспечивал продвижение вперед подразделений дивизии.
В ночь с 20 на 21 Июля 1944 г при выполнении боевой задачи т. Имамов лично уничтожил до 15 немецких солдат и отбил с товарищами три легких пушки, рацию и захватил 2х пленных.
За проявленные смелость и отвагу т. Имамов достоен правительственной награды орден „Отечественной войны II ст"
„21" Июля 1944 г Командир 412 ОРР
ст. л-т Харченко.

**Сугышчының батырлыгы турында сөйләүче документ күчермәсе**

укчы дивизиясе командирына буйсына. Һәрвакыттагыча диярлек, бу юлы да «тел» алып кайту бурычы куела. Гыйнварның 3 сеннән 4 сенә каршы төндә аның группасы мина кырларын һәм тимер чытырларны узып, сиздермичә дошман блиндажына якынлаша һәм ике сакчыга ташлана. Бер гитлерчыны Хәләф үзенең хәнҗәре белән дөмектерә, икенчесен «тел», пулеметын трофей итеп алалар. Аннары Хәләф гранатасы белән дошман блиндажын шартлатып, анда булган 8–10 солдатны юк итә.

...2017 елның февралендә Хәләф абыйның исемен беренче тапкыр авыл тарихында зурлап язган Әлфия апа Хәйдәрова белән очрашып сөйләшергә насыйп булды. Аның турында сүз чыккач, Әлфия апа Хәләф Имамовка Советлар Союзы Герое исеме бирмәүнең төп сәбәбенә ачыклык кертте. Бу хакта батыр авылдашыбыз үзе сөйли торган булган икән. Сугышлар Венгриядә барганда, дошманнан азат ителгән территориядә җирле халык белән конфликт килеп чыга. Сан ягыннан өстенлекле венгрлар бер урында ял итеп яткан совет солдатлары төркемен дөмбәсләмәкче булганнар, шул чакта Хәләф килеп чыгып, чит ил вәкилләрен төрле якка очырган, ди. Венгрлар үч алу уе белән Хәләф өстеннән шикаять язып, аны гаепле итеп калдырганнар, исемен каралтканнар (венгрларның совет солдатларына карата явызлыклары турындагы тарихларны



ВСЕ ГРАФЫ ЗАПОЛНЯТЬ ПОЛНОСТЬЮ

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество Имамов Халяв
2. Звание стар. сержант 3. Должность, часть Вр. и. о. командира взв. 412 Отд. Развед. Роты, 344 стр. Рослав. Краснознаменной дивизии, 43 Армии, 1го Прибал. фронта

Представляется к награждению орденом „Красное Знамя"

4. Год рождения 1916. 5. Национальность татарин 6. Партийность чл. В.К.П (б)
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) 1941, 1942, 1943 г. Западн. фронт, 1944 Белорусс. фр. с сент 1944 1го Приб. фронт
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне Ранен 3 раза 11.04.42, 10.10.43, 19.12.43
9. С какого времени в Красной Армии с Августа м-ца 1939 г 10. Каким РВК призван Бокаминским Р.В.К. Башкир. А.С.С.Р.
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) медаль „За отвагу" прик. №016/н. 17.09.43. по 344 сд. орден „Красная звезда" прик №043 11.02.43 по 344 сд. орден Отечественной войны II ст. пр. №033 от 20.02.44 по 62 ск.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.

ст. серж. Имамов находясь в рядах Красной Армии с 1939 года на фронтах отечественной войны с 1941 года участвовал в боях против немецких захватчиков.
Находясь в 412 Отд. Разв. Роте разведчиком с 1942 года неоднократно принимал участие в поисках за „Языком" где проявил мужество, смелость и отвагу за что был награжден правительственными наградами а также значком „Отличный Разведчик".
т. Имамов как опытный разведчик, командует взводом и пользуется среди разведчиков авторитетом, в боевых действиях своим личным примером воодушевлял разведчиков на боевой подвиг.
Подготовив и хорошо натренировав группу разведчиков ст. с-т Имамов в ночь с 3 на 4е Января 1945 года отправился с ними на поиск за „Языком" идя во главе штурмовой группы. Проделав проволочное заграждение и минное поле он с группой подошел к заранее намеченному объекту (блиндаж). Вся группа во главе с Имамовым набросилась на двух идущих на смену постов немецких солдат. т. Имамов лично ножем уничтожил одного фрица, а его группа захватила другого в плен с пулеметом. Противотанковой гранатой т. Имамов взорвал блиндаж уничтожив при этом от 8 до 10 немцев бывших в блиндаже.
Вся группа разведчиков возвратилась без потерь с пленным немцем и пулеметом в свое расположение.
За проявленные смелость и отвагу т. Имамов достоин правительственной награды ордена „Красное Знамя"

4. Января 1945 г.

Командир (начальник) (звание)

Хәләф Имамовның соңгы бүләге — «Кызыл байрак» ордены

интернеттан да укырга була, шуңа күрә Хәләф абый арттырмыйча сөйләгән дип әйтергә нигез бар).

Ир-атлар сугышта чакта, төп авырлык хатын-кыз җилкәсендә була. Ашарга да, өскә-башка кияргә дә юк диярлек. Шундый шартларда иген игәргә, терлек карарга кирәк. Районнан әледән-әле килеп торган заданиеләрне үтәми хәлең

юк. Кул көче белән генә бихисап эшләрне башкарып булмый, ә тракторлар тик тора — ирләр юк...

Аптырагач, хатын-кызлар корыч атларны иярләргә булалар. Тракторлар артына Галиева Нәфисә (1913 елгы), Шәфикова Тәкмилә (1925), Әюпова Мөхәссәнә (1928) һәм Җәләева Дәнәләр (1928) утыра. Бу хатын-кызларның һәрберсе турында күп сөйләргә булыр иде, ләкин берничә сүз әйтеп китү белән генә чикләнергә туры килә.

Нәфисә апа тракторчылар арасында өлкәне була. Ул яшьли ятим калып, зур авырлыклар күреп үскән. Тракторист эше җиңел түгел, әмма Нәфисә апа күп уйлап тормый, курсларда укып кайтып, эшли дә башлый. Сугыштан соң да әле аңа трактор артына күп утырырга туры килә, барлык стажы унике еллап була, шуның 9 елы — Корыч, 3 елы Бөҗыр МТС ларына туры килә.

Тәкмилә апа да тракторда унике ел эшли. Сугыш башланганда яңа гына җиде классны тәмамлаган була ул. Чоры өчен зур белем алган уналты яшьлек кызның башка уй-хыяллары булгандыр, әмма ләкин сугыш барысына киртә куя. 1941 елдан ул тракторда эшли башлый.

Мөхәссәнә һәм Дәнә апалар яшьтәшләр, икесе дә 12—13 яшьтән колхоз эшенә йөри башлыйлар. Сугыш башлангач трактористлар курсын бетереп бер тракторда эшлиләр. Җир сөрү, тырмалау, культивацияләү, уңыш җыйган чорда комбайнны тарттырып йөрү — яшь кызларның җилкәсенә төшкән эшләрнең кайберләре генә.

Сугышның әйтеп бетергесез михнәтен, авыр йөген авылда калган барлык халык, шул исәптән җитмешен тутырган әби-бабайлар да татый. Район газетасында 1943 елның 8 август санында басылган «Эшлекле Габидә әби» исемле кечкенә язма моны беркадәр чагылдыра кебек: «Яңа тормыш» колхозының 73 яшьлек члены Галиева Габидә әби — колхоздагы патриотларның берсе. Ул урып-җыюның беренче көненнән башлап эшкә чыкты һәм дәвамлы рәвештә эш нормасын арттырып үти. Габидә әби һәр көнне 0,20 гектар норма урынына 0,25 гектар мәйданның игенен ура»[1].

Әлбәттә, яшь хатын-кызларның көнлек эш нәтиҗәсе зуррак була. «Байкал» колхозчылары «Мөхәммәтдинова Хөсни, Зарипова Әфүдә, Әхмәтова Мәрьямнәр уракның беренче көнендә (20 июль) 0,40 гектар урдылар» дип әйтелә икенче бер язмада[2].

«Байкал» колхозында 1944 елда барлык эшчеләрнең нибары 51 е генә ир-ат була. Төп авырлык 225 хатын-кыз һәм 91 яшүсмер өстенә төшә. «Яңа тормыш»та да шундый ук хәл: 52 ир-ат, 272 хатын-кыз һәм 96 яшүсмер[3].

Хатын-кызлар авылдан читтәге эшләргә дә җәлеп ителәләр. 1943 елның декабрендә Баһманшина Мәүдидә, Баянова Дөринур, Гайсина Җәүһәр, Ситдыйкова Саяда, Фәрвазова Җәмилә, Харисова Ридәнә, Хәбибрахманова Мәгъ-

[1] «Ударчы», 1943 ел, 8 август.

[2] «Ударчы», 1943 ел, 25 июль.

[3] БҖОҮДА, 2434 ф., 1 тасв., 3 сакл. бер., 23 б.

мүрәләрне (Катайдан – егерме, районнан йөз егермеләп кыз) Ленинградтан ерак түгел «Назия» торф чыгару предприятиясенә эшкә алып китәләр. «Өстән немец самолетлары бомба ташлап китәләр иде, өчәр-дүртәр көн сусыз, ризыксыз калган чаклар булды. Псков янында сугышлар бара иде», дип искә алды ул көннәрне Саяда Гыйлембаян кызы Ситдыйкова (1925 елгы). Катай кызларының барысына да исән-имин кайту насыйп була.

1944 елда Иске Катайда – 219, Яңа Катайда 287 хуҗалык исәпләнә. Авыр елларда да авыл үсеше тукталмый, халык көнкүрешне яхшыртырга омтылып яши. 1944 елда Иске Катайда – 6, Яңа Катайда 8 хуҗалык яңа өй салып керәләр. Авыл советы исемлеге буенча, сыерсыз 36 колхозчы сыер асрый башлый.

«Байкал» колхозының сөрүлек җирләре 2341 га (1944 елда шуның 1379 гектары – чәчүлекләр), «Яңа тормыш»ныкы 2603 га (1711 га) тәшкил итә. «Байкал» колхозы 1943 елда – 4054 ц, «Яңа тормыш» 5709 ц икмәк тапшыра. 1944 елда табигать шартлары һәм башка сәбәпләр аркасында план үтәлми: «Байкал» – 3184, «Яңа тормыш» нибары 2114 ц икмәк тапшыра. Зур күләмдә планга тапшыргач, колхозларда уңышның бик аз өлеше генә кала. «Байкал» 1944 елда симәнәгә – 730 ц, колхозчыларга хезмәт көннәренә түләргә 330 ц калдыра алган. «Яңа тормыш» 1944 елда симәнәгә – 833 ц, колхозчыларга хезмәт көннәренә түләргә нибары 257 ц калдыра алган.

1944 елда игеннәрнең уңышы түбәнәю терлекчелек тармагына зур зыян китерә. Бу хакта түбәндәге саннар сөйли.

1944 ел башында «Байкал» колхозында 130 баш ат, 81 баш мөгезле эре терлек, 281 баш сарык, 24 баш дуңгыз була. 1945 ел башына бу күрсәткечләр шактый кими: атлар – 94, мөгезле эре терлекләр – 48, сарыклар – 126, дуңгызлар 3 баш кала.

«Яңа тормыш»та да терлекчелек тармагы үсми, киресенчә, шактый кими. 1944 ел башында 190 баш ат, 122 баш мөгезле эре терлек, 305 баш сарык, 25 баш дуңгыз була. 1945 ел башына бу күрсәткечләр түбәндәгечә: атлар – 150, мөгезле эре терлекләр – 64, сарыклар – 178, дуңгызлар 8 баш кала.

Ике колхозга барлыгы 36 ат үлә, 44 башы суела, 20 мөгезле эре терлек үлә, 29 башы суела, 154 сарык үлә, 69 башы суела, 25 баш дуңгыз үлә[1].

Сугыш елларында «Байкал» колхозы рәисләре булып Кәнҗел Харисов, Сәлах Фәррахов (1942 елның июнь-сентябрь айлары), Сәмигулла Хафизов (1942 елның 23 декабреннән 1943 елның октябренә кадәр), Иван Федор улы Егоров (1943 елның октябреннән) һәм Шәйхетдин Хаков (ул Дүртөйле районы Ляшты авылыннан) эшли.

«Яңа тормыш»ка исә сугыш башланганда Сарьянов Салихҗан җитәкчелек итә, калган чорда бер-бер артлы Нигъмәтуллин Хәбибулла (6 ай), Гобәйдуллина Вәҗиха Вилдан кызы (1942 елның маеннан), Харисов Нәҗипләр эшләп ала. Ул чорның кырыс законнары рәис өстенә бик зур таләпләр куйган. Бик

[1] БҖОҮДА, 2434 ф., 1 тасв., 3 сакл. бер., 22 б.а., 23 б.

азлар гына шуларга ярашлы эшли алган, шуңа күрә дә әледән-әле җитәкче алышынып тору – гадәти күренеш.

Авыл советы рәисләре дә алышынып тора. 1941 ел башында – Шәрифуллин Заһит, сугыш башланганда Катайда авыл советы рәисе булып Ихсанов Муллагаян эшли. Сентябрь аенда аны армия сафларына чакыралар, 4 октябрьдә авыл советы карары белән рәис итеп Мофаздалова Галимәне, аның урынбасары итеп Фазлыев Габдулланы куялар. Мофаздалова Галимә әлеге вазифаны 1944 елның 4 мартына чаклы башкара, райком күрсәтмәсе нигезендә аның урынына Зариповны сайлыйлар. Зарипов әлеге вазифаны 1945 елның 8 апреленә чаклы башкара, аннары ул вазифа Галиуллинга күчә.

Җитәкче булып эшләү хәтәр булган, кайбер рәисләрне аз гына гаепләре өчен дә хөкем итеп, төрмәләргә утыртканнар яисә атканнар. «Байкал» колхозыннан иң беренче хөкем Сәлах Фәрраховка чыгарыла. «Уңыш җыйнау эшенә җавапсыз карап, аны үзү һәм иген уңышын югалту хәленә китереп җиткергән» дип, Бакалы халык суды 1942 елның 3 сентябрендә аңа 5 елга ирегеннән мәхрүм итү җәзасын бирә[1].

Аның икенче елында «глубинка»дагы икмәкне халыкка өләшкән дип Сәмигулла Хафизовны атарга хөкем итәләр. Гаепнең бер өлешен район җитәкчеләреннән дә күрәләр, район башкарма комитеты рәисе Гаделшинга да шундый ук җәза бирелә.

Сәмигулла Хафизов – өлкән буын кешеләр күңелендә якты эз калдырган шәхес. Аның турында җылы истәлекләре белән Әлфия Мирзаәхмәт кызы Хәйдәрова уртаклашты: «Өлкән яшьтә һәм саулыгы сәбәпле Сәмигулла абый сугышка алынмады. Чал чәчле, һәркем белән ягымлы мөгамәләдә була белгән бу җитәкче миңа гомерем буе кешеләр белән эшләү үрнәге булып торды. Бу елларда, аеруча кичке якта, почтальон үткәннән соң, кайгы хәбәре килгән йортлардан еш кына балалар елавы, аналар сулкылдавы ишетелә иде. Бу йорт янына күршеләр, туганнар, балалар җыелыр идек. Шушы хәбәрне ишетеп идарә әгъзаларын ияртеп председатель Сәмигулла абзый килер иде. Иң элек ятим калган балаларны алдына алыр иде. «Сабыр булыгыз, бәлки, хәбәр дөрес түгелдер»,– дип юатыр иде. Чыгар алдыннан: «Килен, иртәгә конторага кил әле, уйлашырбыз, бура төбен кырып булса да табарга тырышырбыз»,– дип хушлашыр һәм сүзендә торыр иде. Солдат кайтса да, китсә дә йортларга кереп хәл белешер иде, ярдәм итәр, эшләрлекне эшкә чакырыр иде. Эшчеләр янына килсә, алар салам өйсә, сәнәк алып салам өяр, хәл белешер, бурычлар билгеләр иде. Үзе ялны белмичә эшли, хезмәт кешесе белән җиңел генә уртак тел табар иде. «Сәмигулла абзыйның, эшли торгач, күлмәкләре сыгып ташларлык»,– диләр иде әниләр. Ул кычкырмый, янамый, кемгә нәрсә кирәген алдан белеп торыр иде. Шушы изге күңелле, кешелекле җитәкчене милицияләр килеп алып киткәнен ишеткәч, күп йөрәкләр сыкранды. Аеруча авыр семьяларга аз гына иген өләшү өчен, задание тулгач, азрак алып калган, өләшә дә башлаган. Бу

[1] «Ударчы», 1942 ел, 16 сентябрь.

турыда кара эчле кешеләр районга эләкләгән. «Халык өчен харап булды»,– диделәр күпләр. Аның ике кызы – Хәдичә һәм Гайшә апалар – калды, кияүләре бик яхшы кешеләр булдылар. Сәмигулла абзыйның якты образы оныкларында яши, алар да бик ягымлы, кешелеклеләр».

«Ләкин кешеләр төрле иде,– дип дәвам итте сүзен Әлфия Мирзаәхмәт кызы, гыйбрәтле хәлләргә тукталып.– Кайберәүләр күрсә дә, күргәнен белдертмичә кешеләрне исән алып калырга тырышты, ә кайберәүләр юкны бар итеп утка салды. Мәсәлән, бригадир Шагалиев Миргазыян, бер тәлинкә куырган арыш белән тотып, милициягә алып килеп, ире сугышта үлгән, балигъ булмаган биш бала анасы Харисова Сайма апаны 8 елга төрмәгә җибәрттерде. Тәминдарова Мөхиб апаның ике сабые калды, берсе үзе төрмәдә вакытта үлде. Бер кызы – Сираева Җәүһәрия исән... Мондый хәл безнең баштан да үтте. Әниемне Миргазыян уч төбедәй тәлинкәгә салынган куырган бодай белән тотып, үзеннән дә кушып, милициягә илтеп бирде. Әниемне 5 елга хөкем иттеләр. Судтан соң Күчемова Мөзәккия апа безгә килеп: «Җәннәт апа, судья бездә квартирда, ул яңадан эш кузгатырга кушты»,– диде. Ә иртә белән унике яшьлек күршебез Шарыгин Әүхат абый кереп: «Җәннәт апа, «эш»не яңадан караттыр, бәрәңгеңне сатып булса да. Үзем шаһит булып барам, беләсең, мин басу каравылчысы идем бит. Юлда чәчелгән бодайны үзем җыеп алырга куштым, диярмен»,– диде. Һәм шулай итеп унике яшьлек Әүхат абый алдында Миргазыян да каушап калган, әниемне ακладылар».

Сугыш елларында мәктәптә хатын-кызлар эшли. Шуларның берсе Нуретдинова Бәһия була. Ул түбәндәге истәлекләрне язып калдырган: «1940 елда Корыч урта мәктәбен тәмамлагач мине башлангыч класслар укытучысы итеп Катайга җибәрделәр. Беренче класста 50 бала иде. Беренче чиректән соң аларның тугызын икенче класска күчерделәр. Миңа, яңа гына мәктәп тәмамлаган тәҗрибәсез укытучыга, бик авыр иде. Икенче елны сугыш башланды. Балалар ачлыктан интектеләр, классларда суык, фронттан да хәбәрләр начар иде. Дәфтәрләр, китаплар булмады диярлек. Балалар мәктәпне ташлыйлар иде, күпләре дәресләрне калдырып укыдылар, мәктәпкә йөри алмаганнарны өйләренә барып укыта идек. Сугыш бетте, әмма авырлыклар әле аннан соң да бик озакка барды».

1943 елның июлендә Катайда балалар йорты (детдом) ачыла. Монда илнең төрле почмакларыннан ятим калган 120 ләп сабый бала сыену таба. Аның директоры Гурий Порфирий улы Денисов (1916 елгы) була. Фронттан кайткан Әхнәф Әхмәтлатыйф улы Хафизов бухгалтер булып эшли. Галиев Зиннәт, Бәдретдинов Зәкиулла, аның хатыны Хәдичә, Дәүләтова Фәния, Хафизова Мәгъфия, Нәбиева Нәкыяларның да хезмәт биографиясе әлеге балалар йорты белән бәйле. 1951 елда Бөгәбашка күчерелгәнче, детдом үз ихтыяҗлары өчен мал-туар да тоткан.

Сугыш күпме кешегә кайгы-хәсрәт китерде, балаларны ятим итте, язмышларны җимерде – болар хакында сөйләве чиктән тыш авыр. Халыкның ачы



**«Халык хәтере» сайты документында – Яңа Катай кешеләре. Сугыш бетү белән Бакалы хәрби комиссариаты кешеләрдән сораштырып хәбәрсез югалганнарның менә шундый исемлекләрен төзи башлый**

язмышын чагылдыргандай, авыл да михнәтле елларда кечерәя, анда нибары 400 хуҗалык торып кала.

Менә тагын шушы бер гасырда кылынган ничәнчедер (!) афәтнең Катай авылына да китергән трагедиясен күрдек. Озынрак гомерле кешеләр үз йөрәге, үз җилкәсе белән татыды барлык ошбу бәла-казаларны. Бер буын, бер гасыр өчен артык күп түгелме соң бу кадәр җәфалану?

## Без тынычта аттан артык эшлибез

1945 елның 9 маенда илебез тантана итте, күпме газаплар белән көткән бөек Җиңү килде. Авыр сугыш юллары үтеп фронт киемнәреннән туган якларына ир-егетләр кайта башлады. Аларның бала-чагаларының, туганнарының, хатыннарының шатлыклы авазларыннан Катай тагын да җанланып китә.

Сугышта чыныгу алган, тыныч хезмәткә сусаган ир-егетләр җиң сызганып туган колхозлары кырларына эшкә чыгалар, шактый таушалган каралтыларны ныгыта, яңасын төзи башлыйлар. Дәррәү балта-пычкы, чүкеч тавышлары торган саен ныграк яңгырый, өмәләргә чакырулар ешая.

Авыл нинди проблемалар белән яшәгәнен Катай авыл советы документларыннан күрәбез. 1945 елның 22 июнендә булган 2 нче сессиядә көн тәртибе буенча язгы чәчүгә йомгак, уңыш җыюга хәзерлек, сәрмәя туплау һәм хөкүмәткә авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләү карала, бурычлар куела, заем җыю буенча җитешсезлекләрне бетерү кирәклеге ассызыклана. 20 июльдәге башкарма комитет утырышында көн тәртибе мәсьәләләренең соңгы икесе тагын карала, тагын бурычлар куела. Сәрмәя туплау һәм заемнар җыюны «үз югарылыгына җиткерү өчен бригада төзеп, бу бригадага комскомитет секретарьларын, заемуполномоченныйларны, а/с активларын билгеләргә һәм бу бригада 21/VII нән эшли башларга» тиеш була. 13 сентябрьдә булган утырышның көн тәртибенә уңыш җыеп алу һәм тагын шул сәрмәяләр туплау мәсьәләсе куела[1].

Халыкның акчасы юк, ә аннан сәрмәя, заемнарга язылуны сорыйлар. Сугыш чорында заемнарга язылу мәҗбүри булса, инде хәзер дә авыл кешесе соңгы тиенен бирергә тиеш була. Хөкүмәт әнә шулай бөтен авырлыкларны халык җилкәсенә өя, ә халык иңрәнеп булса да яшәргә тырыша, тырмаша.

Сугыш беткәннең икенче елы. Әле нинди дә булса үзгәрешләр сизелми. Халык туйганчы ипи ашый алмый, ярым ач яши, кием-салым, башка кирәк-ярак юклыктан җәфа чигә. Сугыш елларындагы кебек үк, техника, атлар җитми, сыер һәм үгезләрне җигәргә туры килә. Игенче булганын барлап, тыныч 1946 ел сабанына әзерләнә.

«Авыл хуҗалыгы коралларын ремонтлау эшләре дә тәмамлану алдында. 91 пар тырма, 32 сабан, 23 драпач, 6 чәчкеч ремонтланды. Атлар һәм мөгезле эре терлекләр өчен кирәкле күләмдә сбруйлар әзерләнде. 12 үгез, 20 дән артык сыер җигәргә өйрәтелде. Алар хәзер дә эштә кулланылалар». Бу язмада Иске Катайдагы «Байкал» колхозы турында сүз бара[2].

[1] БҖОУДА, 2434 ф., 1 тасв., 3 сакл. бер., 23–38 бб.

[2] «Ударчы», 1946 ел, 2 февраль.



**Сулда минем әтием – Кәримов Тимергазим Шәймөхәммәт улы. 1946 ел**

Язгы эшләр, бинһая авырлыкларга карамастан, вакытында башкарыла. Инде җәй дә көзгә авышкан чорда басуларда иген җыю эшләре башлана. Монда да игенче сынатмый, җиң сызганып, зур тырышлык белән эшли.

««Байкал» колхозы члены Зарипов Хәниф игеннәрне урып-җыюның беренче көненнән башлап ургыч машинада эшли башлады. Ул эшкә иртән килеп соң китә, үзенә беркетелгән атларны яхшы тәрбияләп йөртә. Шуның нәтиҗәсендә иптәш Зарипов көнлек эш нормасы 4 гектар урынына һәр көнне 7 шәр гектар мәйданның ашлыгын урдыра», дип яза район газетасы[1].

Мондый фидакяр хезмәт мисалларын күпләп китерергә була. Үз-үзен аямыйча, авырлыкларны җиңә-җиңә, игенче табын муллыгын булдыруга зур өлеш кертә. Тик бу муллык тиз генә килми әле (дәүләткә дип читкә ташыйлар), аның өчен шактый еллар тир түгәргә туры килә.

Яугирлар белән бер үк вакытта диярлек сугыш елларында мобилизация белән ФЗО («фабрично-заводское обучение») мәктәпләренә җибәрелгән Катай яшьләре дә авылга кайта башлый. Шуларның берсе – Кәримов Тимергазим Шәймөхәммәт улы, минем әтием була (тексттагы 1946 елгы фотода ФЗО киеменнән, сул якта). Һөнәр алып, чыныгып кайткан ир-егетләр җиң сызганып колхоз эшенә керешәләр.

Яугир авылдашларыбызның бер ише сугыш бетү белән кайтса, башкалары хәрби хезмәт срогын тутыргач кына андый мөмкинчелеккә ия була. Фронт киеме – ул чорның бер төсмере, шактый вакыт ветеранның өстеннән төшмичә,

[1] «Ударчы», 1946 ел, 11 август.



**Шәйхезаман Госман улы Шәяхмәтов хатыны Рауза һәм энесе Гыйльман белән**

җуелмас истәлек булып фоторәсемгә дә күчә. Шул чорның (1947 ел, гыйнвар ае) кадерле ядкарендә орденлы авылдашыбыз Шәйхезаман Госман улы Шәяхмәтовны хатыны Рауза һәм энесе Гыйльман Госманов белән күрәсез.

Сугыш беткән елны «Байкал» колхозында югарыда телгә алынган Шәйхетдин Хаковны Иксанов Муллагаян Нурислам улы алыштыра. Тик аңа озак эшләргә насыйп булмый, эшеннән зур кимчелек табалар. Аның «эше» 1946 елның 4 ноябрендә Бакалы район башкарма комитеты утырышында карала. Иксанов идарә утырышы үткәрмичә, бары тик күрсәтмә биреп складтан колхоз активына 578 килограмм икмәк тараткан. Үзе – 50, колхозның ревизия комиссиясе рәисе Гаязов 48 кг икмәк алган. Аның бу гамәле законны санга сукмау дип бәяләнә, чөнки шул елның 19 сентябреннән СССР ның Министрлар Советы күрсәтмәләр, записикалар нигезендә икмәк өләшүне тыйган була. Район башкарма комитеты өләшенгән икмәкне кире үз урынына кайтарырга, прокурорга җинаять эше кузгатырга, район хәзерләү бүлеге мөдиренә Иксанов белән Гаязовның үз вазифаларында калу-калмауны колхозчыларның гомуми җыелышында карарга куша[1].

Мондый «җинаят»ең булгач кая инде үз урыныңда калу! Иксановтан соң «Байкал» колхозында Б. Фарукшин (Мостафадан), аннары Фазлыев Кәшбелгаян рәислек итә. Яңа Катайдагы «Яңа тормыш» колхозы рәисе булып Харисов Нәҗип (1945, 1946 һәм 1949 елларда), Миңлекәев Әсмәндияр (1947, 1948), Хәбибуллин Яхъялар (1950) эшли.

Колхозларны тагын да ныгыту көн таләбе булып кала. Партия оешмалары инициативасы белән актуаль мәсьәләләр коммунистлар фиркасе ачык җыелышларында тикшерелә торган була. Шуларның берсе 1948 елның 20 ноябрендә «Байкал» колхозында үтә. Анда 9 фирка әгъзасы, 1 әгъзалыкка кандидат, 20 колхозчы актив катнаша. Ул вакытта илебездә дала районнарында корылыкка каршы көрәш максатыннан агач утырту турында карар кабул ителеп, бу карарны үтәү максатыннан зур эш алып барыла. Җыелышта бу эшне Иске Катайда да башлау турында сөйләшәләр,

[1] БҮДТА, Р-1102 ф., 3 тасв., 8 сакл. бер., 286 б.

# Колхоз тормышыннан



**Колхозчылар җыелышка килгән**



**Рәис җыелыш алып бара. 1956 ел**



**Алгы планда колхоз рәисе Әнвәр Фәрхетдинов**


Почетная грамота
Центральный Совет Добровольного Спортивного Общества „Колхозник"
награждает
члена совета коллектива физкультуры колхоза Янги Турмыш Бакалинского р-на, Башкирской АССР
тов. ФАРХУТДИНОВА Анвар
за успехи достигнутые в организации массовой физкультурной работы на селе в 1955 году.
Председатель Президиума Центрального Совета ДСО „Колхозник" /А. КУКУШК
г. Москва „...." ....X...195

**Спортта уңышлар өчен – грамота**

гамәлгә ашыру чараларын билгелиләр. Җыелышта каралган икенче төп мәсьәлә – атлар. Сүз колхоз рәисе Фарукшинга, аннары 4 нче бригада бригадиры Фәрраховка, ат караучы Садыйков Габдерәкыйпка, җыелыш рәисе Фазлыевка бирелә. Җыелыш атларны карауны яхшырту чараларын оештыруны Ф. Сафин һәм Хафизовка йөкли. Колхоз идарәсе белән берлектә алар ат абзарын ныгыту, ат җигүчеләрне контрольдә тоту, атларның асларын һәр көнне тазартып, тиресен тиешле урынга яхшылап өю эшләрен башкарырга тиеш булалар[1].

Ил буенча барган колхозларны эреләндерү сәясәте Катайны да читләтеп үтми. 1951 елда «Яңа тормыш» һәм «Байкал» колхозлары берләштерелә, «Яңа тормыш» исеме уртак булып кала. Бу чорда Иске Катайда – 207, Яңа Катайда 264 хуҗалык була. Колхозга башта Кәшбелгаян Фазлыев, аннары Әнвәр Нуретдин улы Фәрхетдинов (1955 елдан), Әбүгали Солтангали улы Шәнгәрәевлар (1958 елның мартыннан, ул үзе Камайдан) җитәкчелек итәләр.

Колхозның 1953 елда 213 аты, 402 мөгезле эре терлеге, 92 сыеры, 802 баш сарыгы, 50 ана дуңгызы, 2122 баш кошлары була. Әмма Фәрхетдинов рәислек иткән чорда терлек саны кими: атлар – 205, сыерлар – 76, сарык – 777, кошлар 1178 баш торып кала. «Яңа тормыш» колхозының артта калуы турында район гәзитендә язып чыгалар. Шуннан соң район түрәләре ышанычын акламаган рәис озак эшләми, башка эшкә күчерелә.

Әмма Әнвәр Фәрхетдинов рәислек иткән чор халык күңелендә якты истәлек булып кала. Катайлылардан футбол командасы оештырыла, спорттагы уңышлары өчен «Яңа тормыш» колхозы «Колхозчы» ирекле спорт җәмгыяте Үзәк советының мактау грамотасы белән бүләкләнә. Спорт белән бергә мәдәни тормыш та җанланып китә.

Мал-туар санын арттырганда, табыш та, халыкның бер өлешенә шөгыль дә була. Шуны күздә тотып дип уйларга кирәк, илленче еллардан төзелешкә

[1] БҖОҮДА, 4436 ф., 2 тасв., 1 сакл. бер., 8–9 б.



**Катайлылардан футбол командасы**

игътибар арта. Бу хакта район газетасының 1956 елның 9 февралендә чыккан санында түбәндәгеләр языла: «100 баш сыер сыешлы стандарт коровник төзү өчен таш әзерли башладылар. Таш хәзерләүдә һәр көнне 20 кеше эшли, алар 617 кубометр ташны чыгардылар инде. Ташлар чыгарылган урыннарда өелеп куела. Таш хәзерләү эшләре белән колхозның төзү бригадасы бригадиры Фәрвазов Мөдәрис җитәкчелек итә».

Илленче еллар уртасында да уңыш җыю эшләре шактый мәйданда кул көче белән башкарыла әле. «Биш көн эчендә 285 гектарның арышы кул урагы белән урылды. Бригадиры Ш. Госманов булган беренче кырчылык бригадасы алда бара. Биредә кул урагы белән 86 гектарның арышы урылды. Колхозчы Сәгыйдә Ахунова, Әсма Янгирова, Гаделбану Күчемова иптәшләр уракта көндәлек норманы арттырып үтиләр. Урып-җыю эшләрендә колхоз буенча 500 колхозчы катнаша. Колхозны хезмәтләндерүче Корыч МТСының 6 комбайны үз участокларына төштеләр. Колхозчы Әнвәр Фәттахов агрегаты «Сталинец-1» комбайны белән тәүлеккә 20 гектарның арышын урып-җыйды», дип яза район газетасына Катай авыл советы секретаре Р. Госманов[1].

Дәүләткә ашлык тапшыру барганда, йөкләмәләр үтәлүгә карап, колхозчыларга аванс бирергә рөхсәт итәләр. Шуны күздә тотып, колхоз идарәсе 1956 елның август башларында, мәсәлән, апрель-июнь айлары өчен һәр



**Исәп-хисап алып баручылар (сулдан уңга): Тәлгать Әюпов, Мисбах Күчемов һәм Газим Харисов. 1956 ел**

[1] «Коммунизмга» район гәзите, 1955 ел, 28 июль.



даярки по надою молоко за сентябрь месяц 1959 г. по к-зу "Яна-турмуш"

| Фамилия и имя | Закреплена к-в | Надоёна с начала года | В т.ч. за сентябрь месяц | На фуражную корову с начала года | На фуражную корову за сентябрь м-ц | Занимаемое место с начала года | Заним. место за сент месяц |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Арсланова Фания | 10 | 16083,5 | 1589,5 | 1603 | 159 | 3 | 5 |
| Харисова Хана | 10 | 14944,5 | 1612 | 1494 | 161 | 5 | 4 |
| Хафизова Гафия | 10 | 1545495 | 1540 | 1545 | 154 | 4 | 9 |
| Шавалиева Райхана | 10 | 16242 | 1565 | 1624 | 156,5 | 2 | 6 |
| Кашапова Фанадия | 10 | 14300,5 | 1406 | 1430 | 140,5 | 10 | 13 |
| Хабирова Лена | 10 | 13706 | 1487 | 1370,5 | 148,5 | 11 | 10 |
| Галиева Сафира | 10 | 13558,5 | 1471,5 | 1355,5 | 147 | 12 | 11 |
| Набиева Василя | 10 | 14878 | 1734,5 | 1487,5 | 173,5 | 6 | 2 |
| Ахмадишина Музагара | 10 | 13259,5 | 1624,5 | 1326 | 162,5 | 13 | 3 |
| Хабибуллина Разия | 10 | 14416 | 1340 | 1441,5 | 144 | 9 | 12 |
| Гаязова Разина | 9 | 12990 | 1396 | 1443 | 155 | 8 | 8 |
| Гиздатуллина Назибя | 8 | 11775,5 | 1252,5 | 1472 | 156,5 | 7 | 7 |
| Хабибуллина Гамбария | 7 | 11808,5 | 1256 | 1687 | 179 | 1 | 1 |
| итого | 124 | 183362 | 19274,5 | | | | |

**Сыер савучылар исемлеге. 1959 ел**

хезмәт көненә 500 әр грамм күләмендә аванс бирергә карар чыгара. Гыйльмиҗамал Гайфетдинова үзенең хезмәт көннәре өчен 97 килограмм, Гариф Фәррахов, Хәсбиҗиһан Әхмәтова, Афзал Бәдретдинов гаиләләре 1,5 тән алып 3 центнерга чаклы аванс алалар. Бу чорда колхозның 4625 гектар чәчүлек җире була[1].

Колхозчыларның хезмәт көненә күбесенчә әнә шулай натуралата (акча белән түгел) түләгәннәр. Яхшы исәп-хисап алып бару бу чорда Тәлгать Әюпов, Мисбах Күчемов һәм Газим Харисовларга йөкләнгән була.

1959 елда колхоз 34000 центнер уңыш җыеп ала, шуның 13200 центнеры дәүләткә сатыла. Колхозчыларга һәр хезмәт көненә 3 әр килограмм исәбеннән икмәк өләшенә. Арыш уңышы бер гектарга уртача 14,6 (йөкләмә 12), бодай 13,3 (11), солы 15,3 (9), борчак 14,3 (7) туры килә, йөкләмәләр арттырып үтәлә. Уңышны вакытында җыеп алуда Сираев (лафетта 729 гектар бөртеклеләр, 100 гектардан артык кукуруз мәйданын чаптыра), комбайнчылар Галиуллин Җәмигънур, Дәүләтов Т. һәм Госманов Г. зур тырышлык күрсәтәләр. Галиуллин 583 гектар мәйданның уңышын җыеп ала, Дәүләтов – 433 (5455 центнер), яшь комбайнчы Госманов – 369 (4581 центнер). 200 гектардан карабодай, 113 гектардан бәрәңге уңышы да җыеп алына[2].

1959 елда колхозда 124 баш савым сыер исәпләнә, сөт җитештерү күләме артканнан-арта. Савучылардан Хәбибуллина Гамбәрия, Нәбиева Вәсилә, Арсланова Фәния, Хафизова Гафия зур хезмәт җитештерүчәнлеге белән эшлиләр.

Илленче еллар авыл тормышына шактый яңалыклар алып килә. 1955 елны Катайга радио кертелә. Бу эшне монтер белгечлегенә ия булган Әсләм Гариф улы Күчемов башкара. Электр чыбыкларын беренче сузучы Зәкиулла Гыйният улы Бәдретдинов була. 1956 елдан электр җегәре (ул движоктан алына) Яңа Катай ягындагы ферма ихтыяҗлары өчен кулланылса, аның икенче елында авылга керә башлый. Шуңа бәйле рәвештә телефон да 1956 елдан «МБ»дан

[1] «Коммунизмга», 1956 ел, 16 август.

[2] БҖОҮДА, 4436 ф., 3 тасв., 12 сакл. бер., 28–31 б.

(«местно-батарейный»-дан) »ЦБ»га («централь-но-батарейный»га) күчә. Моның өчен Бакалыдан 40 вольт йөрешле чыбыклар сузалар.



**Яңа Катай кызлары Сабантуйда**

Движок, билгеле, бик аз микъдарда гына электрга ихтыяҗны канәгатьләндергән. Шуңа күрә «Яңа тормыш» һәм «Яңа көч» (Килкабыз) колхозлары үзләренең гомуми көчләре белән ягулык ярдәмендә эшли торган электр станциясе төзергә карар итәләр. Төзелеш буенча совет рәисе итеп Фәрхетдиновны сайлыйлар. Җыелыштан соң, берничә көн үткәч, Иске Катайда төзү эшләре башланып китә. Нигез салына, локомобиль куелачак бина бурала. Тиз араларда склад төзеп куялар. «Яңа көч» колхозы ягулык электр станциясенең эшләячәгенә исәп тотып, пилорама сатып ала һәм аны булачак станциянең нигезе янына урнаштыра. Әмма эшләр шуннан ары китми, ахыр чиктә, уртак мөлкәт бүленә. Авыл башында станция өчен җиткезелгән бинаны берникадәр вакыт ипи пешерү өчен пекарня итеп файдаланалар, аннары алтмышынчы елларда сүтәләр.

Илленче еллар – күп авырлыклар инде артта калган, авылның мәдәни тормышы җанлана, Сабантуй һәм башка бәйрәмнәр дә күңелле үтә башлаган чор. Халык яңа өс-баш киемнәрен сатып ала, торган саен матур киенә башлый. Сабантуена аллы-гөлле чәчәкле җыйнак яулыклар бәйләгән, матур күлмәкләр киеп чыккан Яңа Катай кызларын шул чордагы фоторәсемнән күрәсез.

Мәдәни тормыш дигәннән, район газетасында басылган язмаларның берсенә игътибар итик: «Катай колхозының клубы үзешчән сәнгать коллективы район үзәгендә үзешчән сәнгать көчләренә смотрда үзенең осталыгын күрсәтте. Бу коллектив район культура йорты сәхнәсендә Таҗи Гыйззәтнең биш пәрдәлек «Изге аманәт» пьесасын куйды. Пьесадагы карт шахтер Гыйният ролен – Хәбиб Шәкүров, Фоат ролен – Атлас Фазлыев, Нажия – Ф. Гайнуллина, Хәзинә – Топоркова, Асфан – Ф. Гомәров, Лида – Л. Хисамова, Мартынов – Хафизов, Остап Тимофеевич – Н. Гыйззәтов, Афанас Архипович – З. Вахитов иптәшләр зур осталык белән башкардылар. Ф. Якупов, З. Сәрвәров иптәшләр кире характерлы рольләрне табигый итеп башкаруга зур көч салдылар. Пьесаны тамашачылар зур канәгатьләнү белән карадылар»[1].

[1] «Коммунизмга», 1956 ел, 5 февраль.




**Хезмәт алдынгылары. 1964 ел, октябрь**



**Хезмәт алдынгылары. 1965 ел**

Авыл һәм район сәхнәләрендә концерт-пьесалар белән Катай һәвәскәрләре моннан соңгы елларда да уңышлы чыгыш ясап баралар, зур осталыклары белән тамашачы күңелен яулыйлар.

Сугыштан соңгы чорда Катай авыл советы җитәкчеләре әледән-әле алышынып тора. Истәлекләргә караганда, 1945–1949 елларда авыл советы башкарма комитеты рәисе булып Хәбибуллин Яхъя эшли. 1951 елның декабреннән рәис вазифасын коммунист Тимергаян Гаязов, ә 1955 елның мартыннан коммунист Мирзаәхмәт Нәбиев башкара. Секретарь булып 1952 елның июленнән Рифгать Госманов эшли[1].

1960 елның 4 апрелендә Катай авылын «Бакалы» совхозына кушалар, бүлекчә җитәкчесе (управляющие) итеп Әбүгали Солтангали улы Шәнгәрәев билгеләнә. Шул ук елның җәендә ул башка эшкә күчерелә, бу вазифаны берничә ай Әмир Афзал улы Баһаутдинов башкара. Моннан соң бүлекчә җитәкчесе – Фәез Мирзаәхмәт улы Нәбиев.

Фәез Нәбиев Катай бүлекчәсенә 1960 елның көзеннән 1968 елның августына чаклы җитәкчелек итә. Бу чорда күп кенә төзелеш эшләре алып барыла. Сыер, бозау, дуңгыз абзарлары, сарык фермасы (Яңа Катайда), складлар салына. Бу эшләрне 75 кешедән торган төзелеш бригадасы башкара. Катай бүлекчәсендә генә 700 эшче була ул чакта, алар арасыннан хезмәт алдынгыларын авылдашым Әлфия Зиннурова җибәргән фоторәсемнәрдә күрәсез (Өстәгесендә беренче рәттә (сулдан уңга): Яхин Мәүләви, Әхмәтова Фәүзәна, Әхмәтова Мәсхүдә, Мәхмүтҗанова Галимә, Дәүләтов Мәүләви һәм Хафизов Мәдих; 2 нче рәттә (сулдан уңга): Латыйпов Әшрәфҗан, Шәяхмәтов Зиннур, Латыйпов Зәки, Госманов Рифгать, Галиуллина Гафия, Нәбиев Фәез, Фәррахова Зилә, Шәкүров Хәбиб, Сөнәгатуллин Нурулла; астагысында – Галиуллин Җәмигънур, Шәяхмәтов Зиннур, Госманов Гыйльман, Фәттахов Тәлгать, Мөхәммәтдинов Роберт, Исмәгыйлов Фән). 1963 елның октябрь аеннан Бакалыдан электр энергиясе килә башлый, авыл тулысынча электрлаштырыла.

1961 елның 9 мартында авыл советы сессиясендә рәис итеп Фәварис Хәмзә улы Гомәров, секретарьлеккә Фәварис Хәниф улы Вәлиев сайлана. Фәварис Гомәров укуга киткәч, 1962 елның 5 октябреннән Фәварис Вәлиев – рәис, Әмирҗан Нәфиков секретарь вазифасын башкаралар. 1966 елның 21 апреленнән авыл советында Әмирҗан Нурлыгаян улы Нәфиков (рәис) һәм Газим Харис улы Харисовлар (секретарь) эшли[2].

Сугыштан соңгы елларда Катай мәктәбе озак вакытлар җидееллык булып кала. 1946 елдан 1959 елга кадәр аның директоры булып Әнгам Габделхак улы Яугилдин эшли. Бу чорда шактый үзгәрешләр була. 1951 елны балалар йорты башка җиргә күчерелә, аның биналары мәктәп карамагына бирелә. Нәтиҗәдә, бишенче, алтынчы, җиденче класслар бу биналарга күчәләр. Ә башлангыч

[1] БҮДТА, Р-1102 ф., 3 тасв., 40, 58 сакл. бер.

[2] Бакалы район архивы, 32 ф., 1 тасв., Яңа Катай авыл советы (1961 елның 4 февраленнән 1968 елның 16 сентябренә кадәр булган сессияләрнең протоколлары).




**Катай урта мәктәбе укытучылары коллективы. 1967 ел**

классларэлеккеге урында, Яңа Катайда кала. Ул мөстәкыйль башлангыч мәктәпкә әйләнә, аның директоры булып Зыязетдин Сәрвәров эшли. Директорлардан тыш, мәктәпләрдә Михаил Максим улы Агилев, Мирсалих Яугилдин, Вәҗиха Гобәйдуллина, Валентина Степанова, Хәзинә Күчемова, Кыям Ситдыйков (1951 елдан), Мәүфәт Садыйков, Гобәев, Бәһия Нуретдинова, Әнисә Яугилдина һәм башка укытучылар эшли.

1959–1960 уку елын мәктәп (ул сигезьеллык итеп үзгәртелә) яңа директор белән башлый. Әлеге вазифага югары уку йортын тәмамлаган яшь белгеч Равил Ислам улы Дәүләтов билгеләнә. Уртача чыгарылыш 40–56 укучы була. 1963–1966 елларда мәктәп өчен агачтан зур яңа бина салына. 1964 елдан биредә – бию (җитәкчесе М. Г. Хафизова), 1967 елдан тынлы оркестр (Р. Җ. Хәсәнов) түгәрәкләре эшли башлады.

Тынлы оркестр түгәрәгенә беренчеләрдән булып Айрат һәм Рузалин Әхмәтовлар, Тимерҗан Галиев, Зинир Заһиров, Рифкат Күчемов, Рудамир Латыйпов, Диләвир Нәбиев, Ринат һәм Риф Нәбиевлар, Ирек Шәрифуллин, Хәбиб Йосыпов, Фәнәвис Йосыпов, Миргалифан Шагалиев, Камил Шакировлар йөриләр. Түгәрәк 1967 елның сентябрь уртасында эшли башлый, ә инде 7 ноябрьдә беренче тапкыр демонстрациядә катнаша. Оркестр башкаруында СССР гимны, революцион һәм башка җыр маршлары демонстрацияләргә, мәктәптәге төрле тантаналарга искитмәле бәйрәм рухы өсти торган иде.

1966 елда Катай сигезьеллык мәктәбе урта мәктәп (унъеллык) статусын ала. 1966–1967 уку елында Катай урта мәктәбендә барлыгы 528 укучы исәпләнә. 1967 елда укучылар саны 552 гә җитә. Мәктәптә 35 укытучы эшли, аларның унбере – югары белемле, унбише читтән торып укый. Авылда барлыгы 2150 кеше яши.

Алтмышынчы елларда Катай мәктәбендә күп кенә укытучылар хезмәт юлын башладылар. Шуларның берсе Ралия Гафият кызы Хәсәнова. 1962 елның августында Мәсгут педагогия училищесын тәмамлаган яшь кызны юллама белән Бакалы районына эшкә җибәрәләр. Ул Катай сигезьеллык мәктәбендә өлкән пионервожатый булып эшли башлый. Бер елдан башлангыч класслар укытучысы итеп билгеләнә. Читтән торып Бөре педагогия институтын тәмамлый, урыс телен һәм әдәбиятын укыта, озак еллар директорның укыту эшләре буенча урынбасары вазифасын да башкара. Сүз уңаеннан әйтим, Ралия апа минем һәм энекәшем Дамирның беренче укытучысы, класс җитәкчесе булды. Бүгенге көндә лаеклы ялда, аның тормыш иптәше укытучыбыз Рәмил Җәмигънур улы Хәсәнов иде.

Ралия Хәсәновадан өлкән пионервожатый вазифасын 1963 елның 29 августында Ахунова Римма Бәгзинур кызы кабул итеп ала. Аның да бу вазифасы вакытлыча була, белемен күтәреп, биология укытучысы булып китә. Пенсиягә чыккач та укытты ул, директорның класстан тыш эшләр буенча урынбасары эшен дә алып барды.

1964 елда Катай сигезьеллык мәктәбенә биология укытучысы булып Фәттахова Зәйфә Хәлим кызы килә. Белгечлеге авыл хуҗалыгы буенча булса да, укытучы һөнәрен үз итә. Читтән торып Казан педагогия институтына укырга керә (1968), аны уңышлы тәмамлый. Күп еллар мәктәптә биология, география, тарих һәм химия фәннәрен укытты, класс җитәкчесе булып эшләде. Зәйфә апа бер үк вакытта мәктәп яны тәҗрибә участогы өчен дә җаваплы булды. Укучыларны эш сөяргә, тәҗрибә үткәрергә, яшелчә-җимеш үстерергә өйрәтте, тыныч холкы, ягымлы карашы белән аерылып торды. Ул да, вакыты җиткәч, лаеклы ялга чыкты.

Мәктәп сигезьеллыктан унъеллыкка үзгәртелгәч, авылның югары уку йортын тәмамлаган үз уллары һәм кызлары эшкә кайта башлый. Шуларның берсе – Рүзидә Фәрвазова. Мин аннан үз истәлекләре белән уртаклашуын сорадым, җавап итеп Рүзидә апа түбәндәге истәлекләрне язып җибәрде.

«Мин Катай мәктәбенә 1967 елның 1 сентябрендә кайттым, Равил Ислам улы юллавы буенча. Аңарчы Бакалының 1 нче санлы урта мәктәбендә бер ел эшләп алдым. Минем белән бергә Ихсанова Лина Гаяновна кайтты. Ул урыс теле һәм тарих фәннәрен укытты, ә мин математика һәм 10 нчы класста физика укыттым, беренче чыгарылышта (10 нчы класста) класс җитәкчесе идем. 1973 елның гыйнвар аенда райкомга эшкә күчү сәбәпле мәктәптән киттем. Лина Гаяновна, 1972 елда булса кирәк, РОНОга эшкә күчте. Мин эшләгән дәвердә Йосыпов Әгъзам физрук булып эшләде. Фәвәрис Хәмзә улы Гомәров

химия белән биология укытты, соңыннан аны Илек мәктәбенә директор итеп җибәрделәр. Мин башлангыч класста укыганда башлангыч класс укытучылары Мофаздалова Бибигалимә белән Гобәйдуллина Вәҗиха апалар булды «башкорт» ягында, ә завуч Сәрваров Зыязетдин абый иде (1949–1953 елларда). Фәнә апа мине ана теленнән укытты, ул күп еллар завуч булып эшләде һәм татар әдәбиятын укытты. Рәмдерәк абый, Әнгәм абыйлар – минем беренче математика укытучыларым! Башлангыч классларда Нуретдинова Бәхия белән Степанова Валентина апалар эшләде. 1968 елның 1 сентябреннән физиканы Исламова Фәния Фатыховна укыта башлады. Синең бүгенге көндә Катайда тормыш иптәше Фән Гата улы Хафизов белән гомер итүче икетуган апаң Халә Ярмөхәммәт кызы да мәктәптә пионервожатый булып эшләде (Халә апа Маты унъеллык мәктәбен тәмамлый (1956 ел; беренче чыгарылыш), Катайдан чыгып киткәнче бер ел пионервожатый булып эшли.– *Т.К.*) ».

1964 елда Яңа Катай ягында яңа клуб һәм китапханә төзелә. Китапханә мөдире итеп 1959 елдан Әлфия Мирза кызы Хәйдәрова эшкә алына (аңа чаклы бер-бер артлы Зәкуан Вахитов, Венера Шәнгәрәевалар эшли).

Үзенең ничек итеп эшли башлавын Әлфия Мирза кызы болай искә ала: «1959 ел азакларында мине вакытлыча Катай китапханәсенә эшкә кайтардылар (декретка чыгучы Венера Шәнгәрәева урынына). Бакалыда эшли идем, клуб мөдире Вахитов Зәкуан абый, минем эшләп торуымны район хуҗаларыннан сораган, соңыннан үз эшемә кайтырга тиеш идем. Дөрес, авылдашлар белән уртак тел табуы җиңел булмады. Китапханәдә тәмәке тартуны, чүпләүне, акырып сөйләшүне бетерү, исерек килмәүләрне булдыру бурычы тора иде. Эшне төрле алымнардан – яшьләрнең ялы күңелле үтсен өчен кичәләр, конференцияләр, диспутлар оештырудан һәм башка яңа чаралардан башлап җибәрергә туры килде. Һәр чараны үткәрүгә җитәкчеләрнең катнашуларын, ярдәмләшүләрен сорадым. Эшләр уңай якка үзгәрә башлады. Фермада эшләүче яшьләр райкомга, минем бөтенләйгә калуымны сорап, хат язганнар. Мин калдым, авылдашларыма яхшы хезмәт итәргә тырыштым».

Әлфия Мирзаәхмәт кызы эшли башлаганда 1670 китап, 260 укучы булса, 1967 елга бу сан ике тапкырдан күбрәккә арта (4109 китап, 690 укучы). Китапханә 32 төрле газета-журнал алдырган. Шул чордан алып 1999 елда лаеклы ялга киткәнчегә кадәр үз эшенең остасы буларак та, авылның иҗтима-



**Сыер савучылар белән очрашу**

гый тормышында актив катнашуы (депутат, соңгы чорга кадәр КПССның башлангыч партия оешмасы секретаре итеп тә сайлана) белән дә аерылып торды Әлфия апа. Ул «Фидакяр хезмәт өчен» (ике тапкыр) һәм «Хезмәт ветераны» медальләре белән бүләкләнә.

Җәйләүдә әледән-әле савучылар белән очрашулар уздыру – Әлфия апаның эш алымнарыннан берсе булуы шул чордагы фоторәсемдә дә чагыла (сез аны текстта күрәсез; уңнан сулга: Зилә Фәррахова, Римма Сабирова, Әлфия Хәйдәрова, Нәкыя [...], Бибидәнә Раипова, Вәсилә Авзалова, Фәнәзия Авзалова)...

Сүз уңаеннан әйтик, Әлфия Мирзаәхмәт кызы Хәйдәрова – авылда беренче махсус белемле китапханәче булды. Аннан кала бу һөнәрне тагын 13 кеше сайлый: Вахитова Рәсимә Зәкуан кызы, Габдерәхимова Фәнүзә Шәйхатдәр кызы, Кәримова Зөлфия Тимергазим кызы (минем апам; Казан дәүләт культура институтын бетерде), Хафизова Зәйлә Кави кызы, Шамбазова Рәсимә Әгълә кызы, Гомәрова Гүзәл Зөфәр кызы (Казан дәүләт культура институты; бүгенге көндә район китапханәсе директоры), Хәбирова Лена Кәбир кызы һәм башкалар. Алар Әлфия апаларына киңәшләре, ярдәме өчен рәхмәтле.

Алтмышынчы еллар катайлыларның зур хезмәт җиңүләре белән дә истәлекле. Галимә Мәхмүтҗанова сөтчелек тармагында югары хезмәт күрсәткечләренә ирешеп, Ленин ордены (1966, 22 март) белән бүләкләнә. РСФСР Югары Советына депутат (1967 елдан), КПСС ның 24 нче съездына делегат итеп тә сайлана. Катай урта мәктәбенә типовой ике этажлы кирпечтән салынган бина, Бакалыда Сөн елгасы аша тимер-бетоннан салынган күпер (элеккесе астарак урнашкан, агачтан иде) – болар Галимә Сабирҗан кызының депутат наказы белән башкарылган эшләренең без ишетеп белгәннәре генә.

Галимә Мәхмүтҗанова белән бер үк көнне Рифгать Госманов «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләнә. Тагын биш елдан аның күкрәген «Октябрь революциясе» ордены бизи.

Алтмышынчы елларда терлекчеләр Нажих Вәлиев, Мәсхүдә Әхмәтова («Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены, 1966 елда), Фәнәдия Харисовалар да орденнар белән бүләкләнәләр. Гамбәрия Хәбибуллина, Фәүзәнә Әхмәтова, Хәбиб Шәкүров, Фәез Нәбиев һәм башкаларга медальләр бирелә.

Катай дуңгызчылык фермасы коллективы 1964 елда районда беренчеләрдән булып коммунистик хезмәт коллективы дигән мактаулы исемгә лаек була. Берничә елдан соң тырыш авылдашларыбыз югары культуралы терлекчелек коллективы исемен дә алалар. Тутыя Гәрәева, Саҗидә Нәбиева һәм Гөлҗәннәт Мансуровалар үз хезмәттәшләре арасында зур осталыклары белән аерылып торалар. Соңрак озак еллар һәм югары җитештерүчән эшләгәне өчен Тутыя Гәрәева «Почет билгесе» ордены (1976 ел) белән бүләкләнә.

Бакалы совхозының Катай бүлекчәсе иң куәтлеләр рәтенә керә. 1967 елда фермаларда 622 баш мөгезле эре терлек, 3234 дуңгыз, 2390 баш сарык була. Болардан тыш, 200 кролик, 4500 тавык та асрала. Һәр сыердан сөт савып алу



**Яңа Катайда печән чапканда. 1955 ел, 28 июнь**

буенча бүлекчә алдынгы урыннарны били. Чәчүлек җире 5054 гектарга җитә. Катай кырларында 14 комбайн һәм 26 трактор эшли. Һәр гектардан 18,58 центнер иген җыеп алынып, хөкүмәткә планда каралган 15000 урынына 25000 центнер иген сатыла (әлеге саннар авыл тарихына багышланган альбомда китерелә). Анның икенче елында, Фәез Мирзаәхмәт улы Нәбиев мәгълүматларына караганда, 76000 центнер уңыш җыеп алына. 1200 гектар мәйданда игелгән борчакның һәр гектары 34 ешәр центнер уңыш бирә. Борчак исәбенә генә диярлек дәүләт заданиесе дә үтәлә.

Ит-сөттән тыш, Катай бүлекчәсендә кымыз да җитештерелә. Исламов Фиркать әйтүенчә, бу эш тулысынча диярлек Мансуров Мәгънәви белән Гыйлаҗев Әүхәди (бияләр карый) карамагында була. Болар белән бергә Кашапов Мөтәвәкил абзый да эшләгән, ул урын Акбур буасы тирәсендә иде, дип өсти Мәннапов Илфак. Шешәләргә тутырылган кымыз кибет киштәләрендә урын ала, кемнәрнендер яраткан эчемлегенә әйләнә.

1967 елда бүлекчәдә 486 – даими, 70 сезонлы эшче исәпләнә. Айлык хезмәт хакы уртача 56 сум булса, аерым эшчеләрнең 90 сумнан 200 сумга кадәр җитә.

Акчасы булгач, халыкның тормыш дәрәҗәсе дә күзгә күренеп яхшыра. Ел саен уннан артык яңа йорт җиткерелә, хуҗалыклар саны тагын да арта, 500 гә кадәр җитә. Йортлар зур, матур итеп салына, түбәләре шифер яисә калай белән ябыла. Авылда 90 мотоцикл, 350 велосипед, 310 радиоалгыч, 8 телевизор була. Иң беренче телевизорларны Вил Шәкүр улы Мофаздалов, Әслам Гариф



**Сабантуйда. 1970 еллар башы**

улы Күчемов һәм Атлас Йосыф улы Фазлыев сатып ала. «Москвич» маркалы җиңел машинада беренчеләрдән булып шул ук Атлас Фазлыев йөри башлый.

Тормыш алга киткән саен бәйрәмнәр дә күңеллерәк үтә. Зур бәйрәмнәрнең берсе – Сабантуй. Ул күп халык катнашында, төрле ярышлар, җыр-уеннар белән үтә. Дистәләрчә еллар гел бер урында үткән Сабантуй мәйданын җитмешенче ел тирәсендәрәк төшерелгән уникаль фотода күрәсез. Читән янында төркем-төркем булып җыелган (басып торган, чүгәләп утырган) катайлылар, волейбол ярышы өчен тарттырып куелган сетка, шат йөзләр (алгы планда көләч йөзле әнием белән сеңлем Зөлфирә, кулын артка куеп елмаеп атлап баручы әтием). Нинди күңелле дә, моңсуландыра да торган мизгелләр!

Әйе, дөньядагы күп илләрдән шактый артта калган булсак та, без шат идек, үзебезне бәхетле саный идек. Бер укытучы авылдашыбыз бердәнбер җиңел машинада йөргән чакта алдынгы дәүләтләрдә һәр ихата саен диярлек машина барлыгын, аның бик тә табигый хәл икәнен без каян белик? Чит илләрне көнтөн хурлыйлар, бәхет ул бездә генә – коммунизм илендә генә, дип сафсата сибәләр, читтән информация дә, юньле-башлы товар да керттермиләр...

## Алга барсак та, артта калганбыз икән...

1968 елда авыл Яңа Маты совхозы бүлекчәсенә әйләнә. Бүлекчә белән берникадәр вакыт Гыйрат Хыял улы Кашапов (Урманайдан), аннары озак еллар Рифкать Гыйльфан улы Госманов җитәкчелек итә. Алар эшләгән чорда да Катай бүлекчәсе ит һәм сөт җитештерү буенча алдынгы урыннарны биләп бара. Терлекчелектә эшләүче дистәгә якын авылдашыбыз хөкүмәтнең төрле дәрәҗәдәге бүләкләренә лаек булды. 1971 елда савучы Галимә Мәхмүтҗанова икенче тапкыр Ленин орденына лаек була. Әхмәтвәлиев Нажих Хан улы (1928 елда туган), ит тапшыру планын һәрвакыт арттырып үтәгәне өчен, «Почет билгесе», «Хезмәт Кызыл Байрагы» орденнары, «В. И. Ленинның 100 еллыгы» юбилей медале, «ВДНХ»ның көмеш (1979 елны) һәм алтын (1980) медальләре белән бүләкләнә. Савучылардан Хәбибуллина Гамбәрия Лотфрахман кызы (1940) «Хезмәт Кызыл Байрагы» орденнарына (1971, 1976), «Хезмәт батырлыгы» медаленә, «ВДНХ»ның көмеш һәм алтын медальләренә лаек була. Аның хезмәттәше Габдерәхимова Сәфирәнең (1943) күкрәген «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены (1973), «9 нчы бишьеллык ударнигы» (1975), «Социалистик ярыш җиңүчесе» (1975) билгеләре бизи.

Савучы Сәлманова Сажидә Әхмәтгали кызы (1938) ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Алтын Башак» билгесе (1969), «В. И. Ленинның 100 еллыгы» юбилей медале (1970), «ВДНХ»ның бронза медальләре (1968, 1970), «Социалистик ярыш җиңүчесе» (1975, 1976), «Бишьеллык ударнигы» (1975) билгеләре, күпсанлы Почет грамоталары белән бүләкләнә, исеме Яңа Маты совхозының Мактау кенәгәсенә языла (1976).

Җитмешенче еллар уртасыннан сөтчелек тармагында Шәйхразыева Гөлсинә Нигъмәтҗан кызы хезмәт юлын башлый, өч ел рәттән районның яшь савучылары арасындагы социалистик ярышта җиңеп чыга, «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале (1981) белән бүләкләнә. Соңрак аның тырыш хезмәте «3 нче дәрәҗә Хезмәт даны» ордены белән дә билгеләнә.

Сөтчелек тармагының нәтиҗәле эшләвендә бригадир Госманов Рифкатьнең өлеше зур була. Ул 1924 елның 16 июнендә туган, 9 класс белем алган, 1941–1945 елларда сугышта катнашкан. Сугыштан кайткач, трактор бригадасында учетчик, авыл советында секретарь булып эшли, аннары ун елдан артыграк (1962–1972) сөтчелек тармагын җитәкли. Мондагы яхшы хезмәт күрсәткечләре өчен «Хезмәт Кызыл Байрагы» (1966), «Октябрь революциясе» (1971) орденнары, «Фидакяр хезмәт өчен» медале (1970), «РСФСР авыл хуҗалыгының социалистик ярыш отличнигы» (1969), «Социалистик ярыш җиңүчесе» (1973)

билгеләренә лаек була. Зур тәҗрибәсен искә алып, аны Катай бүлекчәсе идарәчесе (управляющие) итәләр. Моннан соң «Яңа Маты» совхозында ярдәмчел хуҗалык башлыгы булып та эшли ул.

Катайның ул чордагы уңышлары турында, үткәннең уңай якларын үрнәк итеп алырга өндәп Әлфия апа Хәйдәрова сөйләгәннәр искә төшә. Горурланып, сүз ахырынарак, ачынып, түбәндәгеләрне сөйләде ул: «Безгә еш кына эш алымнарын өйрәнергә киләләр, журналистлар эшләребезне гәзит-журнал битләрендә уңай тәҗрибә итеп язалар иде. Алтмыш сигезенче елларда дүрт районның идеология хезмәткәрләре өч көнлек семинарга килделәр. Йөздән артык кешене аерым йортларга урнаштырдык. Алар яшьләребез ялын оештыруны, көнкүрешен, эш урыннарында эшләүләрен күзәттеләр һәм уңай нәтиҗәгә килделәр. Без – бүлекчә управляющийлары Әбүгали Шәнгәрәев, Әмир Баһаутдинов, Фәез Нәбиев, Рифкать Госманов, авыл советы рәисләре Фәварис Вәлиев, Фәварис Гомәров, Әмирҗан Нәфиков, КПССның башлангыч партия оешмасы секретарьлары Хәбиб Шәкүров, Мисбах Күчемовлар үзебезгә түгел, халыкка булсын дип эшләдек. Үзебез урлашмагач, халкыбыз да урлашмады. Икмәк келәткә керми торып басудан кайтмадык. Төнге кизүләр (дежурстволар) басуда, фермаларда оештырыла иде. Аларны тыңлап нарядлар башланыр иде. «Катай – это есть Катай»,– диярләр иде район, республика трибуналарыннан. Мондый уңышка җитәкчеләр үзләре чиста булса гына ирешергә мөмкин. Эчүче, урлашучы җитәкчене кем санласын? Аның эшчесе дә шуны кабатлый. Шундый җитәкчеләр авылымның йөзенә, авылдашлар ышанычына кара якты. Хатаны төзәтү авыр булачак...»

Ит җитештерүне арттыру максатында, җитмешенче елларның беренче яртысында авылда 12 мең баш дуңгызга исәпләнгән дуңгызчылык комплексы төзелә (ул удар комсомол төзелеше дип игълан ителгәнлектән, бер җәйне хәтта Мәскәү энергетика институты студентлары да эшләде), анда йөзгә якын кеше эш белән мәшгуль була. Иске дуңгызчылык фермасы да эшләвен дәвам итә. Саф татар авылында дуңгыз асрау бөтенләй башка сыймый торган гамәл дә бит, әмма нишлисең, югарыда утыручы коммунист түрәләр шулай мәҗбүр иткәннәр.

Төзелеш ихтыяҗлары өчен «Яңа Маты» совхозының Катай бүлекчәсендә кирпеч җитештерү дә оештырыла. Мондагы техниканы көйләү, эшне оештыру Зиннур Шәяхмәтовка йөкләнә. Бикләндедә җитештерелгән кирпеч терлек абзарлары салганда-төзекләндерелгәндә, шәхси хуҗалыкларда кулланыла.

1970 елны авылны телефонлаштыруда зур адым ясала – 50 номерлы АТС (автоматлаштырылган телефон станциясе) файдалануга тапшырыла. Күп кенә катайлылар өчен телефон хезмәте чынбарлыкка әйләнә. АТСны көйләп-карап торучы Әсләм абый Күчемов була.

Җитмешенче еллар башында авылның иҗтимагый тормышында иң зур вакыйгаларның берсе – ике этажлы типовой мәктәп төзелеп бетү (1972). Аңа 1969 елда нигез салынды, төзелешкә укучылар һәм укытучылар да үзләреннән



**Мәктәп ачу тантанасы. 1973 ел**

берникадәр өлеш кертте. Мәктәп тирәли яшелчә-җимеш бакчасы булдырылды, каен-юкә агачлары утыртылды.

Мәктәпне ачу тантанасы, әле дә хәтерлим, 1973 елның апрелендә булды. Районнан зур кунаклар – КПСС ның Бакалы райкомы беренче секретаре М. Ш. Шакирҗанов (тексттагы фотода ул символик тасманы кисә), райсовет башкарма комитеты рәисе Г. Җ. Хаҗипов, район мәгариф бүлеге мөдире Ә. К. Латыйпов, Яңа Маты совхозы директоры С. Х. Фәхретдинов килгән иде. Символик ачкыч тапшыру, төзүчеләрне һәм мәктәп директоры Р. И. Дәүләтовны мактау грамоталары белән бүләкләү, тынлы оркестр уйнавы, алкышлар – болар барысы да зур бәйрәм рухын чагылдырды, күңелләрдә җуелмас якты истәлек булып калды.

Бу чорда Катай урта мәктәбе районыбызда зурлардан санала. 1971 елның 3 сентябренә монда 590 укучы белем ала. Укыту ике сменада алып барыла.

Җитмешенче елларда мәктәптә зур тәҗрибәле укытучылар – Р. Б. Ахунова (биология укытучысы), Ф. А. Ахунова (физика һәм математика), М. Гарданова (биология укытучысы), З. Х. Гомәров (физика), Т. Н. Гомәрова (чит телләр), Р. И. Дәүләтов (тарих), Р. Г. Дәүләтова (урыс теле һәм әдәбияты), Х. Г. Күчемова (татар теле һәм әдәбияты), В. Ш. Мофаздалов (математика), Л. М. Мофаз-



**Мәктәп ачу тантанасы. 1973 ел**

далова (башлангыч класслар), В. К. Исламов (физкультура), Э. Г. Исламова (чит телләр), Р. Л. Латыйпов (география), М. Н. Садыйков (машиноведение), К. К. Ситдыйков (башлангыч хәрби әзерлек), А. Й. Фазлыев (урыс теле һәм әдәбияты), С. Ш. Фазлыева (татар теле һәм әдәбияты), З. Х. Фәттахова (химия), М. Г. Хафизова (хезмәт), Ф. Н. Хафизов (хезмәт), Л. Г. Хәбирова (башлангыч класслар), Р. Җ. Хәсәнов (җыр), Р. Г. Хәсәнова (урыс теле һәм әдәбияты), М. Х. Хөснетдинова (башлангыч класслар), Ф. Ш. Шәрифҗанова (тарих), Ә. Г. Яугилдин (математика), Ф. Ә. Җәләевалар (математика) һәм башкалар эшләделәр. Болар арасыннан Р. Г. Дәүләтова «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены белән бүләкләнде, күпләре халык мәгарифе отличнигы исеменә лаек булды. Мәктәп тормышы, укытучыларның эш тәҗрибәсе район гәзите битләрендә әледән-әле яктыртылып тора иде. Мәктәп укучылары җәен-көзен басулардан уңыш җыеп алуда зур өлеш кертеп килделәр, бертуган Фәттаховлар кебек комбайнчы-механизатор ярдәмчеләре булып та эшләделәр.

Катай мәктәбен тәмамлаган авылдашларым илебезнең төрле почмакларына сибелгән, араларында нинди генә һөнәр ияләре, нинди генә дәрәҗәгә ирешкәннәре юк, фән өлкәсендә генә галимнәр дистәдән артык. Алар хакында күп язарга, күп сөйләргә булыр иде, тик бу китапта андый максат куймадык, бу хакта



**Алдынгы комбайнчы Әнвәр Фәттахов уллары белән. 1975 ел**

өлешчә сүз «Җиде бабаңны бел, катайлым» китабында барачак. Катай турында сүз барганда нинди генә зур шәхес булмасын, безнең өчен иң әһәмиятлесе — ул шәхес туган авылы өчен нинди эшләр башкарган. Фән докторы Өлфәт Шәяхмәтов кебек үзе укыган мәктәпкә ярдәм иткәнме яисә эшкуар Рәзиф Латыйпов кебек мәчет салдырганмы — күп булмаса да мондый мактап сөйләрлек шәхесләребез бар һәм игелекле эшләр турында сөйләргә дә күңелле.

Җитмешенче-сиксәненче елларда Катай авыл советы башкарма комитеты рәисләре булып Әлфия Мирзаәхмәт кызы Хәйдәрова (1973 елның июненнән), Флүзә Әкрәм кызы Җәләева (1978 елның 8 апреленнән), Рузил Хәмидулла улы Гомәров (1982 елның 25 июненнән), Риф Шәйхенур улы Мансуров (1984 елның 1 августыннан), Рудамир Хәбиб улы Шәкүровлар (1987 елның 26 июненнән) эшләделәр.

Хәзер мәгълүм: зур уңышларга ирешелгән кебек тоелса да, җитмешенче еллар торгынлык еллары дип бәяләнде. Баксаң, без дөньядан күпкә артка калганбыз икән. Авыл хуҗалыгы буенча да, башка өлкәләрдә дә. Җитештерелгән икмәк ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндермәгән, алтмышынчы еллар уртасыннан алып аны күпләп чит илләрдән сатып ала башлаганнар. Космоска менсәк тә, гап-гади эш коралларын, башка техниканы сыйфатсыз я булмаса зур чыгымнар белән эшләгәнбез. Без бер адым алга атлаганда, башкалар бишне атлаган икән...

## Гасырлар алышынганда

Үзгәртеп кору еллары безнең артталыкны бетерү девизы белән башланса да, чынбарлыкта киресе килеп чыкты. Халык ил өчен дип эшләде, ә менә Кремльдә утырган хакимият, депутатлар үз проблемалары белән мәш килде, юньле-башлы кануннар кабул итә алмыйча гомер сатты. Еллар үтә тора, тик алга китеш һаман да булса сизелми...

1985 елда Катай, Килкабыз һәм Куян авылларын «Яңа Маты» совхозыннан аерып, «Сөн» совхозына берләштерделәр. Яңа совхозның беренче директоры Вәис Галимҗан улы Ахунов булды. Ул эшләгән чорда совхозда шактый гына төзелеш эшләре алып барылды. Аннан соң совхоз белән Рәфкать Мөхәммәткәрам улы Яугилдин, Рәис Сәгъди улы Фәрраховлар җитәкчелек иттеләр. 1990 елдан 2002 елга кадәр авыл советы рәисе булып Вәзир Габбәс улы Нурисламов эшләде (бүгенге көндә Катай урта мәктәбе директоры), аннан соң бу вазифа Галимҗан Фаткылбаян улы Галиевка йөкләнде. Секретарь вазифасын Флүзә Галинур кызы Вәлиева башкара (1985 елдан).

1989 елны халык санын алганда Иске Катайда даими яшәүче 617 кеше теркәлә, шуларның 274 е ир-ат, 343 е хатын-кыз була. Яңа Катайда бу вакытта 615 кеше, шул исәптән 271 ир-ат һәм 344 хатын-кыз яши. Бу саннар авылыбызның кечерәеп калганына ишарәли түгелме?

Кайбер авыллар бетү алдында торганда, шөкер, Катайга андый куркыныч беркайчан да янамады. Матур, иркен йортлар төзелә торды, алар авылның читендә, кайчандыр иген басуы җәйрәп яткан урында да калкып чыкты. Мәчетләре, кибетләре, урта мәктәбе, фельдшерлык-акушерлык пункты, китапханәсе бар аның. Газлаштыру программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә, йортларга «зәңгәр ягулык» килә башлады, монысы халык өчен нинди уңайлык икәнен сөйләп тә торасы юк.

Ил торган саен упкынга тәгәрәгәндә нинди уңышлар булсын кебек. Туксанынчы елларда «Сөн» совхозының икътисади-финанс күрсәткечләре начарайганнан-начарайды. Эшче-хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү торган саен авырлашты, алай гына да түгел – бөтенләй тукталды. Күршеләргә күз салсак, икътисади сазлыкта батмыйча, үз көнен күреп, җай гына эшләп ятучылар бар икән. Димәк, хәлләр бөтенләй өметсез түгел.

«Сөн» совхозында килеп туган хәл күптән түгел район хакимияте башлыгы итеп билгеләнгән Рәмис Маһиян улы Дәүләтовны да борчыды. Эшне тамырдан үзгәртмичә, алга китеш булмаячагы ачык иде. Менә шундый шартларда совхозны таратып, авылларның һәрберсен аерым кооператив итеп үзгәртү

мәсьәләсе көн тәртибенә килеп басты. 1999 елның 25 июнендә Катай житештерү кооперативы оештырылды, аның җитәкчесе итеп Рәис Галимҗан улы Ахунов билгеләнде.

Ахыр чиктә 2002 елда авылның ике ягында аерым хуҗалыклар оештырылды. Беренчесенә (Катай крестьян-фермер хуҗалыгы) җитәкче итеп Наил Ситдыйковны, икенчесенә («Катай» ҖЧЖ) Галим Харисовны билгеләделәр. Җитәкчеләргә, билгеле, җиңел түгел: техника күптәннән искергән, ягулык кыйммәт, салымнар да түлисе. Шулай да, хуҗалыклар булдыра алганча җирләрне эшкәртеп, икмәк үстереп, үзләренең көнен күреп яталар.

Бүгенге көндә авыл алдында килеп туган проблемаларны бергәләп хәл итү сорала. Әйтик, авылның җитештерү базасын ныгыту. Рәсәй хөкүмәтенең бу проблемаларны хәл итәчәге юк. Кооператив җитәкчесе, авыл хакимияте халыкка һәм үзләренә таянсалар гына, иҗади эшләсәләр генә, адәм рәтле юлның табылуы ихтимал. Читтә яшәүче катайлылар да (әйткәнебезчә, алар арасында зур оештыру тәҗрибәсе туплаган җитәкчеләр шактый), авылыбызның киләчәген уйлап, эшне җайга салырга ярдәм итмәсләрме?

Җитештерү базасын ныгыту – бер үк вакытта социаль проблема да. Яшьләребез, ә аларны киләчәгебез дибез, арасында эшсезлек булмас иде. Кайда эшсезлек, билгесезлек, шунда яман күренешләр (эчкечелек, тәртип бозу, олыларны санга сукмау һәм башкалар) өчен җирлек туа түгелме?

Билгеле, тырышкан кеше бу шартларда да, төшенкелеккә бирелмичә, җай гына көн күреп ята. Ул үз хуҗалыгында күп терлек асрый, аның бер өлешен сата, ягъни акчага әйләндерә. Уйлап карыйк, бабаларыбыз да шулай үз көчләре белән яшәгәннәр бит. Төп аерма – аларның җире булган, шуңа күрә алар арасында таза тормышта яшәүчеләр байтак булган (кушымтада бирелгән 1917 елгы хуҗалыклар исемлегенә тагын бер кат күз салыгыз әле).

Җир – муллык чыганагы (карый белеп эшкәртсәң, тәрбияләсәң), киләчәктә, бәлки, аның да хуҗалары булыр. Чын хуҗалар тәрбияләнми торып (совет чоры хакимияте, белгәнебезчә, аларның тамырын корытты, сөргеннәргә сөрде), авыл җиренә җитеш тормыш тиз генә килмәячәк әле.

Авылымның өч гасырлык тарихында нинди генә борылышлар булмасын, кешеләре аның төп байлыгы булып торды. Тырыш, эшчән халкы бар – димәк, киләчәге дә өметле!

Өмет белән, иҗат белән яшә, авылым, бирешмә, бәхетле бул! Син – безнең иң кадерле, иң газиз бишегебез! Ничек кенә яшәсәк тә, кайда гына торсак та, без синнән куәт һәм илһам алып яшибез.

*1999*

*Кушымта*

АВЫЛДАШЛАРЫБЫЗ ГӘЗИТ БИТЛӘРЕНДӘ

## Мәхмүтҗанованы бөтен район белде

Районның матур почмагына урнашкан Катай авылы элек-электән үзенең хезмәт сөючән кешеләре белән данланды. Авылдашлар әле дә традицияләрне күзәтергә, үткәннәр турында яхшы истәлекне сакларга һәм үстерергә тырышалар. Фидакяр хезмәт белән якты эз һәм истәлек калдырган терлекчеләрнең, игенчеләрнең исеме авыл тарихына язылган. Аларның берсе турында сөйлисем килә. Ул – хөрмәтле якташыбыз, танылган терлекче, ике тапкыр Ленин ордены кавалеры, РСФСР Югары Советының VII чакырылыш депутаты Галимә Сабирҗановна Мәхмүтҗанова.

Ул 1939 елның ноябрендә Сабирҗан һәм Бибиҗиһан гаиләсендә көтеп алынган беренче бала булып туа. Әти-әнисенә белем алу насыйп булмый, шуңа күрә дә алар кызларының белемле кеше булуын телиләр һәм аңа «грамоталы, белемле» дигән мәгънәле Галимә исеме кушалар. Әмма аңа иркәләнеп әти-әнисе канаты астында гына үсәргә, теләгән белемен алырга туры килми – Бөек Ватан сугышы башлана. Үсмерләр зурлар белән бертигез эшлиләр. Җәйге лагерьда төн кунарга, караңгы кичкә кадәр калырга туры килгән чаклары була.

«Әлбәттә, яшь вакытта күңел ачарга да теләдек,– дип хәтеренә ала Галимә Сабирҗановна.– Шуңа күрә кичке савымнан соң Килкабыз авылы клубына кичәгә, ә Таш-Елга лагеренда эшләгәндә Әрнәш клубына кинога ашыктык. Безне куркытыр өчен егетләрнең юлга агач аударып куйган һәм шул рәвешле юлны бүлгән чаклары да булды. Кызык һәм күңелле була торган иде. Шимбә өмәләре оештырдык, үзешчән сәнгатьтә катнаштык. Фермада «кызыл почмагы» белән терлекчелек йорты бар иде. Анда листовкалар эленде, йомгаклар белән «Молния»ләр чыгарылды, аңа эштәге уңышлар турында язылды, эшләп җиткермәүләр һәм кимчелекләр «Прожектор»да чагылдырылды. Анда без төшке ашны ашый, көндәлек кирәкле товарлар сатып ала алдык. Иртәнге һәм кичке савым арасында яшь савучылар, терлекчеләр «кызыл почмак»ка радио тыңлаучыларның заявкалары буенча тапшырылган җырларны тыңларга җыелдылар. Безгә мәктәп укучылары да килде – терлекчеләр алдында концерт куйдылар. Укытучылар Әфтәх Арсланов, Зөфәр Гомәров политинформацияләр үткәрделәр. Китапханәче Әлфия Хәйдәрова гәзит-журналларны, китапларны еш алып килде. Танылган кешеләр белән очрашулар, китап укучылар конференцияләре, диспутлар оештырды. Күп чаралар башлангыч комсомол

оешмасы инициативасы белән үткәрелде. Ул чагында мин комсомол оешмасы секретаре идем. Без тату булдык, эшли дә, ял да итә белдек.

Ветеран Сажидә Сәлмәнованы, Гамбәрия Хәбибуллина, Сәфирә Габдрәфыйкова, Рәшидә Галиева, Рүзилә Хәйдәрова, Нәҗибә Кәримова, Фәнәхия Бәдретдинова, Рәзинә Исламова, Бибиданә Рәипова, Рәхимә Харисова, Кифая һәм Рая Ситдыйковаларны, Ягъдә Гайсина, Гөлнәзирә Габдуллина, Фәния Габдерәфыйкованы һәм башка күпләрне зур хөрмәт һәм җылы тойгылар белән исенә төшерә.

Менә ул тагын нәрсәне хәтергә алды. «Көннәрнең берсендә ферма мөдире Р. Усманов миңа Бакалыга барырга кирәклеген әйтте, әмма нәрсәгә икәнлеген аңлатмады. Иртәгәсен Хәбиб Шәкүров белән район үзәгенә киттек. «Сиңа паспорт алачакбыз»,— диде ул. Нигә кирәк ул миңа, дип уйлыйм. Депутат итеп сайларга теләүләре турында хәтта белми идем әле. 1967 елның 12 мартында 783 нче Туймазы сайлау округы буенча мине РСФСР Югары Советы депутаты итеп сайладылар».

Депутатлык бурычлары күп вакытны ала. Ветеранның сүзләре буенча ике очрак – Сөн елгасы аша күпер һәм Катай урта мәктәбе бинасын төзү турында сөйләргә телим. 1959 елда Равил Ислам улы Дәүләтов мәктәп директоры итеп билгеләнә, ә аның тормыш иптәше Рәйсә Һадиевна урыс теле укытучысы булып эшли. Мәктәп берничә иске бинага урнашкан була. Депутат Галимә Сабирҗановна һәм Равил Исламович, кирәкле барлык документларны әзерләп, Мәскәүгә китәләр, анда аның запросы буенча төзелешкә һәм смета төзүгә ризалык бирелә, объектны бишьеллык планына кертәләр.

Бүгенге яшьләр аңлап җиткермәскә мөмкин, мәктәп төзү өчен нигә әле Мәскәүгә барырга кирәк, диярләр. Ул вакытта барлык төзелеш эшләре бары тик ил башкаласында гына хәл ителде. 1970 елда төзелеш башлана, ә 1973 елның маенда ул тантаналы шартларда ачыла. Миңа күп еллар анда эшләргә туры килде, бүгенге көнгә кадәр мәктәп актив тормыш белән яши. Мәхмүтҗанованың аны төзүгә керткән өлешен халык онытмый.

– Равил Исламович белән төзелеш мәсьәләсе буенча Мәскәүгә күп барырга туры килде, төгәл генә әйтә алмыйм, кем инде аны санаган,– ди Галимә Сабирҗановна һәм якты истәлекләре белән бүлешә.– Бар нәрсәгә кытлык булган вакытны күз алдына китерегез, магазиннарда сатып алырга бер нәрсә дә юк. Министрлыкларда эшләр тәмамланганнан соң магазиннарга кердек. Зур чиратларда торып, укучыларга спорт триколары, альбомнар, буяулар һәм башка мәктәп кирәк-яраклары сатып алдык.

Язмы яки көзме икәнлеген төгәл генә хәтерләмим, Туймазыда тимер юл вокзалында безне райком УАЗигы каршы алды. Без барлык әйберләрне багажникка төядек һәм өйгә кайтып киттек. Ул вакытларда Туймазыдан Бакалыга кадәр юл бик начар, асфальт түшәлмәгән иде. Бер мәлне машина әйләнде. Куркуымнан шоферның кулына шундый итеп тотынганмын, көч-хәл белән ычкындырдылар. Ул да курыкты. «Бу хәл турында начальнигыма сөйләмәгез,

зинһар»,– дип үтенде ул. Кая инде әләкләшеп йөрү, исән калуыбызга сөендем. Әйе, төрле хәлләр булды,– дип тынып кала Галимә апа.

Сөн елгасы аша күпернең начар торышта булуы сәбәпле, депутат Мәхмүтҗановага бакалылар исеменнән Бакалы райкомы секретаре М. Ш. Шакирҗанов мөрәҗәгать итә. Галимә Сабирҗановнаның хәстәрлеге белән халык хуҗалыгының мөһим объекты кыска срокта файдалануга тапшырыла. Депутат буларак аңа кешеләр белән күп аралашырга, белемен тулыландыру өчен үз өстендә күп эшләргә туры килә. 1970 елда ул авылдашы Тимергази Ситдыйковка кияүгә чыга. Бер-бер артлы дүрт уллары туа. Декрет ялында һәркайсы белән бер айдан артык утырмый, эшкә чыга – вакыты шундый була. Бар нәрсәдә аңа әнисе ярдәм итә, ул аның зур таянычы була. Әмма тиздән әнисе үлә, ә балаларга күз-колак булырга кирәк. Шунлыктан ул Яңа Маты совхозының Катай дуңгызчылык комплексына эшкә күчә. Анда эш сәгатьле була, ял көннәре бирелә. Фидакяр эшләргә күнеккән Галимә анда да 10 ел дәвамында алдынгы операторлар арасында була, коллективның даны бөтен тирә-якка тарала.

80 нче еллар башында гаилә Чишмә районына күчеп китә. Яңа җирдә Галимә элеккечә кышын фермада, җәен чөгендер плантациясендә эшли. 1995 елда, 41 ел хезмәт стажы туплап, лаеклы ялга чыга. Тормыш иптәше белән ярты гасырга якын бергә яшиләр. Улларын үстерделәр, аякка бастырдылар, өйләндерделәр, хәзер аларның 5 оныгы бар.

Яшь барган саен туган җир, авылдашлар үзенә тарта. Аларның гаиләсе дә берничә ел элек Катай авылында йорт сатып алып, шунда яшәргә кайтты. Йортлары кайчандыр фермага илткән урамда урнашкан. Кайчак, үткәннәрне сагынып, ветеран моңсуланып та аладыр. Сызланулар авыр хезмәте турында еш хәтеренә төшереп тора, куллары, аяклары авырта. Әмма авырлыкларны түземле кичерергә өйрәнгән данлы эшчән моны күрсәтергә теләми, тыныч, тотрыклы тормыштан һәм көнкүрештән шатлык таба, үсеп җиткән балалары, оныклары һәм авылдашлары турында хәстәрлекләр белән яши.

Чишмә районында Галимәгә гаиләсе белән Шанжаровка дигән украин авылында яшәргә туры килә. Күршеләре белән тату булалар, хәзер дә телефон аша сөйләшеп торалар, сәламәтлекләре һәм эшләре белән кызыксыналар, бер-берсенә ярдәм итәргә һәм кәефләрен күтәрергә тырышалар, чөнки безнең буынны интернационалистлар итеп тәрбияләделәр. Шуңа күрә ветеран Украинада барган вакыйгаларга ваемсыз кала алмый. Тик менә аңа җавап табуы гына авыр: шундый хәл ничек килеп чыкты икән?

*Нуризә Ситдыйкова.*
педагогик хезмәт ветераны,
РФның Почетлы гомуми белем бирү хезмәткәре
(Авыл таңнары, 2018 ел, 9 февраль)

# Мәчетле авыл – нурлы авыл

Бакалы районының Катай авылында яшәүче Вил хәзрәт Мофаздалов гәзитебезгә беренче булып шалтыратты. «Сез безнең ничә еллар буе күңелебезне әрнеткән проблеманы күтәреп чыга алдыгыз, рәхмәт сезгә!» – диде. Озакламый Катай авылында мәчет-мәдрәсә ачылу тантанасына да чакырды. Мәчет ачылу тантанасына бара алмасак та, соң булса да уң булсын дип, соңрак бу авылга сәфәр юлландык…

Бакалы районы Катай авылы безне саф, табигый халәте белән каршы алды. Мәчет ачылу тантанасына бөтен тирә-юньнән карты да, яше дә, район үзәгеннән, якын-тирә шәһәрләрдән кунаклар җыелган булган. Тантанада Русия Үзәк Диния нәзарәте вәкиле ахун Рөстәм Абушахмин хәзрәтнең һәм Октябрьский шәһәре «Нуруль-Ислам» мәдрәсәсе ректоры Мәүлимҗан хәзрәт Сибгатуллинның килүе вакыйгага зур дәрәҗә өстәгән.

Мәчетне төзү инициаторы һәм төп төзүче – Катай авылында туып-үскән Түбән Кама шәһәрендә яшәүче Рәзиф Латыйпов, лаеклы әти-әни Зәкиҗан һәм Мәгъсүмә Латыйповларның улы. Мәчет-мәдрәсәгә «Әниләр» исеме бирелгән. Мәчет заманча итеп төзелгән.

– Бу – безнең авылда икенче мәчет инде,– дип бәян итте Вил хәзрәт.– 13 ел элек авылыбызда «Зиннур» мәчете ачылган иде. Анда җомга намазларына 30 лап кеше йөрде. «Зиннур» мәчете халык акчасына төзелә. Рәзиф Зәкиҗан улы икенче мәчет салу турында кайтып киңәшләшкәч, каршы килмиләр. Ике мең кеше яшәгән авыл халкы өчен ике мәчет тоту һич артык булмас.

– Әмма күп авылларда мәчетләр буш тора,– дип күңелендәгене бүлеште Вил хәзрәт.– Имамнар юк. Яшьләргә гаиләне карарга эш хакы кирәк. Хәер акчасына гаилә карый аламыни? Бер 5 мең сум булса да эш хакы түләсәләр, бәлки, ризалашучы табылыр иде. Мәчеткә хезмәт итәр иде. Безнең авылда халык дингә бик теләп бара. Коръән мәҗлесләре үткәреп торалар. Әмма гыйбадәт турында да онытмаска кирәк. Вакытында намазыңны укып, корбаныңны чалдырып, уразаңны тотарга, Коръән белән гамәл кылырга кирәк, димен аларга. Китаплар алып кайтып бушка таратам, үзегез укырга өйрәнегез, димен. Урамда исерек кешеләр күренми. Үткән җомгада мәчеттә 17 кеше булды.

«Зиннур» мәчетенә 6–7 бала йөргән. Көзгелеккә «Әниләр» мәчете-мәдрәсәсендә дә балаларга дин сабаклары укыту турында планлаштыралар.

Вил хәзрәт Мофаздалов гомере буе – 38 ел мәктәптә физика, математика фәненнән укыта. Әнисенең Коръән укуын ишетеп, аңа охшарга тырышып, мулла булам дип түгел, укыйсым, беләсем килә дип Октябрьскийдагы Русия

Ислам университеты филиалына укырга юллана. 2006 елда аны тәмамлый. Бүген аларның бурычы – мәчет-мәдрәсәне буш тотмау, милли-дини йөзебезне саклау, киләчәк буынны ялгыш юлдан саклап, хак динебез Исламны өйрәтү. Пәйгамбәр с.г.в. ирләргә, сез көтүче һәм көтүләрегез өчен җаваплы, ди. Ир кеше Аллаһ каршысында үзе һәм гаилә әһелләре өчен җавап бирәсе булса, мәчет-мәхәллә имамы үзе, гаилә әһелләре һәм мәхәлләсендәге кешеләр өчен дә җавап тотачак.

*Э. Әсәдуллина*

(«Өмет» гәзите, 2015 ел, № 47 (2857)).





## Әгъләм Күчемов 80 яшендә дә сафта

Ветераннар арасында спорт йөреше буенча 9 тапкыр (!) дөнья, 27 тапкыр (!) Русия чемпионы, 4 тапкыр Русия һәм Дөнья рекордсмены, 2 тапкыр Русия кубогына ия булучы, Дөнья һәм Русия ветераннары арасында уеннарда, Нью-Йоркта, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Минскида һәм Саранскида үткәрелгән Халыкара ярышлар җиңүчесе, СССРның спорт мастеры, «Русия спортының почетлы ветераны», «Башкортстанның атказанган спорт эшлеклесе», Салават Юлаев орденына лаек Әгъләм Җәмгыйтдин улы Күчемов яңа ел алдыннан үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләде.

Шундый олы яшьтә булса да Ә. Җ. Күчемов вакыйгалар уртасында, җәмгыятькә файдалы, сафта булырга тырыша. Район, кече туган иле белән элемтәсен өзми. Танылган спортчының инициативасы буенча Катай мәктәбендә узган зур спорт бәйрәме – шуның дәлиле.



Чара башлану алдыннан мәктәп директоры В. Г. Нурисламов укучыларны кунаклар белән таныштырды. Алар арасында районның спорт комитеты рәисе, СССРның спорт мастеры, авыр атлетика буенча Русия һәм Дөнья чемпионы П. Л. Лобанов, комитет белгечләре булды. Павел Леонидович Ә. Җ. Күчемовның районга гына түгел, бәлки республиканың да спорт үсешенә өлеш керткән кеше булуын билгеләде. Үзенең 80 яшендә дә яшь буын өчен үрнәк булып тора. Балаларның аңа тиңләшүен һәм киләчәктә чемпион булырга тырышуларын теләде.

Әгълә Күчемов үзе чараның Катай мәктәбендә спортның үсешенә булышлык итәчәгенә, катнашучыларга шатлык китерәчәгенә, һәр премия һәм җиңү тир түгеп алынуы белән хәтердә калачагына ышаныч белдерде.

Аннан соң балалар спорт йөреше буенча дөнья чемпионы Ә. Җ. Күчемов призына җиңел атлетика кроссы үткәрелү урынына киттеләр. Кроссta беренче сыйныфтан 9 сыйныфка кадәрге бар укучылар да катнашты. Бу көнне бер генә укучы да, бер генә укытучы да бүләксез калмады: Әгълә Җәмгыйтдин улы һәркемгә автографы белән истәлекле календарьлар, кросс турында истәлеккә вымпеллар тапшырды. Җиңүчеләр дә, призчылар да, акчалата премиядән тыш, Мактау грамоталары, алтын, көмеш һәм бронза медальләр белән бүләкләнделәр. «Әгълә планета буйлап атлый» китабы матур бүләк булды. Кем белә, бәлки, укучылар арасында китап героеның үрнәгенә иярүче һәм спортта югары үрләргә ирешүчеләр табылыр.

Балаларны спортка җәлеп итү эше, спортны үстерүдәге өлеше өчен танылган спортчы мәктәп директоры В. Г. Нурисламовка зур кубок һәм мәктәпнең җыелма командасына спорт формасы комплектлары тапшырды.

Тантаналы өлеш тәмамланганнан соң кросста җиңүчеләр һәм призчылар өчен ул мастер-класс үткәрде, аерым укучыларга файдалы киңәшләр бирде. Ак сакаллы спорт ветеранының яшьләрчә җиңел, җитез хәрәкәтле адымнарын балалар да, олылар да сокланып күзәтте. Чара өч сәгатькә якын дәвам итте.

Павел Лобанов район хакимияте исеменнән оештыручыларга, кросста катнашучыларга рәхмәт әйтте, укучыларга уңышлар, максатка омтылучанлык теләде. Билгеләнгән дистанцияләрнең җиңел булмавына карамастан, барлык укучылар яхшы әзерлекләрен күрсәттеләр. Үз чиратында, Ә. Җ. Күчемов, мәктәп директоры В. Г. Нурисламов район хакимиятенә, спорт бәйрәмендә катнашучыларга рәхмәт белдерделәр, сәламәтлек һәм спорт белән ныграк дус булырга өндәделәр.

## Кросста җиңүчеләрнең тәэссоратлары:

Д. Урунов, 9 сыйныф укучысы:

Бу күңелле һәм файдалы зур спорт бәйрәме булды. Ярышта 3 километрга йөгердек, яшьтәшләрем арасында беренче урынны алдым, мине Әгълә Җәмгыйтдин улы шәхсән үзе котлады, зур премия тапшырды. Изге күңеллелеге һәм юмартлыгы өчен аңа зур рәхмәт әйтәсем килә. Уңышлар телим.

А. Хафизова, Э. Вәлиева, 7 сыйныф укучылары:

Без дә кросста катнаштык. Ул җылы, ярыш үткәрү өчен матур көн иде. Икенче төркемдә йөгердек. Бик кыен булса да, икебез дә призлы урыннар алдык. Ярышлардан соң Ә. Җ. Кучемов мәктәпнең спорт залында спорт йөреше буенча осталык дәресе үткәрде. Без спортның бу төрендә үзебезне сынап карадык, барысы ошады. Әгълә Җәмгыйтдин улы Эмманы хәтта мактады. Вакыт табып безгә килгәне һәм бик яхшы бәйрәм үткәргәне өчен аңа рәхмәтлебез.

*Ленизa Габдуллина,*
Иске Катай мәктәбе укытучысы
(«Авыл таңнары», 2018 ел, 30 гыйнвар)

# «Очу җене» кагылган авыл

Һәр төбәкнең, һәр авылның аңа гына хас үзенчәлекләре була, халкы исә башка җирдәгеләрдән нәрсәсе беләндер аерылып тора.

Бу авыл халкы элек-электән бер-берсеннән көнләшеп дөнья көтүе, үҗәтлеге белән беррәттән, шаянлыгы, җор сүзлелеге белән дан тоткан, аның тарихында кызыклы вакыйгалар буа буарлык, аларның күбесе көләмәчкә әйләнгән хәтта. Ә менә аның очарга булган теләге башкалардан тагын да ныграк аерып торучы бер ягыдыр.

Моннан өч-дүрт дистә еллар элек дөнья куйган, империалистик сугыш ветераны күрше Сабир бабайны «яраплан Сабир» дип йөртәләр иде. Шул сугыш чорында ярапланга утырып, аякларын салындырып авыл өстеннән үтеп киткәнен сөйләгәне хәтеремдә. Ә без, балалар, аңа чын күңелдән ышанып, авыз ачып тыңлый торган идек. Үсә төшкәч кенә аның бу сөйләгәннәренен хыял икәненә төшендек. Димәк, ул күңеле белән күктә очып йөргән булган...

Очуга бәйле тагын бер вакыйганы әткәй-әнкәйләрнең сөйләгәне истә. Монысы үткән гасырның 20 нче елларында булган вакыйга. Таҗетдин атлы кеше кулларына кабыктан канатлар ясый да Гыйлемхан исемле үсмерне аркасына атландырып, лапас түбәсеннән очып китмәкче була. Гыйлемханы исә «Таҗи абзый, Кирәмәт тавына бәрелмәбез микән?», дип, борчуга да калган ди. Тик кайда Кирәмәткә җитү, шунда ук җиргә егылып төшәләр. Авылдашыбыз, техник фәннәр кандидаты Роберт абый Мофаззаловның Маты елгасының Ачы дип аталып йөртелүче үзәненә вертолетка утырып әнисенә, өлкән укытучыбыз Галимә апага кайтып төшкәненә күп тапкырлар шаһит булырга туры килде. Бигрәк тә малай-шалай өчен бәйрәм була иде андый мәлләр: барысы да вертолетны якыннан күреп калыр өчен шунда йөгерә торган иде. Аларның кайсысы гына күккә күтәрелергә хыялланмагандыр?!

Авыл малайларының да, шулай ук үзенең дә балачак хыялын тормышка ашырган Нәфис Кучемов үз куллары белән эшләгән дельталетларында инде ничәнче ел күккә күтәрелә. Әнисе Зәкия апа аңа курага кайтмый йөрүче бозауларын эзләргә куша торган була, сәгатьләр буена тыңлаусыз малны эзләп йончыган малай «их, күккә күтәрелеп, бозауның кайдалыгын тиз генә күрергә иде», дип хыялланган. Менә шул мәлдән бирле бала күңелендә очкыч ясау теләге уяна да инде.

Күккә иң беренче адымын ул 1996 елда үзе эшләгән беренче очкычында ясый. Шул көннән бирле күпме очкычлар эшләнгән, һәм күккә ничә тапкыр ашкандыр – исәбенә чыгарлык түгел: сабантуйларында күрсәткеч очыш-



лар, күрше Татарстан басуларына ашлама сиптерү, күңел күккә тартылганда штурвал артына утыру... Авыл малайлары исә аның пассажирлары булган.

Нәфис Гавис улы Күчемов – Башкортстан республикасы җиңел авиация берләшкән федерациясенең региональ бүлекчәсендә җәмгыять оешмасы әгъзасы, җиңел очкычларны сынаучы-очучы. Аңа кагылган «очу җене» авыл малайларына да күчкән. Очучының дельталеты урнашкан зур бина һәм очу юлында еш урала бала-чага. Нәфис абыйларының дөнья мәшәкатьләреннән бушаган һәм күңеленең гомерлек чире булган очкычы янына килгән чакларын түземсезлек белән көтә алар. Малайлар остазлары җитәкчелегендә очу эшенә өйрәнә, җиһан киңлекләренә беренче адымнарын атларга җыена. Кем белә, бәлки, киләчәктә Катай авылыннан билгеле конструкторлар, очучылар чыгар...

Ә бит бу шөгыль Нәфис Гавис улына бернинди дә матди ярдәм бирми, бары тик күңел өчен генә. Ә һәр ясаган корылма шәхси вакыт белән бергә шактый чыгымнар да таләп итә бит.

Шушы ук авылда туып-үскән, бәләкәйдән үк, нигә кешеләр дә кошлар шикелле очмый икән, дигән сорауларга җавап эзләгән, авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң Чиләбедәге радиотехник мәктәптә шөгыльләнеп үзенең киләчәк авиатехник һөнәренә өйрәнә башлаган, 40 елга якын гомерен авиациягә багышлаган ике туган абыйсы Рифкать Күчемов та аның бу шөгыленә йогынты



ясамый калмагандыр, мөгаен. Нәфис энесенең уңышлары аны шатландыра. «Катай Жуковскийы», талантлы конструктор, дип бәяли ул аны.

– Бар нәрсәне өстән күрү – зур бәхет,– ди Рифкать Әсләм улы,– һаваны беренче тапкыр тою – тәүге мәхәббәт шикелле, үзеңне кош итеп хис итәсең...

Шул арада Нәфис әфәнде үзенең очкычында күккә күтәрелде, ә без аны җирдән кызыгып та, сокланып та күзәттек. Кызыгырлык та шул, «яраплан Сабир» бабайның да, кабык канатлар белән Кирәмәт тауларыннан югарырак очарга теләгән Таҗетдин белән Гыйлемхан агаларының да хыялларын тормышка ашырган кеше иде авыл күгендә...

*Хәбибә Гәрәй*
(«Сәлам» гәзите, 2010 ел, сентябрь)

# Кирәмәткә менгән идем

Кирәмәткә менеп, еракларга җәйрәп яткан авылыбызга сокланып карап тору үзе ни тора! Кирәмәт – безнең балачакның аерылгысыз өлеше, Катайның истәлекле урыны. Балачакта чакматаш эзләп ыштаннарны ерта-ерта шунда менгәли идек. Анда менүнең ансатрак юллары да бар, әмма безне анысы кызыктырмый иде. Безгә үз көчебез белән, тирләп-пешеп, тезләрне-кулларны канатып менү кирәк!

Чакматаш бары тик шунда гына була иде, ул өелеп ятмый, аны башта эзләп табасың, ул кечкенә дә, артык зур да булырга тиеш түгел. Тезләнеп утырып, үзең белән алып килгән мамыкны чыгарып, чакматашны бер-берсенә ышкып очкын чыгарып, шуны мамыкка юнәлтәсең. Борынгы кешеләрнең шырпылары булмаган, шырпы урынына чакматаш кулланганнар дип әйтә иде картлар. Әнә без дә шул борынгы кешеләр, имеш, шуларга охшарга тырышып чакматаш белән тәҗрибә ясаучылар. Әмма күпме тырышып та, бармакларны канатып та мамыкка ут кабыза алмагач, үзебезнең нәтиҗәсез азапланууларыбызга эчебез поша иде. Кара инде, мамыкка да ут кабыза алма, имеш. Борынгы кешеләрнең мамыгы да булмаган бит, алар каен тузын файдаланганнар, алай авыррак та әле. Ә без нинди булдыксыз!

Чакматаш кәефне кырса да, без бөтенләй үк булдыксыз түгел әле. Төшкәндә тауның текә урынын сайлап төшә идек. Монда инде бик сак төшәргә кирәк, егылырга ярамый, егылсаң беттең, шуңа һәр адым саен аяк астын карыйсың. Шулай тирләп-пешеп, зур стресслар кичереп төшеп җиткәндә, чакматаш белән булган уңышсыз тәҗрибә инде онытылган, син үзеңне дөньяның иң көчле кешеләреннән берсе итеп тоясың. Кабат өскә карыйсың да, кара нинди биек таудан, аның нинди текә урыныннан төшкәнсең дип үз-үзеңә сокланасың. Безнең кебек болай һәркем төшә алмый, кыз-кыркыннарны әйтәсе дә юк.

Соңыннан белдек, борынгы кешеләр безнең кебек чакматаш белән азапланмас өчен ут саклаганнар. Әле сугышка чаклы шырпы дефицит чорда да, чират белән ут саклаганнар. Ут тергезергә кирәк булса, утлы күмер кисәген чираттагы ут саклаучыга барып алганнар. Менә шулай әмәлен тапканнар.

Без үскәндә шырпыга кытлык булмады, әмма шул заманнарны истә тотып аны күпләп алып куялар иде. Килер бер вакыт, шырпының да бөтенләй кирәге калмас, ул да чакматаш кебек бер истәлек булып калыр. Тик заманалар ничек





кенә үзгәрмәсен, безнең Кирәмәт тавы мәңге булачак, мәңге яшәячәк. Дистәгә якын буын бабаларыбызның, бүгенге чорыбызның тере шаһиты кебек Кирәмәт тавы яшәгәндә безнең күп гасырлык тарихыбыз да яшәячәк!

*27 гыйнвар, 2017 ел*

## Казыяр ташыса әгәр

1960 елның март ахыры-апрель башларында Казыяр елгасыннан искитмәле зур бозлар аккан, елганың шаулап акканы әллә кайларга хәтле ишетелеп торган. Су шул кадәрле күп аккан диләр, хәтта Бакалыга бара торган юлдагы күпер аша бөтенләй чыкмаслык булган. Ул вакытта күпере дә хәзергесе кебек биек булмаган, язгы ташулар аның ныклыгын киметә, таушалта торган булган.

Ат җигеп, әнием белән Бакалыга бәби тудыру йортына барырга чыккан әтием кире борылып кайтырга мәҗбүр булган. Менә шулай Ходайның хәер-фатихасы белән 1 апрель көнне Катайда мин дөньяга килгәнмен.

Шул күпер белән бәйле тагын бер истәлек бар әле. 60 нчы еллар уртасымы-ахырынаракмы күпер алдыннанрак елганы буып куялар. Искесен сүтеп яңасын, хәзергесен сала башлаганнардыр инде. Казыяр елгасы ярларыннан чыга, шул тирәдәге кешеләрнең бакчаларына үрмәли, зур диңгезгә әйләнә. Безгә бу искитмәле кызык тамаша иде, хәзерге кебек буалар юк иде ул заманда, шуңадыр да зур суларны күрмәгән балаларга диңгез булып тоелгандыр. Ә диңгездә корабларда йөзәргә була.

Кемнеке булгандыр ул «кораб», әмма Әлфия апам белән икебез сыярлык иде. Эче куыш юан бүрәнә иде ул, аны йөзәр өченме, башка максаттанмы эчен юганнар, аннары шактый кулланыпмы, тик ятыпмы тузгач ташлаганнар, тыкрыкка якынрак җирдә тирес-чүплекләр тирәсендәрәк чайкалып ята иде ул. Әлфия апам миннән биш яшькә зуррак, ул ишеп бара. Инде суның уртасына җиттек дигәндә, карыйм, суда бер күбәләк чәбәләнеп ята. Кулымны сузуым булды, көймәбез әйләнде дә китте.

Кая инде ул яшьтә йөзә белү сабый балага. Беттек дигән уй йөгереп узганмы баштан, анысы истә түгел, әмма бик курыкканымны хәтерлим. Сөннәтче бабайдан качып, бакчада бәрәңге куаклары артында яшеренеп яткандагы курку халәтеннән дә зуррак курку иде бу.

Ярый, бөтенләй үк каушап калмаганмын, чытырдатып ябышканмын көймәгә. Апам үзе генә ишкәнме, мин дә ярдәм иткәнменме, анысын хәтерләмим, көч-хәл белән чыкканбыз Кәшбел абзыйлар тыкрыгы тирәсенә.

Язгы ташуларда Казыяр суы кодрәте аркасында мин Катайда (Бакалыда түгел!), ата-бабалар гомер иткән авылымда дөньяга килгәнмен. Бу сабый халкына, аның тарихына хезмәт итсен диптерме, Казыяр суы үзенә тартып алмаган, киресенчә, зур бәладән котылырлык көч-кодрәт биргән кебек тоела миңа. Безнең өчен диңгезгә тиң булган Казыяр елгасы буенда үткән күңелле балачак истәлекләре әле дә көч-кодрәт, яшәү дәрте бирә миңа!

*28 гыйнвар, 2017 ел*

# Кар сулары акканда

Яз минем өчен елның иң күңелле фасылларыннан берсе. Кышка керсәм, язны көтеп яшим. Беренче апрельне, туган көнен көтә дип уйламагыз тагын, язның минем өчен башка күркәм яклары да бар, шуларның берсе – яз балачак истәлекләрен яктыртып җибәрә.

Балачак дигәннән, иң беренче күңелгә язгы гөрләвекләрдә кәгазьдән көймәләр агызып уйнау искә төшә. Капка төбеннән агызып җибәрәсең дә, артыннан карап барасың, юлында боз-йомычка кебек тоткарлыклар булса, алып ташлыйсың. Шулай юл сала-сала Кыям абзыйлар почмагына кадәр җитәсең, бу – ике йөз метрлап ара. Шуннан да ерак агызып булмый башта, Мәрфуга әбиләр тирәсендә кар калынрак яткан, су яңа гына чыгып килгән була.

Бер заманны сәгатьләп диярлек Мәрфуга әбиләр тирәсе дә кардан арына башлый, син һаман көймәләр җибәрәсең, тик алар артыннан карап барып булмый, аяк асты пычранган, итеккә ләм иярә, сине оекбашка чаклы юешләрлек чокырлар да бар. Менә шунда инде хыялларга биреләсең, син җибәргән көймәләр Маты елгасына чаклы җиттеме икән. Маты елгасы диңгезләргә чаклы акса, синең көймәләрең дә зур юл үтә, кемнәрдер аларны күрә, сәламли, тик кем агызып җибәргәнен генә белми. Белсеннәр өчен мин көймәләргә исемемне яза башладым.

Икенче зур истәлек – язга чыккач өй юулар. Өйне мин юмыйм, әнием һәм өч кыз туганым юа, минем бурыч – аларга су ташып тору. Ул бары тик кар сулары белән генә юыла. Чиста кар сулары кайда күп ятканын, басуга якынрак чиләк тыгып алырлык чокырларны мин генә беләм. Иртәнгә ул чокырлар юка боз белән капланган була, аларны ватасың да, чиләк сыярлык булса чиләк белән, чиләк сыярлык булмаса чүмеч белән су җыя башлыйсың. Аны кайтарып бирәсең дә, тагын киләсең. Шулай берничә тапкыр юл үткәч, шактый арыган буласың, ул вакытка өй дә юылып беткән була.

Юылган, сафланып калган өйнең исләре! Әни мичтә пешергән көлчәне ашый-ашый шактый әсәрләнеп, хозурланып йөрисең, әле бөтен әйберләр дә урнаштырылып бетмәгән, өйдәге тавышлар да яңгырабрак тора. Шул ук көнне чаршау-пәрдәләр дә юыла, кичкә таба алары да үз урынына элеп куела, тәмам арып, җилләтелгән-кагылган урын-җиргә менеп яту белән, изрәп, төшләр күреп йокыга да китәсең.

Күп алар, язгы истәлекләр, әмма болары күңелнең иң түрендә урын алганнары, аеруча кадерлеләре.



**Студент елларында дустым Рәфикъ Мөхәммәдиев белән үзебезнең университет каршында**

Үсә төшкәч көймәләр агызу бетте, шулай да язгы гөрләвекләргә карап озаклап басып тора идем. Хәзер шуны уйлыйм, гөрләвекләр кебек гомерләребез дә ага, диңгезгә булмаса да, кайсыдыр чикләргә таба бара түгелме? Тик һәр яз алып килгән дәрт һәм илһам күңелсез уйлардан арындыра, яңа юылган өй кебек күңелләр дә чистарынып-яктырып китә. Язларны көтеп яшик, дусларым, авылдашларым!

*29 гыйнвар, 2017 ел*

# Зур тормышка аяк басканда



1977 елда мин Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга кердем, тарихчы булырга. Мәктәптә укыганда шул университет ишекләрен ачып керермен дип башка да китерми идем, кая инде мәшһүр Ленин исеме белән бәйле уку йорты минем өчен, анда бик сәләтлеләр генә укый ала иде кебек. Ә миндә кайда инде андый сәләт, бөтенесе шул тырышлык аркасында. Башкаларныкы кебек хәтер дә әйбәт түгел, кемдер шунда ук отып алганны, мин көч куеп, ятлап-кабатлап истә калдыра идем.

Әле соңгы кыңгырау тавышлары яңгыраганда да мин үземнең кая барасымны белми идем. Бары тик шуны белә идем – кая укырга барсам да, мин сайлаган профессия гуманитар фәннәр белән генә бәйле булырга тиеш. Аттестатта «4» ле булса да, математиканы белеп бетерми идем, ә менә тарих, татар әдәбияты һәм теле, урыс теле һәм әдәбияты минем «5» легә генә укыган фәннәрем иде. Урыс теленнән аттестатка «4» ле куйдылар, анысына укытучыма үпкәләдем дә бугай әле, гел «5» кә укып йөр дә соңгы мәлдә «4» ал, имеш. Аттестатта «4» билгеләре дүртәү иде, ә болай өчәү генә буласы иде.

Кая барасымны белмәгән шул вакытта Казаннан Зөлфия апам кайтып төште. Апам – минем горурлыгым, мин аңа соклана идем. Гел «5»легә генә диярлек укый, район ярышларында йөгерү буенча Катай данын да яклый, призлы урыннар ала, район гәзитенә язмалар да биргәли иде. Авылдан берүзе чыгып китеп, бернинди ярдәмсез-«блатсыз» әллә кайдагы Казанга, андагы мәдәният институтына барып керүе белән мине шаккаттырды, күз алдымда дәрәҗәсен иң югары баскычка күтәрде дә куйды ул.

Апамның беренче сүзе шул булды: кая укырга барасың? Белмим, дидем. Мине шаккаттырып, Казан университетына укырга барасың, димәсенме апам. Мин шүрли төштем: кая инде анда миңа укырга, башта имтиханнарны биреп конкурсны да үтәргә кирәк бит әле аның өчен! Юк, диде апам, анда синең кебекләр укый, тырышсаң син дә булдыра аласың. Ә тырышлык бар анысы миндә, максат куям икән, шул максатка ирешкәнче тырышам, барыбер үземнекен итәм. Соңрак гороскоплар модага кергәч әйттеләр үземә, син кучкар (овен), кучкарлар барысы да шулай, имеш. Монда күпмедер дөреслек булса



да, нәсел күзәнәкләренә Ходай салган зиһен һәм башкасыннан чыгып фикер йөртергә кирәктер.

Мин Казан университетында укыячакмын! Апам белән сөйләшүдән соң мин шактый әсәренеп, үземне кая куярга белмичә йөрдем. Анда укып йөрүемне күз алдына да китереп карадым, юк, берничек тә барып чыкмый. Уйлап-уйлап йөрдем дә, шундый фикергә килдем: ә шулай да, имтиханнарга ныклап әзерләнсәм, аларны «4»лелек булса да бирсәм, бәлки, андагы зур конкурстан да үтә алырмын.

Миңа барыбер укырга керергә кирәк иде. Тырышып карыйм, имтиханнарга ныклап әзерләним. Шул фикергә килдем дә, китап-дәфтәрләремне алып яңа салынган, нарат бүрәнәләрдән сагызлары бүселеп чыккан, әле сафлык бөркелеп торган мунчага кереп бикләндем. Казанга киткәнче моннан ашарга-йокларга гына чыга идем. Кичке сәфәрләргә чакырган классташларыма ияреп кич тә чыкмадым, алар үпкәләделәр дә әле. Минем башта бары тик бер генә уй: укырга да укырга, уеннары да, башкасы да соңыннан. Тарих дәреслекләрен укып чыктым да, урыс әдәбиятына тотындым, аннары нимес теле буенча кагыйдәләрне яңабаштан карап чыктым, шул телдә диалоглар әйтеп карадым. Мунчада зур, сихри тормыш бара иде, истә калырлык булсын өчен кайбер текстларны кычкырып укыйм, укыганнарың тышка чаклы яңгырап тора иде, дип әйтә торган иде әнием. Ул эчтән генә хуплый иде кебек, башыңа-күзеңә көч килмәсен дип әйтми, соңрак, галим булып киткәч кенә әйтә торган иде ул сүзләрне.

Инде Казанга китәр вакыт та җитте. Мин башны белем, тарих дәреслекләрендәге даталар белән тутырган, ятласыларын ятлаган, үземдә имтихан кебек киртәләрне җиңәрлек көч тоя башлаган идем. Казанга баргач дәрес-



лекләрне тагын бер карап, хәтердән йөгертеп чыгарга иде ният. Булырга тиеш, аннан кайтсам, бары тик студент булып кайтырга!

Поездда озын юл үтеп, документларны тапшырып тулай торакка урнашкач, мин кабат дәреслекләргә ябыштым. Монда читенрәк: бүлмәдәшләрнең берсе грек Рома, икенчесе әзербайҗан Ислам – Грузиядән юридик факультетка укырга керергә килгән шаян егетләр иде. Икесен дә бик яраттым, әмма, «әйдә, безнең белән тегендә чыгып керәбез, монда барып киләбез» дип чакырганнарына һәрвакыт «юк» дип җавап бирә идем. Алда катлаулы, хәлиткеч имтиханнар торганда, ничек итеп күңел ачып йөрим инде. Укырга керергә дип килгәннәр, ә үзләре дәреслекләрне тотып карамый түгелме болар?

Бу егетләр гел күз алдында йөргәндә имтиханга әзерләнү читен иде, шулай да җаен таптым. Тулай торак каршында куаклардан, вак-төяк агачлардан торган урын бар иде. Җәй җылы, шунда кереп утырсаң, сине бер кем дә күрми дә, комачаулаучы да юк. Шул куаклык-агачлар арасында тарихтан имтиханга әзерләнеп утырганда, бер кочак Ленин хезмәтләрен күтәреп Зөлфия апам килеп җитте. «Укы, имтиханда Ленин әсәрләрен сорыйлар, вакытыңны алмыйм»,– дип уңышлар теләп тиз генә китеп тә барды. Тарих дәреслекләрен карап чыккан идем, тотындым юлбашчыбыз хезмәтләрен өйрәнергә-ятларга. Кайчан язылганнарын да истә калдырырга тырыштым.

И рәхмәтләр укыдым да апама тарихтан имтихан биргәндә! Өстәмә сорауны Ленинның «Герцен истәлегенә» («Памяти Герцена») әсәре буенча бирделәр. Бу хезмәтне мин биш бармагым кебек белә идем, сөйләп бирдем, Ленин кайчан язган дип сорадылар, анысына да төгәл җавап бирдем. Кайдан килдең дип сорадылар, әллә шаккатыпмы, әллә бу балага кайда мондый тирән белем




биргәннәрен беләселәре килепме. Үзем эчтән уйлыйм, болар бик канәгать калдылар бит, «5»ле куярлар әле. Һәм, чынлап та, беренче имтиханны мин «5» легә бирдем!

Беренче имтиханнан югары билге алу миңа канат куйды, инде башкаларын да яхшы бирергә кирәк. Алары «5» легә булмады, әмма барысы да «4»ле иде. Бер урынга биш кеше туры килгән конкурстан үтәчәгемә шигем бик үк булмаса да, күңел барыбер тыныч түгел иде әле. Авылны, өйдәгеләрне сагынган идем, комиссия укырга кабул итү турында карар чыгарганны көтмичә, кайттым да киттем. Киткәндә бүлмәдәш дустым Ромага әйтеп калдырдым, үзеңнеке белән бергә минекен дә кара, укырга кергәннәр исемлегендә булсам телеграмма бир, дип. 24 август көнне почтальон Казаннан телеграмма китерде. Шатлыкның чиге юк: мин Казан дәүләт университеты студенты!!! Алда мине зур тормыш, студент еллары көтә!!!

Менә шулай зур тормышка беренче адымымны ясадым. Ул адым уңышлы, мин теләгәнчә булсын өчен күпме көч куярга туры килде. Тормышта имтиханнар күп, кайберләре кабул итү имтиханнарыннан да авыррак, әле хәтәррәк тә булачак. Әмма бу тәүге хәлиткеч имтихан, борынгыларның «тырышкан – ташка кадак каккан» дигән әйтемен раслап, якты вә рухландыргыч бер истәлек булып калачак.

*31 гыйнвар, 2017 ел*

## *Ветераннар арабызда чакта*



**Алгы рәттә (сулдан уңга): Яугилдин Әнгам, Бәдретдинов Зәкиулла, Сәрвәров Зыязетдин, Садыйков Мәүфәт; артта: Ситдыйков Кыям, Йосыпов Атлас (өченче)**



**Сулдан уңга: Нәбиев Заһит, Бәдретдинов Тәкыйулла, Фәрвазов Мәгъдәнур, Әхмәтов Кәшбелгали, Шәмсетдинов Галимҗан, Саяда һәм Кыям Ситдыйковлар, Гомәров Хәмидулла. 1995 ел**



**Ветераннар белән мәктәптә очрашу**



**Сулдан уңга: Шәяхмәтов Шәйхезаман, Саяпов Әнвәр, Дәүләтов Тимерҗан, Мифтахов Мөдәррис**



**Алгы рәттә (сулдан уңга): Саяпова Сания, Латыйпов Әхнәф, Исламов Шәмсегали, Солтанов Әбүнәгыйм; артта: Саяпов Әнвәр, Галиев Галимҗан, Бәдретдинов Зәкиулла. 2005 ел**



**Алгы рәттә (сулдан уңга): Саяпов Әнвәр, Мифтахов Мөдәррис, Исламов Шәмсегали, Бәдретдинов Зәкиулла, Әхмәтханов Рәеф, Нәбиев Заһит; артта: Вәлиева Флүзә, Якупова Зәйтүнә, Солтанов Әбүнәгыйм, Шәяхмәтов Шәйхезаман, Фәрвазов Мәгъдәнур, Әхмәтов Кәшбел, Шәрәфетдинов Әслах, Хафизов Әхнәф, Бакиров Сибагать, Маликов Хәмит, Нурисламов Вәзир**

*Хезмәтенә күрә – хөрмәт һәм орденнар*


Галимә Мәхмүтҗанова


Гамбәрия Хәбибуллина


Мәсхудә Шәйдуллина


Нажих Вәлиев


Рифгать Госманов


Әсгать Кәлимуллин



Тутыя Гәрәева



Сәфирә Габдрахимова



Фәнәдия Харисова



Гөлсинә Шәйхразыева



Әнүзә Якупова

## *Олы тормышка юл мәктәптән башлана*




**Катай урта мәктәбенең 2 нче чыгарылышы. 1969 ел, 5 июль**



**Р.Җ. Хәсәнов җитәкчелегендәге Катай мәктәбе хоры. 1970 еллар башы**



**Катай урта мәктәбенең 10 нчы чыгарылыш укучылары һәм бер төркем укытучылар. Алгы планда (утырганнар): Җәләева Ф.Ә., Хәсәнов Р.Җ., Хәсәнова Р.Г., директор Дәүләтов Р.И., Садыйков М.Н., Нуретдинова Б., Фәттахова З.Х., авыл советы рәисе Хәйдәрова Ә.Х., Шәйхуллин М.М., Яугильдин Ә.Г. 1977 ел**




**Катай урта мәктәбенең 11 нче чыгарылышы. 1978 ел**



**Укытучылар коллективы. Алгы рәттә (сулдан уңга): Галиев Т.Ф., Махиянова Г.Р., директор Нурисламов В.Г., Рәхимова З.А., Садыйкова З.Р.; артта: Нурисламова Л.Ф., Габделгалиева А.Р., Галина А.Х., Күчемова И.А., Күчемов Ф.Ф., Хөснетдинова Р.К., Фәхруллина З.Р. 2018 ел, март**



**Бүген безнең бәйрәм. 2012 ел, 25 май**



**Ветеран-спортчы Әгъләм Күчемов (артта) белән**



**«Ажаган» уены. 2012 ел, февраль**

*Күңелле дә соң Сабантуйлары!*




**Классташлар Рәшит, Зилара, Ришат һәм Таһир. 2017 ел**



**Ринат Нәбиев, Нуризә һәм Наил Ситдыйковлар, Таһир Кәрим. 2017 ел**



**Фиркать белән Роберт Бакалы Сабантуенда. 2017 ел**



**Таһир Кәрим, Рәмис Дәүләтов, Илдар Нурлы, Римма Күчемова Бакалы Сабантуенда. 2017 ел**

## *Бергә җыелган чакта*



**Минем гаиләм**




**Җизнәбез Коля белән Әлфия апа Дамирда кунакта. 2007 ел**




**Зөлфия һәм Галиәсгар Мәмәтовлар, автор, Зөлфирә һәм Фәнәвис Вәлиевлар Бакалы Сабантуенда. 2013 ел**



**Түбән Кама районының Ташлык авылында беренче китабым презентациясе көне. Артта җырчы Фән Вәлиәхмәтов, язучылар Разил Вәлиев, Фәнзаман Баттал, Таһир Кәрим. 2000 ел, май**



**Икетуган апабыз Һалә Ярмөхәммәт кызы Хафизова. 2018 ел, март**





**Венера һәм Дамир Кәримовлар, балалары Булат, Эльвира. 2018 ел, март**



«Илһам» Бөтенроссия яшь язучылар бәйгесен оештыручыларның берсе, Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы хезмәткәре Рүзәл Таһир улы Кәримов (сулдан икенче) профессор Васил Гарифуллин, язучылар Гөлзада Бәйрәмова, Ләбиб Лерон белән. Арча, 2018 ел, 3 апрель



Сабакташлар белән үзебезнең университет каршында очрашу. Казан, 2017 ел, июль



Казыяр буасы. 2017 ел, 12 июнь



Туган нигез. 2010 ел, 9 октябрь

## Мин ничек төбәк тарихчысы булып киттем

1992 елның көзендә мин үзем укыган Казан дәүләт университетында тарих фәне буенча кандидатлык диссертациясе якладым. Диссертация яклаганчы ук мин туган ягым тарихын ныклап өйрәнергә дигән карарга килгән, Уфа архивларына йөри башлаган идем. 1993 елның җәенә туган авылым һәм Бакалы төбәге тарихына кагылышлы шактый архив документларын караган идем. Җәйге ялга Катайга кайткач, өстәмә документлар ачыклар өчен Уфа архивына барып килдем дә, тыныч урында – өебезнең җәйге бүлмәсендә (верандасында) Катай тарихын язарга утырдым. Язган әйберләремне заманында Татарстан китап нәшриятының иң яхшы корректоры саналган, фоторәсеме Почет тактасыннан төшмәгән хатыным Миләүшәгә күрсәтә торган гадәтем бар: ул укып чыга, хаталары булса төзәтә, аннары энҗе кебек хәрефләр белән бик матур итеп ак кәгазьгә күчерә. Менә шундый пөхтә итеп, татар телендә бернинди хатасыз язылган Катай тарихын мин авылдагы ялым беткәндәрәк район газетасы редакторы Наил Кәримовка кертеп калдырдым. Һәм мин Казанда вакытта ул тиз арада басылып та чыкты.

Катай тарихына багышланган язма – кандидатлык диссертациясен яклаганнан соң минем иң беренче зур фәнни-популяр хезмәтем булды. Аннан соң район газетасында тагын берничә язма бастырдым да, төбәк тарихы буенча зуррак күләмле хезмәт язу максатын куйдым. 1995 елда урыс телендә «Очерки по истории Бакалинского района» дигән китабымны яздым. Ул китапта төбәк тарихы буенча бик күп мәгълүматлар бирелсә дә, аны тагын да тулыландырырга кирәк иде, шуңа күрә типографиядә бастыруны киләчәккә калдырдым.

Ә менә Катай тарихын зур китап итеп язарлык мәгълүматлар миндә җитәрлек иде. Ул чынлап та дистәдән артык бүлектән торган зур китаплык күләмдә язылды, 1999 елның җәенә әзер дә булды. Китапның миңа аеруча якын үзенчәлеге шунда – бик күп истәлекләр кулландым. Туксанынчы елларда инкыйлабка чаклы һәм бераз соңрак туган әби-бабайлар исән иде әле, авылга кайткан саен, алардан нәрсәдер булса язып ала торган идем. Кайбер истәлекләрне диктофонга яздырам да, аннары кампитерга күчерә идем.

1999 ел – минем өчен икеләтә шатлыклы ел буласы иде. «Гасырлар кичкән авыл» исемле беренче китабым чыкты. Катай тарихын да чыгару хәстәрен күрә башладым. Район хакимияте башлыгы Рәмис Дәүләтов мине хуплады, хәтта минем үтенеч буенча район карарын да кабул итте. Шул карарны тотып, Уфага махсус бардым, зур түрә булып эшләүче авылдашым-күршем янына кердем. Ул да хуплады, куанып Казанга кайтып киттем, типографиядән счет-фактура



алып, тагын Уфага килдем. Авылдашым кайбер башка вәгъдәсез-имансыз төрләр кебек юкка чыкты, койрыгын тотарлык түгел иде. Якташлар җәмгыяте яңа оешкан чор, аның башкарма комитеты рәисе минем авылдашым иде, инде ул да, башкалар да ярдәм итә алмагач, күңелсез уйлар белән Казанга кайтып киттем.

Мин бер генә нәрсәгә үкенәм: нәкъ шул вакытта Катай тарихын тулысынча район газетасында бастырасы калган. Үз исемнәре телгә алынган күпме авылдашларым мин язганнарны укып шатланырлар, тирән уй-хисләр кичергән булыр иде. Китап алар өчен язылды, гәзит битләреннән булса да алар китапны укырлар иде, чөнки китап язылганын белделәр, аның басылып чыгасын көттеләр. Соңлап булса да, кичерегез мине, дип әйтәсе килә. Мин тарихчы һәм үз авылын, аның тырыш-иманлы кешеләрен яраткан шәхес буларак, авылдашларым алдындагы бурычымны тулысынча үтәячәкмен: Катай тарихы район гәзите битләрендә дә, аерым китап булып та дөнья күрер, иншалла.

*22 март, 2017 ел*

## Сагынып искә алам

1999 елда минем беренче китабым – «Гасырлар кичкән авыл» – чыкты. Ул Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең туган авылы Ташлык тарихына багышланган иде. Ничектер шулай туры килде, бер кайтуымда район мәдәният сараенда якташлар очрашуы оештырылган иде. Залда минем урыным Наил Баһаутдинов белән ике кеше аркылы гына иде. Китабым үзем белән, карап чыгарга тәкъдим иттем. Тәнәфес вакытында без беренче тапкыр сөйләштек, ул визиткасын бирде, Уфада очрашырбыз дип сүз куештык.

Шуннан соң минем Уфага килүләр еш булды, килгән саен, мөмкинчелек булганда, мин аңа кермичә калмый идем. Ул үзенең нәсел тарихы белән кызыксына иде, күпсанлы архив документларын кулланып мин аның шәҗәрәсен төзеп бирдем. Бер очрашуда, бу 2001 елның көзе иде, Камышлы тарихын язу һәм китап итеп чыгару турында сөйләштек. 2002 елда авылның барлыкка килүенә 160 ел булачак, китап шул юбилей датасын күз алдында тотып әзерләнергә тиеш иде.

Минем ярты еллап чамасы вакытым бар иде, җиң сызганып эшкә керештем. Ай саен Уфа архивына килә, командировкалар арасында китапның бүлекләрен яза идем. Һәр килгәндә китапның аерым бүлекләрен Наил Баһаутдиновка танышырга-карап чыгарга калдырып китә идем. Камышлыга да барып килдем, бик күп кешеләр белән очраштым, мәгълүматлар тупладым, истәлекләр язып алдым (бу хакта тулырак шул китапның йомгак сүзендә әйтелә, шуңа аерым тукталып тормыйм). Язга чыгуга китап язылып беткән иде. Хатыным Миләүшә корректорлык хезмәтен башкарып, аны карап чыкты, хаталардан арындырды, аннары Уфа désинститутында кайчандыр Наил белән бергә эшләгән профессорга күрсәттек. Ул югары бәя бирде, беренче тапкыр авыл тарихы турында мондый зур эчтәлекле китап укуы, башкалар өчен үрнәк булуы турында әйтте.

Җәйгә кергәндә Казанда китапның макетын эшләттем, аннары аны типографиягә бастырырга тапшырдым. Камышлыда авыл юбилеена багышланган бәйрәм датасы билгеләнгән, әзерлек бара иде. Сөенечлесе шул, китап нәкъ шул көнгә әзер булды. Наил машина җибәреп, китапларны типографиядән алып, туп-туры Камышлыга кайттык. Бәйрәм ничек узган, кемнәр кайткан-килгән – бу хакта район газетасында тулы язылды, шуңа аерым тукталып тормыйм.

Сүземне йомгаклап, төп фикеремне әйтим. Әйе, китап чыкканга 15 ел вакыт үтте. Китабым әле яңа гына дөнья күргән кебек тоела, ә шул вакыт эчендә күпме нәрсәләр үзгәрде, югалтулар да булды. Китап чыгуның әһәмияте – тагын бер татар авылы үзенең тарихын белде, шул тарихны укып сөенде, бабаларын табып куанды, рәхмәт әйтте. Камышлыны китаплы иткән бу юллар авторын һәм Наил Баһаутдиновны киләчәк буыннар да искә алыр, рәхмәт укыр, иншалла.

*27 гыйнвар, 2017 ел*

# 1917 елда Иске Катай авылы хуҗалыклары

1917 елда Вакытлы хөкүмәт карары белән Россия губерналарында хуҗалыклар исәбен алу (перепись) үткәрелә. Авыл хужалыгының торышын яктырткан мәгълүматлар вәгъдә ителгән җир реформасын үткәргәндә кулланылыр дип көтелә.

Хуҗалыклар санын алуның төп нәтиҗәләре Совет хакимияте урнашкач кына бастырыла һәм тарихчылар тарафыннан киң кулланыла. Әмма алар гомумиләштерелеп губерналар һәм өязләр буенча гына бирелгәнлектән, шактый кызыклы мәгълүматлар читтә кала.

1917 елда земство статистиклары тутырган перепись карточкалары-бланкларының (һәр хуҗалык буенча) Уфа губернасына караган өлеше (Минзәлә өязеннән башка) Башкортстан Үзәк дәүләт тарих архивында (Р473 фонд) саклана.

Аларны өйрәнү шул чордагы һәр авылга һәм хуҗалыкка кагылышлы бай мәгълүмат бирә. Аерым алганда, хуҗалыклар санын, һәр хуҗалык буенча гаилә составын, шөгылен, җир мәйданын (ул дисәтинәләрдә бирелә; 1 дисәтинә = 1,09 гектар), мал-туар санын ачыклап була.

Катай авылы тарихын һәм үзенең шәҗәрәсен өйрәнүче һәркем өчен кызыклы чыганак булуын истә тотып, әлеге мәгълүматларның төп өлешен укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдым.

Исемлекләрне өйрәнгәндә укучы түбәндәге искәрмәне истә тотсын иде: архив документы начар укылу, яисә төгәл тутырылмау (мәсәлән, Солтангир урынына Солтангәрәй дип язу) аркасында, исем-фамилияләр язылышында кайбер очракта хата киткән булырга мөмкин.

Автор бу исемлекне 1990 нчы еллар уртасында халык танышсын, шуннан бабаларын тапсын дигән максаттан чыгып Катай авылы китапханәсенә тапшырган иде, авылдашларымда ул зур кызыксыну уяткан, шәҗәрәләр төзегәндә кулланалар дип әйттеләр соңыннан.

1. Фәттахетдин Камалетдинов (55 яшь), хатыны (49), 2 улы (3, 16 яшьләрдә) һәм кызы (6) белән яши; 2,79 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, сарыгы һәм кәҗәсе бар.

2. Хәбир Галимов (42), хатыны (35), 3 улы (2, 5, 7), кызы (14), атасы (70) һәм анасы (50) белән яши; 4,27 дисәтинә җире, аты, сыеры, кәҗәсе, 3 сарыгы бар.

3. Сәгура Гыймадетдинова (55), олы улы (21) сугышка алынган, кече улы (15) һәм кызы (18) белән яши; 4,30 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 7 сарыгы бар.

4. Солтангали Идрисов (30), сугышка алынган, йортында абыйсы (45), хатыны (21) яңа туган улы һәм анасы (70) калган; 4,89 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 2 сарыгы бар.

5. Миңлемөхәммәт Якупов (49), хатыны (35), 3 улы (0, 4, 11) һәм кызы (1) белән яши; 4,39 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе бар.

6. Шәймөхәммәт Шамбазов (61), 2 хатыны (40, 45), 2 улы (12, 17) һәм 4 кызы (4, 5, 8, 16) белән яши; 8,74 дисәтинә җире, аты, сыеры, 5 сарыгы бар.

7. Баһманша Ганиев (42 яшь), хатыны (25), ике абыйсы (28, 38) һәм абыйсының улы (2) белән яши; 8,62 дисәтинә җире, аты бар.

8. Миңлехан Мөхәммәтшин (38) сугышка алынган, йортында хатыны (35), улы (11) һәм кызы (10) калган; 4,08 дисәтинә җире, аты һәм кәҗәсе бар.

9. Кадермөхәммәт Мөхәммәтшин (42), хатыны (38), 2 улы (6, 12), кызы (11) һәм анасы (75) белән яши; 7,61 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 сарыгы бар.

10. Әлмөхәммәт Мөхәммәтшин (46), хатыны (40), 2 улы (3, 13) һәм кызы (10) белән яши; 4,27 дисәтинә җир эшкәртә, 2 эш аты, сыер һәм бозау асрый.

11. Габделхәбир Йосыпов (37), хатыны (25), 2 улы (7, 9) һәм 5 кызы (0, 3, 5, 6, 12) белән яши; 8,28 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

12. Габдрахман Йосыпов, хатыны (30), 3 улы (4, 7, 9) һәм 2 кызы (8, 11) белән яши; 7,35 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

13. Мортаза Мөхетдинов (58), хатыны (55), оныгы (8) һәм кызы (18) белән яши; аты, 2 сыеры, 7 сарыгы бар. Җире юк.

14. Бикмөхәммәт Әюпов (43), хатыны (42), 3 улы (2, 7, 13) һәм кызы (9) белән яши; 10,54 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

15. Миргали Тимергалин (51), хатыны (45) һәм 3 кызы (4, 12, 17) белән яши; 5,42 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы һәм 3 сарыгы бар.

16. Фазлырахман Мохтаруллин (64), хатыны (45), улы (6) һәм 2 кызы (8, 10) белән яши; 7,78 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы, 3 сарыгы бар.

17. Әхмәтгали Габдерәфиков (63), кече улы (25) сугышка алынган, хатыны (69), олы улы (29), кызы (19) һәм килене (29) белән яши; 12,09 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

18. Шаһвәли Габдерәфиков (55), хатыны (45) һәм 3 улы (10, 15, 20) белән яши; 8,35 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры, 7 сарыгы бар.

19. Латыйф Вафиев (66), 2 улы (25, 27) сугышка алынган, хатыны (63) белән яши; 6,83 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 5 сарыгы бар.

20. Солтангәрәй Мөхәммәтгәрәев (50), хатыны (35), яңа туган улы һәм 3 кызы (5, 9, 11) белән яши; 5,25 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

21. Шәйхезаман Шәяхмәтов (39), сугышка алынган, йортында хатыны (25), 2 улы (3, 6) һәм сеңлесе (17) калган; 13,12 дисәтинә җире, аты, сыеры, 6 сарыгы бар.

22. Габделгалләм Маликов (40), хатыны (35), 2 кызы (3, 10) һәм анасы (70) белән яши; 10,28 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

23. Батыргәрәй Габделгалимов (18), абыйсы (25) сугышка алынган, энесе (13) һәм 3 кыз (10, 17, 20) туганы белән яши; 5,26 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, бозавы, 3 сарыгы бар.

24. Арслангали Мөхәммәтгалимов (66), улы (36) сугышка алынган, хатыны (62), килене (25) һәм оныгы (1) белән яши; 3,49 дисәтинә җире, сыеры һәм бозавы бар.

25. Мөхәммәтзариф Вәлимөхәммәтов (75), хатыны (70) һәм улы (15) белән яши; 4,45 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 2 бозавы бар.

26. Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшин (57), хатыны (40), 3 улы (5, 16, 20) һәм кызы (10) белән яши; 4,40 дисәтинә җире, аты бар.

27. Гыйкрәмә Гаязетдинов (43), хатыны (38), 2 улы (5, 9), кызы (12) һәм анасы (65) белән яши; 18,34 дисәтинә җире, 3 аты, 3 сыеры һ.б. маллары бар.

28. Мөхәммәтхарис Насыйпов (46), хатыны (35), 4 улы (5, 8, 10, 13) һәм анасы белән яши; 6,67 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

29. Мәүләви Мөхәммәтнәбиев (47), 2 улы (20, 27) сугышка алынган, 2 кызы (12, 17) белән яши; 12,80 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

30. Мөхәммәтшәфикъ Мөхәммәтҗанов (73), улы (25) белән генә яши; 7,27 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, 3 сарыгы бар.

31. Фәхрелислам Гыйльфанов (27) сугышка алынган, йортында хатыны (20), улы (1), сеңлесе (15) һәм анасы (65) калган; 1,54 дисәтинә җире, сыеры бар.

32. Исрафил Ризванов (66), хатыны (60), улы (36), килене (25) һәм оныклары (0, 3, 7) белән яши; 7,96 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

33. Мөхәммәтсадыйк Сафин (68), улы (31) сугышка алынган, хатыны (68), килене (31) һәм 3 оныгы белән яши; 4,80 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 бозавы, 2 сарыгы бар.

34. Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтсафин (60), улы (25) белән яши; 3,87 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм 6 сарыгы бар.

35. Сәмигулла Сәйфуллин (31), сугышка алынган, йортында хатыны (28), улы (3), кызы (яңа туган) һәм анасы (70) калган; аты, 2 сыеры, 4 сарыгы, 4,80 дисәтинә җире бар.

36. Шәймөхәммәт Кәримов (32), хатыны (25) һәм 2 улы (1, 5) белән яши; 3,30 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе бар.

37. Гафиятулла Хәйруллин (60), хатыны (60) белән яши.

38. Мөхәммәди Чураголов (70), хатыны (30), улы (2) һәм кызы (яңа туган) белән яши.

39. Габдерәшит Җәмилев (30), анасы (75) белән яши; 3,62 дисәтинә җире, аты бар.

40. Мөхәммәтсадыйк Сафиуллин (61), 4 улы (19, 20, 25, 30) сугышка алынган, 2 килене (25, 30) һәм кызы (15) белән яши; 6,42 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм бозавы бар.

41. Мөхәммәтзакир Мифтахетдинов (55), хатыны (55), 2 улы (20, 25) сугышка алынган, 2 улы (7, 10) һәм кызы (14) белән яши, 6,65 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

42. Мөхәммәтзакир Шакиров (60), 3 улы (23, 25, 30) сугышка алынган, хатыны (60) һәм килене (20) белән яши; 6,07 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

43. Садретдин Сәхәбетдинов (54), олы улы (21) сугышка алынган; хатыны (45), кече улы (8) һәм кызы (4) белән яши; 0,05 дисәтинә җире, 3 кәҗәсе бар.

44. Шәйхеразый Габделихсанов (68), хатыны (63) белән генә яши; 4,28 дисәтинә җире, 2 сыеры бар.

45. Шәйхенур Шәйхелисламов (42), хатыны (35), 4 улы (1, 6, 8, 13) һәм 2 кызы (4, 10) белән яши; 4,30 дисәтинә җире, икешәр аты, сыеры, сарыгы, кәҗәсе бар. Агач эше остасы.

46. Фәрислам Габделихсанов (56), хатыны (50) һәм 2 кызы (14, 17) белән яши; 3,73 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 2 сарыгы бар. Балта остасы.

47. Нурислам Габделихсанов (50), хатыны (45), 4 улы (7, 9, 12, 14) һәм 2 кызы белән яши; 9,19 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Балта остасы.

48. Ахунҗан Шәймөхәммәтов (46), кызы (13) белән яши.

49. Габдулла Насыйров (35), хатыны (24) һәм 2 улы (3, 5) белән яши; 3,80 дисәтинә җире, аты һәм 2 сыеры бар.

50. Гыймадетдин Җамалетдинов (43), хатыны (33), 2 улы (0, 6) һәм кызы (8) белән яши; 4,25 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм кәҗәсе бар.

51. Вәлиулла Сафиуллин (50), хатыны (45) һәм кызы (12) белән яши; кәҗәсе бар. Утын кисүче, такта яручы.

52. Хисмәтулла Гыйззәтуллин (35), җире һәм мал-туары юк.

53. Мөхәммәтнур Кадерголов (50), хатыны (35), 3 улы (6, 10, 14) һәм кызы (3) белән яши; 0,25 дисәтинә җире бар. Көтүче.

54. Суфиҗан Шәймөхәммәтов (40), сугышка алынган, йортында хатыны (30), улы (12) һәм кызы (7) калган; мал-туары, җире юк.

55. Җәмил Шәнгәрәев (77), хатыны (74) белән генә яши; 4,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 6 сарыгы бар.

56. Зәйдулла Шәрифуллин (64), улы (28) сугышка алынган, хатыны (60) һәм кызы (16) белән яши; 4,28 дисәтинә җире, аты, 4 кәҗәсе бар.

57. Шәйхеәгъзам Сәхратуллин (32), 3 улы (5, 8, 10) һәм хатыны (30) белән яши; 4,29 дисәтинә җире, аты, 3 сыеры, кәҗәсе бар.

58. Әхмәтхан Мөхәммәтҗанов (57), 3 улы (20, 25, 29) сугышка алынган, хатыны (57), кызы (19) һәм килене (28) белән яши; 12,87 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче яллаган.

59. Әхмәтгәрәй Мөхәммәтгәрәев (33), 2 кызы (8, 13) һәм хатыны (30) белән яши; 5,41 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Итекләр тегә.

60. Габделвәли Габделвәлиев (87), ялгыз яши; 4,87 дисәтинә җире, аты, сыеры бар.

61. Шаһисолтан Баһманшин (37), улы (3) һәм хатыны (30) белән яши; 4,56 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

62. Фәррахетдин Мифтахетдинов (50), тәрбиягә алынган улы (12) һәм хатыны (35) белән яши; 6,97 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Дегет-сумала кайната. Даими эшче яллаган.

63. Әхтәмҗан Мөхәммәтҗанов (65), ике оныгы (1, 3) һәм кызы (22) белән яши; 0,62 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе бар.

64. Мөхәммәтшакир Мифтахетдинов (56), 6 улы (5, 6, 8, 11, 15, 20), кызы (22) һәм хатыны (48) белән яши; 2,17 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, бозавы бар.

65. Нәбиулла Кәлимуллин (48), 2 улы (19, 21) сугышка алынган, калган 4 улы (1, 7, 10 12), туганының улы (16), кызлары (3, 20) һәм 2 хатыны (20, 26) белән яши; 9,88 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Ярма яргычы бар.

66. Сираҗетдин Гыйлаҗетдинов (65), улы (26) сугышка алынган, ялгыз яши; 4,30 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 сарыгы бар.

67. Габделҗәлил Габделзаһиров (44), улы (3), 3 кызы (8, 12, 20) һәм хатыны (43) белән яши; 8,33 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

68. Сафиулла Рәхмәтуллин (65), 2 улы (25, 33) сугышка алынган, оныгы (1) һәм килене (20) белән яши; 5,05 дисәтинә җире, 2 аты, 11 сарыгы, 2 кәҗәсе бар.

69. Габдерәхим Маликов (43), хатыны (40), 3 улы (1, 4, 7) һәм 3 кызы (9, 11, 13) белән яши; 4,16 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, бозавы бар.

70. Шәйхулла Рәхмәтуллин (47), хатыны (35), улы (12) һәм 2 кызы (2, 16) белән яши; 4,29 дисәтинә җире, аты, 3 кәҗәсе бар. Йөкче.

71. Әхмәтвәли Рәхмәтуллин (35), хатыны (25), кызы (1) һәм энесе (12) белән яши; 5,05 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 4 сарыгы, 2 кәҗәсе бар.

72. Мәҗит Вафиев (35), хатыны (25) һәм улы (1) белән яши; 3,17 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сарыгы һәм кәҗәсе бар.

73. Мөхәммәтгариф Мөхәммәтнәбиев (67), олы улы (23) сугышка алынган, хатыны (55), кече улы (15) һәм өч кызы (12, 20, 25) белән яши; 4,14 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 3 кәҗәсе бар.

74. Мөхәммәтзакир Шакиров (65), улы (43) сугышка алынган, хатыны (55), килене (35) һәм оныгы (15) белән яши; 14,62 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче яллаган.

75. Исмәгыйль Ибраһимов (53), бер улы (18) сугышка алынган, хатыны (45), 4 улы (3, 7, 15, 21) һәм 3 кызы (0, 5, 10) белән яши; 4,25 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы һәм 2 сарыгы бар.

76. Мөхәммәтсолтан Сафин (54), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (35), 3 улы (1, 10, 14) һәм 2 кызы (8, 16) белән яши; 7,62 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Сәүдә итә.

77. Әлмөхәммәт Әюпов (49), хатыны (40), 2 улы (4, 9) һәм 2 кызы (12, 14) белән яши; 12,49 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

78. Мөхәммәтхафиз Гатауллин (50), хатыны (45), улы (13), кызы (13) һәм анасы (80) белән яши; 4,29 дисәтинә җире, икешәр аты, сыеры һәм сарыгы бар.

79. Исхак Сәхипов (47), хатыны (48), улы (3), 2 кызы (5, 15) һәм абыйсы (50) белән яши; 4,00 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 кәҗәсе бар.

80. Фәррахетдин Шәйхетдинов (60), хатыны (45), 2 улы (7, 10) һәм 2 кызы (14, 15) белән яши; 12,75 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Айгыр печүче.

81. Әхмәдиша Мөхәммәдишин, хатыны (65), улы (12) һәм кызы (11) белән яши; 5,81 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм сарыгы бар.

82. Шагали Шәмзаров (57), 2 улы (25, 27) сугышка алынган, хатыны (30), 2 улы (0, 4) һәм кызы (13) белән яши; 5, 75 дисәтинә җире, аты һәм кәҗәсе бар.

83. Бәдретдин Шатбәһаров (52), уртанчы улы (19) сугышка алынган, хатыны (52) һәм 2 улы (16, 22) белән яши; 6, 69 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ. б маллары бар.

84. Шәмсебану Якупова (45), 2 кызы (14, 16) белән яши; 2,19 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе бар.

85. Мөхәммәтзариф Мөхәммәтҗанов (66), хатыны (65), улы (17) һәм 2 кызы (19, 20) белән яши; 9, 66 дисәтинә җире, 3 аты, 3 сыеры һ.б. маллары бар.

86. Мөхәммәтгәрәй Гайнаншин (35), сугышка алынган, йортында хатыны (30) һәм 2 улы (8, 10) калган; 2,00 дисәтинә җирен арендага биргән, кәҗәсе бар.

87. Шәрига Ибраһимов (50), олы улы (22) сугышка алынган, хатыны (45), кече улы (12) һәм кызы белән яши; 9,63 дисәтинә җире, 2 аты, 4 сыеры һ.б. маллары бар.

88. Газиз Шәфиков (60), олы улы (26) сугышка алынган, хатыны (55), 2 улы (15, 18) һәм килене (27) белән яши; 4,93 дисәтинә җире, 4 аты һәм 7 кәҗәсе бар.

89. Габделгали Юсупов (48), олы улы (19) сугышка алынган, хатыны (35), 2 улы (9, 12) һәм 4 кызы (0, 4, 8, 16) белән яши; 5,75 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

90. Ахунҗан Муллаянов (35), сугышка алынган, йортында хатыны (31) һәм кызы (7) калган; 0,25 дисәтинә иманасын арендага биргән, аты бар.

91. Мөхәммәтнәгыйм Мөхәммәтгарифов (25), сугышка алынган.

92. Габидулла Галиуллин (60), хатыны (33), улы (3) һәм кызы (11) белән яши; 0,75 дисәтинә җире, аты һәм кәҗәсе бар.

93. Фәттахетдин Баһаутдинов (55), хатыны (33), 3 улы (5, 14, 17), кызы (2) һәм анасы (75) белән яши; 2,07 дисәтинә җире, сыеры, 2 сарыгы һәм кәҗәсе бар.

94. Галләметдин Шатбәһаров (60), ике улы (19, 28) сугышка алынган, хатыны (50) һәм 2 кызы (7, 10) белән яши; 4,36 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче тота.

95. Камалетдин Сайранов (80), олы улы (42) сугышка алынган, 2 улы (13, 15) белән яши; 4,16 дисәтинә җире бар.

96. Заһидулла Хәлиуллин (53), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (50), кече улы (17) һәм кызы (11) белән яши; 3,44 дисәтинә җире, 2 аты һәм 4 кәҗәсе бар.

97. Шәфигулла Хөснетдинов (40), хатыны (35), 2 улы (7, 10), кызы (5) һәм анасы (70) белән яши; 4,66 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы һәм 5 сарыгы бар.

98. Нәдергол Шәмиголов (76), хатыны (55), 3 улы (8, 12, 21) һәм кызы (4) белән яши; 4,00 дисәтинә җире бар, мал-туары юк. Такта яручы.

99. Мөхәммәтхарис Нурмөхәммәтов (55), бер улы (21) сугышка алынган, хатыны (50), 4 улы (3, 8, 15, 25) һәм 2 кызы (13, 17) белән яши; 10, 93 дисәтинә җире, 4 аты, 4 сыеры һәм башка маллары бар. Даими эшче яллаган.

100. Мәрдия Нәфикова (38), 2 улы (7, 20) һәм 3 кызы (7, 11, 13) белән яши; 4,34 дисәтинә җире, аты һәм кәҗәсе бар.

101. Мөхәммәтлатыйф Нәбиев (64), хатыны (25), уллары (6, 7), кызлары (1, 4) һәм эшчесе (20) белән яши; 8, 03 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Мулла.

102. Гайнулла Шәрифуллин (40), хатыны (40) һәм 2 кызы (12, 15) белән яши; 2,15 дисәтинә җире һәм 3 кәҗәсе бар.

103. Насыйфулла Фәрхетдинов (47), хатыны (60) белән генә яши. 5,96 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе бар. Такта яручы.

104. Дәүләтгәрәй Коңгырбаев (82), улы (35) сугышка алынган, хатыны (65), килене (30) һәм кызы (15) белән яши; 9,14 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 8 сарыгы һәм кәҗәсе бар.

105. Кәнжел Сәйфуллин (22), сугышка алынган, йортында анасы (70) һәм энесе (18) калган; 8,71 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

106. Сәйфетдин Шәмсетдинов (47), хатыны (35), улы (13) һәм кызы (1) белән яши; 2,64 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

107. Гайфетдин Шәмсетдинов (42), хатыны (35) һәм 2 кызы (8, 12) белән яши; 4,58 дисәтинә җире, аты һәм 3 кәҗәсе бар. Итекче.

108. Хафиз Мөгыйтаев (62), 2 улы (24, 28) сугышка алынган, хатыны (60) белән яши; 7,63 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры һ.б. маллары бар.

109. Раян Муллаянов (45), хатыны (32), улы (6), 2 кызы (3, 12) һәм бер ятим малай (15) белән яши; 3,12 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе бар.

110. Сиражетдин Яхшыголов (60), 2 улы (19, 21) сугышка алынган, хатыны (45), 3 улы (7, 11, 22) һәм 2 кызы (12, 16) белән яши; 10,07 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Такта яручы, утын кисүче.

111. Ислам Мөхәммәтсафин (49), хатыны (45), 2 улы (6, 13) һәм 2 кызы (10, 18) белән яши; 4,34 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры, бозавы, 6 сарыгы һәм 3 кәҗәсе бар.

112. Габдулла Галләмов (50), хатыны (48), 2 улы (8, 13) һәм 3 кызы (2, 5, 14) белән яши; 16,85 дисәтинә җире, 4 аты, 4 сыеры һ.б. маллары бар. Лавкасында сәүдә итә.

113. Гыймадетдин Гыйлаҗетдинов (52), хатыны (52) белән яши; 4,32 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 3 сарыгы бар.

114. Нургали Нәфиков (49), улы (20) сугышка алынган, хатыны (52) һәм 5 кызы (14, 15, 16, 17, 18) белән яши; 8,80 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сыеры һ.б. маллары бар. Җилгәргече бар.

115. Афзалетдин Могтәметдинов (45), хатыны (40), улы (10) һәм кызы (11) белән яши; 3, 78 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һәм кәҗәсе бар.

116. Әхмәтгали Мөхәммәтшин (55), хатыны (45), 2 улы (2, 7) һәм 2 кызы (6, 12) белән яши; 15,72 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче яллаган.

117. Габделбасыйр Габделхаликов (64), олы улы (24) сугышка алынган, хатыны (40), 4 улы (6, 8, 10, 20) һәм 2 кызы (12, 15) белән яши; 6,98 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 2 сарыгы бар.

118. Нурлыгаян Нәфиков (39), хатыны (35) һәм 3 улы (1, 8, 12) белән яши; 4,63 дисәтинә җире, аты һәм 5 сарыгы бар.

119. Габделбаян Галләмов (61), кече улы (23) сугышка алынган, хатыны (61), олы улы (30) һәм кызы (18) белән яши; 4,32 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

120. Лотфулла Гатауллин (16), анасы (40), 2 энесе (6, 8), 2 кыз туганы (12, 18) белән яши; 2,22 дисәтинә җире, аты һәм сыеры бар.

121. Хәбибулла Шәрифуллин (50), олы улы (26) сугышка алынган, хатыны (50) һәм 4 улы (10, 15, 18, 23) белән яши; 6,77 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

122. Шәйхулла Шәрифуллин (50), хатыны (40), улы (6) һәм кызы (3) белән яши; 2,08 дисәтинә җире, 2 сарыгы һәм 3 кәҗәсе бар. Кара эшче.

123. Гарифулла Шәрифуллин (43), хатыны (40), 2 улы (5, 12) һәм кызы (14) белән яши; 4,32 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

124. Кашшафетдин Габделвәлиев (64), хатыны (48), 4 улы (0, 3, 6, 10) һәм кызы (12) белән яши; 5,82 дисәтинә җире, 4 аты, 3 сыеры һ.б. маллары бар.

125. Габделкадыйр Габделхаликов (67), олы улы (28) сугышка алынган, хатыны (50) һәм 3 улы (12, 19, 26) белән яши; 7,06 дисәтинә җире, аты, 3 сыеры, 8 сарыгы бар. 2 улы һәм үзе такта яручы.

126. Шәмсемөхәммәт Ситдыйков (38), хатыны (25), улы (4) һәм кызы (3) белән яши; 2,06 дисәтинә җире, 4 сарыгы һәм кәҗәсе бар.

127. Хөснулла Хөснетдинов (48), олы улы (21) сугышка алынган, хатыны (40), 4 улы (5, 10, 17, 19) һәм кызы (6) белән яши; 2,43 дисәтинә җире, аты һәм 3 кәҗәсе бар.

128. Шәймөхәммәт Кәримов (75), хатыны, 3 улы һәм 2 кызы белән яши; 9,00 дисәтинә җире, 6 баш умартасы, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

129. Төхвәтулла Хөснетдинов (59), хатыны (45), улы (16) һәм 3 кызы (2, 9, 17) белән яши; 4,18 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 4 сарыгы бар. Такта яручы.

130. Шәрәфетдин Җамалетдинов (46), хатыны (40), 4 улы (10, 12, 14, 20) һәм 3 кызы (0, 4, 18) белән яши; 4,22 дисәтинә җире, аты h.б. маллары бар. Кара эшче.

131. Шәйхетдин Фәрхетдинов (70), 2 улы (25, 35) сугышка алынган, хатыны (60), кызы (20), килене (25), оныгы (3) белән яши; 8,55 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 5 сарыгы бар.

132. Габделҗәмил Галләмов (50), кече улы (22) сугышка алынган, хатыны (50), олы улы (25) һәм кызы (14) белән яши; 6,99 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры h.б. маллары бар. Хезмәтче тота.

133. Гыйльметдин Низаметдинов (47), хатыны (37), 5 улы (4, 6, 9, 14, 18) һәм кызы (2) белән яши; 2,81 дисәтинә җире бар, маллары юк.

134. Фазлыйәхмәт Нуриәхмәтов (20), 2 сеңлесе (12, 18) белән яши.

135. Гайса Галләмов (54), олы улы (24) сугышка алынган, хатыны (40), 2 улы (1, 9) һәм 3 кызы (2, 7, 11) белән яши; 11,78 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры h.б. маллары бар. Хезмәтче яллаган.

136. Афзалетдин Гыймадетдинов (43), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (40), кече улы (16) һәм 4 кызы (7, 9, 12, 17) белән яши; 18,01 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры h.б. маллары, җилгәргече бар; хезмәтче яллаган.

137. Сираҗетдин Гыймадетдинов (45), хатыны (35), 4 улы (9, 12, 15, 18) һәм кызы (1) белән яши; 16,25 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры h.б. маллары, җилгәргече бар. Хезмәтче яллаган.

138. Мөхәммәтдин Камалетдинов (48), хатыны (35) һәм 2 улы (9, 15) белән яши; 1,43 дисәтинә җире, 2 аты һәм кәҗәсе бар. Такта яручы.

139. Шәйдулла Хәлиуллин (62), улы (25) сугышка алынган, хатыны (57) белән яши; 0,81 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе бар.

140. Солтан Гәрәев (39), сугышка алынган, йортында хатыны (30), 2 улы (9, 12) һәм кызы (3) калган. Балта остасы.

141. Гыйндулла Хөснетдинов (45), хатыны (42), улы (5) һәм 3 кызы (3, 7, 10) белән яши; 2,65 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һәм 2 кәҗәсе бар.

142. Әхмәтвәли Халиков (62), улы (24) сугышка алынган, хатыны (35) һәм 3 кызы (3, 4, 9) белән яши; 4,26 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм кәҗәсе бар.

143. Әхмәдулла Габдуллин (28), хатыны (19), энесе (25) һәм анасы (70) белән яши; 3,79 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 3 сарыгы бар.

144. Шәрәфетдин Хисаметдинов (85), улы (41) сугышка алынган, килене (42) белән яши; 5,96 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 сарыгы һәм 2 кәҗәсе бар.

145. Кадермөхәммәт Мөхәммәтситдыйков (34), хатыны (20) һәм улы (1) белән яши; 2,17 дисәтинә җире бар, маллары юк. Утын кисүче, такта яручы.

146. Мөхәммәтнәби Ханнанов (72), хатыны (55), улы (12) һәм кызы (7) белән яши; 9,28 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры, 4 сарыгы һәм 2 кәҗәсе бар.

147. Бикмөхәммәт Ситдыйков (42), хатыны (25) белән генә яши; 4,26 дисәтинә җире бар, мал-туары юк.

148. Мөхәммәтситдыйкъ Ханнанов (77), улы (24) сугышка алынган, хатыны (65) белән яши; 8,57 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 2 кәҗәсе бар.

149. Габделихсан Газизов (33), хатыны (28) белән яши; 1,31 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 кәҗәсе бар.

150. Фәррахетдин Гыйлаҗетдинов (65 яшь), 2 улы (22, 42) сугышка алынган, хатыны (65), килене (42) һәм оныклары (5, 10) белән яши; 16,06 дисәтинә җире, 5 аты, 3 сыеры һ.б. маллары, җилгәргече бар. Хезмәтче яллаган.

151. Мөхәммәтсафа Вәлимөхәммәтов (59), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (55), 3 улы (4, 7, 16) һәм 2 кызы (11, 13) белән яши; 14,84 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче тота, умартачылык белән шөгыльләнә.

152. Мөхәммәтсадыйк Вәлимөхәммәтов (62), улы (20) сугышка алынган, хатыны (60) һәм кызы (23) белән яши; 4,29 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

153. Фәхретдин Гыймадетдинов (61), олы улы (22) сугышка алынган, хатыны (52) һәм кече улы (9) белән яши; 4,11 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

154. Мохтарулла Рәхмәтуллин (65), хатыны (45), 3 улы (5, 9, 18) һәм 2 кызы (3, 14) белән яши; 4,23 дисәтинә җире, 3 аты һ.б. маллары бар.

155. Борһанетдин Габделвәлиев (72), улы (25) сугышка алынган, хатыны (57) белән яши; 9,16 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар. Даими эшче яллаган.

156. Әхмәтгәрәй Мифтахетдинов (66), хатыны (44), 2 улы (3, 6) һәм кызы (40) белән яши; 15,56 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һәм 5 сарыгы бар.

157. Гаязетдин Насыров (74), улы (22) һәм кызы (15) белән яши; 2,80 дисәтинә җире, аты бар. Утын кисүче, такта яручы.

158. Галләметдин Гыйлаҗетдинов (66), хатыны (63), 2 улы (22, 35) һәм кызы (19) белән яши; 6,59 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

159. Әбелнәгыйм Хаҗипов (13), ялгыз яши.

160. Исмәгыйль Миңлегалиев (60), 2 олы улы (24, 28) сугышка алынган, хатыны (55), 2 кече улы (10, 12) һәм 2 кызы (6, 16) белән яши; 4,23 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

161. Муллагали Ибраһимов (30), сугышка алынган, йортында хатыны (28) һәм кызы (4) калган; аты бар.

162. Зиннур Ибраһимов (45), хатыны (35), 2 улы (9, 11) һәм 2 кызы (0, 4) белән яши; 7,12 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Даими эшче яллаган.

163. Саяфетдин Бәдретдинов (32), хатыны (30), 2 улы (7, 9), 2 кызы (3, 7), энесе (20), сеңлесе (19) һәм анасы (62) белән яши; 15,93 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче яллаган.

164. Шәйхелислам Рахманколов, хатыны (25), 2 улы (8, 12) һәм 4 кызы (2, 5, 7, 14) белән яши; 2,50 дисәтинә җире һәм аты бар.

165. Әхмәтвәли Җәләлетдинов (54), хатыны (35), 6 улы (3, 6, 10, 12, 18, 21) һәм кызы (7) белән яши; 7,68 дисәтинә җире, 2 аты һәм 2 кәҗәсе бар. 2 улы утын кисүче.

166. Мөхәммәди Мөхәммәтгалин (80), улы (37) сугышка алынган, хатыны (80), килене (30), оныгы (3) һәм кызы (50) белән яши; 1,76 дисәтинә җире, аты һәм 4 кәҗәсе бар.

167. Әхмәдулла Авзалетдинов (15), анасы (40) һәм сеңлесе (7) белән яши; 1,05 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм кәҗәсе бар.

168. Әбүбәкер Йосыпов (54), хатыны (52) һәм 3 улы (5, 13, 21) белән яши; 6,99 дисәтинә җире, 3 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

169. Госман Йосыпов (50), улы (21) һәм хатыны (40) белән яши; 3,12 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

170. Мөхәммәтзәет Шәфиков (47), хатыны (47) һәм кызы (40) белән яши; 3,55 дисәтинә җире, аты, сыеры, бозавы һәм 2 сарыгы бар.

171. Муллагали Галиуллин (50), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (43), кече улы (1) һәм 5 кызы (4, 6, 13, 16, 21) белән яши; 8,62 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Эшче тота. Мулла.

172. Мөхәммәтхарис Мөхәммәтшин (49), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (45), кече улы (12) һәм кызы (9) белән яши; 10,72 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Даими эшче яллаган.

173. Ямьмөхетдин Батыршин (39), хатыны (35) һәм 3 улы (4, 6, 9) белән яши; 1,04 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе бар.

174. Муллаян Әхдиманов (41?), хатыны (40), 3 улы (0, 3, 13) һәм 2 кызы (5, 17) белән яши; 0,37 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе бар.

175. Мирсәгыйт Зарипов (35), хатыны (35), 3 улы (0, 8, 12) һәм кызы (7) белән яши; 7, 04 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һәм сарыклары бар.

176. Мөхәммәтхәлим Шәймөхәммәтов (41), сугышка алынган, йортында хатыны (28), улы (8) һәм кызы (10) калган; 0,29 дисәтинә җире бар, мал-туары юк.

177. Мөхәммәтнасыйп Сафиуллин (38), сугышка алынган, йортында хатыны (28) калган.

178. Әхмәтлатыйф Шәфиков (30), сугышка алынган, йортында хатыны (25), яңа туган улы һәм кызы калган.

179. Мөхәммәтшакир Шәфиков (37), хатыны (35), улы (1) һәм 2 кызы (3, 5) белән яши; 3,30 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм сарыгы бар.

180. Хәйдәргали Сайранов (31), сугышка алынган, йортында анасы (64) һәм хезмәтчесе (55) калган; 17,10 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

181. Мөхәммәтдин Мөхәммәтсафин (42), хатыны (37), 2 улы (5, 10), 3 кызы (1, 9, 13) һәм туганының улы (15) белән яши; 4,82 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм кәҗәсе бар.

182. Сәмигулла Габдуллин (35). Авылдан чыгып киткән, йортында хатыны (35) калган.

183. Нургали Мөхәммәдиев (44), хатыны (40), 2 улы (10, 14) һәм 3 кызы (1, 5, 8) белән яши; 2,50 дисәтинә җире, аты, сыеры бар.

184. Малик Басыйров (35), сугышка алынган, йортында хатыны (35) калган.

185. Фәхретдин Җәләлетдинов (42), хатыны белән яши; 1,55 дисәтинә җире бар. Итекче.

186. Сәлимгәрәй Кадыйров (43), сугышка алынган, йортында хатыны (40), 3 улы (0, 5, 8) һәм 2 кызы (11, 15) калган; 2,12 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 2 сарыгы бар.

187. Ислам Гатиятуллин (32), хатыны (30), улы (6) һәм кызы (4) белән яши; 0,62 дисәтинә җире һәм 4 кәҗәсе бар.

188. Госмангали Габделвәлиев (44), хатыны (40), 2 улы (7, 14) һәм 4 кызы (8, 9, 11, 16) белән яши; 3,06 дисәтинә җире һәм аты бар.

189. Мифтахетдин Җәләлетдинов (42), хатыны (40), улы (11) һәм 3 кызы (0, 6, 8) белән яши; 6,61 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

190. Гыйльметдин Хасбиранов (42), сугышка алынган, йортында хатыны (40), улы (1) һәм кызы (4) калган.

191. Фәтхетдин Шәрәфетдинов (50), хатыны (48), улы (7) һәм 2 кызы (1, 12) белән яши; 0,06 дисәтинә бәрәңге бакчасы, 3 сарыгы һәм кәҗәсе бар.

192. Ихсан Сахиков (46), хатыны белән яши; 0,04 дисәтинә бәрәңге бакчасы бар.

193. Идиятулла Заяратуллин (42), сугышка алынган, йортында хатыны (40), 2 улы (1, 9) һәм 3 кызы (4, 7, 12) калган; 1,31 дисәтинә җире, сыеры һәм кәҗәсе бар.

194. Шәрифулла Заяратуллин (52), хатыны (40), улы (2) һәм 2 кызы (11, 16) белән яши; 0,56 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе бар.

195. Хөрмәтулла Габдуллин (41), сугышка алынган, йортында хатыны (35) һәм 2 кызы (5, 7) калган; җире һәм мал-туары юк.

196. Хәйдәр Кадыйров (34), сугышка алынган, йортында хатыны (25) гына калган; аты бар.

197. Әсма Шакирова, авылдан чыгып киткән.

198. Әхмәтлатыйф Нәбиев (57), 2 улы (20, 27) сугышка алынган, хатыны (48), 2 улы (15, 18) һәм 2 кызы (4, 9) белән яши; 7,62 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары, 2 баш умартасы бар.

199. Исхак Ибраһимов (41), хатыны (35), улы (3) һәм яңа туган кызы белән яши; 1,55 дисәтинә җире, аты һәм 2 кәҗәсе бар. Утын кисүче, такта яручы.

200. Мөхәммәтнәдер Зарипов (42), хатыны (40), 4 улы (7, 9, 11, 18) һәм 3 кызы (1, 5, 14) белән яши; 4,58 дисәтинә җире, аты, сыеры һәм 5 сарыгы бар.

201. Сабир Хафизов (39), сугышка алынган, йортында хатыны (35), улы (9) һәм 3 кызы (1, 5, 8) калган; 2,12 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 2 бозавы һәм сарыгы бар.

202. Насыйр Шәфиков (49), хатыны (47), 2 улы һәм 3 кызы (8, 10, 14) белән яши; 3,32 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һәм 2 сарыгы бар.

203. Мөхәммәтназыйф Шәфиков (55), хатыны (45), улы (2) һәм 2 кызы (10, 16) белән яши; аты бар. Утын кисеп, такта ярып йөри.

204. Хаҗиәхмәт Мөхәммәтнәбиев (44), хатыны (44), 2 улы (8, 13), 3 кызы (2, 6, 16) һәм бер хезмәтчесе (41) белән яши; 18,93 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

205. Миргали Муллагалиев (35), хатыны (27), улы (3) һәм 3 кызы (2, 5, 7) белән яши; 12,88 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче тота, җилгәргече бар. Мулла.

206. Шәйсолтан Шәрәфетдинов (39), хатыны (35), 2 улы (2, 7) һәм кызы (5) белән яши; 0,72 дисәтинә җире, 2 сарыгы һәм кәҗәсе бар. Балта остасы.

207. Кәшфетдин Мөхәммәдиев (39), хатыны (30) һәм улы (2) белән яши. 1,05 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе бар.

208. Мөхәммәтбәдигъ Шәфиков (42), хатыны (35) һәм 2 кызы (2, 9) белән яши; 0,66 дисәтинә җире, 2 аты, 4 сарыгы һәм 2 кәҗәсе бар.

209. Нуретдин Борһанетдинов (39), сугышка алынган, йортында хатыны (30) һәм 2 улы калган; 1,54 дисәтинә җире, аты һәм кәҗәсе бар.

210. Әхмәтсафа Әхмәтгәрәев (33), сугышка алынган, йортында хатыны (30) һәм 3 улы (1, 4, 6) калган; 13,56 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

211. Нургали Шәйхеразыев (43), хатыны (40), 2 улы (4, 9) һәм 2 кызы (1, 13) белән яши; 2 аты һәм 2 кәҗәсе бар.

212. Габдрахман Шәйхеразыев (28), хатыны (25) һәм 3 улы (0, 4, 7) белән яши; кәҗәсе бар.

213. Шәйхерам Шәймөхәммәтов (35), сугышка алынган, йортында хатыны (24) калган; 0,55 дисәтинә җире, сыеры, 2 сарыгы һәм кәҗәсе бар.

214. Фәттахетдин Бәдретдинов (39), сугышка алынган, йортында хатыны (36), улы (10) һәм 3 кызы (3, 6, 12) калган; 2,18 дисәтинә җире, аты һәм 3 сарыгы бар.

215. Мөхәммәтша Шәрәфетдинов (38), хатыны (18) белән яши; 0,55 дисәтинә җире һәм аты, сарыгы бар. Утын кисеп, такта ярып йөри.

216. Җәләлетдин Гаязетдинов (49), хатыны (40), 3 улы (1, 7, 13) һәм кызы (15) белән яши; 1,05 дисәтинә җире, 2 аты һәм 3 кәҗәсе бар.

217. Әбелфатыйх Гафиятуллин (34), хатыны (28) һәм 2 улы (4, 6) белән яши; 2,80 дисәтинә җире, 2 аты һәм 2 кәҗәсе бар. Слесарь, тимерче; үзенең тимерчелеге бар.

218. Кәраметдин Кашшафетдинов (20), анасы (65) белән яши; 1,00 дисәтинә җире һәм аты бар. Утын кисүче, такта яручы.

219. Шәех Әхмәдишин (36), сугышка алынган, йортында хатыны (25) калган; 3,75 дисәтинә җире, сарыгы һәм 2 кәҗәсе бар.

220. Госмангали Мөхәммәтшәрипов (38), энесе (25) сугышка алынган, хатыны (24) һәм 3 кызы (1, 3, 7) белән яши; 2,16 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар. Такта яручы.

221. Гомәр Йосыпов (46), 2 улы (21, 23) сугышка алынган, хатыны (43), кече улы (6) һәм 4 кызы (7, 9, 12, 14) белән яши; 10,13 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Ит сәүдәсе белән шөгыльләнә. Хезмәтче яллаган.

222. Мөхәммәтнәби Вәлиев (52), хатыны (30) һәм 3 улы (2, 9, 13) белән яши. Такта яручы.

223. Ислам Габделвәлиев (40), сугышка алынган, йортында хатыны (30) һәм 2 кызы (13, 15) калган; 0,30 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

224. Шәйхезаман Вәлиәхмәтов (44), хатыны (45), 2 улы (9, 12) һәм 2 кызы (6, 14) белән яши; 14,41 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Итекләр тегә. Хезмәтче яллаган.

225. Мөхәммәтхарис Шәрәфетдинов (44), хатыны (30), улы (1), 2 кызы (5, 9) һәм сеңлесе (17) белән яши; 16,02 дисәтинә җире, 4 аты, 2 сыеры, 8 сарыгы, 3 кәҗәсе, 2 баш умартасы бар. 1 елга хезмәтче яллаган. Мулла.

226. Хисаметдин Галләметдинов (30), сугышка алынган, йортында хатыны (25) һәм улы (1) калган; сыеры бар.

227. Миңлегалим Җәмилев (44), хатыны (35) һәм 2 улы (8, 12) белән яши; 2,06 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе бар. Чабатачы.

228. Сабир Шәймөхәммәтов (36), хатыны (25), улы (1), кызы (4) һәм анасы (65) белән яши; 2 кәҗәсе бар.

229. Шәкүр Заһиров (38) сугышка алынган, йортында хатыны (32), 3 улы (2, 6, 9) һәм кызы (10) калган; 3,04 дисәтинә җире, аты, сыеры, 7 сарыгы һ.б. маллары бар.

230. Мөхәммәтша Дәүләтшин (60), туганының улы (15) белән яши; мал-туары, җире юк.

231. Хәйретдин Камалетдинов (35), сугышка алынган, йортында хатыны (30) һәм 2 кызы (4, 8) калган; сыеры бар.

232. Ильяс Ибраһимов (35), хатыны (30), улы (10) һәм 2 кызы (4, 8) белән яши; 4,37 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры бар.

233. Мөхәммәтгәрәй Гайнаншин (38), сугышка алынган, йортында хатыны (35) һәм 2 улы (5, 7) калган; иманасын арендага биргән.

234. Вахит Вафиев (50), хатыны (50) һәм кызы (10) белән яши; 1,75 дисәтинә җире бар. Көтүче.

235. Мөхәммәтмәҗит Кәримов (40), хатыны һәм 2 кызы (3, 8) белән яши; 2,18 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе бар.

236. Әхмәтнәгыйм Бәдретдинов (34), сугышка алынган, хатыны (30) белән яши; мал-туары, җире юк.

237. Миңлехәлим Хәлиуллин (65), олы улы (25) сугышка алынган, хатыны (60), кече улы (22) һәм кызы (15) белән яши; 4,42 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар.

238. Габдулла Фәрхетдинов (55), хатыны (40), улы (8) һәм кызы (4) белән яши; мал-туары, җире юк. Такта ячучы.

239. Мөхәммәтсафа Ситдыйков (44), хатыны (44) һәм улы (14) белән яши; 6,54 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

240. Мөэмин Маликов (50), олы улы (21) сугышка алынган, хатыны (50), кече улы (15) һәм 2 кызы (7, 10) белән яши; 2,67 дисәтинә җире, 2 аты, 2 колыны, 8 сарыгы бар.

241. Мөхәммәтхарис Һадипов (46), хатыны (35), 3 улы (2, 7, 12) һәм 2 кызы (5, 13) белән яши; 2,80 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе бар. 1771елда туган.

242. Имаметдин Камалетдинов (40), олы улы (20) сугышка алынган, хатыны (45) һәм кече улы (4) белән яши; 4,26 дисәтинә җире, аты бар.

243. Шәрәфетдин Шатбәһаров (77), хатыны (56) белән яши; 1,39 дисәтинә җире, 3 сарыгы бар. Чабатачы.

244. Хәйдәр Шакиров (45), хатыны (30), 4 улы (6, 9, 12, 17) һәм кызы (16) белән яши; 7,08 дисәтинә җире, 3 аты һ.б. маллары бар.

245. Хәсән Хәйруллин (40), сугышка алынган, йортында хатыны (38) һәм анасы (70) калган; 4,33 дисәтинә җире, аты, сыеры, 2 сарыгы, кәҗәсе бар.

246. Габделбаян Сәхипов (62), 2 улы (25, 38) сугышка алынган, хатыны (64), килене (28) һәм оныгы (3) белән яши; 4,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

247. Нургали Миңлегалиев (40), хатыны (38) белән яши; 3,87 дисәтинә җире, сыеры һәм бозавы бар.

248. Шәйхулла Хәлиуллин (50), хатыны (47) һәм кызы (4) белән яши; 2,19 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе бар.

249. Әхәзулла Шаһиәхмәтов (70), хатыны (40), улы (35), килене (20) һәм 2 кызы (6, 9) белән яши; 5,19 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе бар. Итекче.

250. Сәмигулла Равилов (20), сугышка алынган, йортында анасы (70) калган; 1,55 дисәтинә җире бар.

251. Нафтука (?) Габделганиев (70), ялгыз яши; 1,42 дисәтинә җире, 2 сыеры, бозавы бар.

252. Гыйззенур Мөхәммәтзакирова (27), 3 кызы (2, 5, 7) белән яши; 4,57 дисәтинә җире, 2 аты, 3 сарыгы бар.

253. Әхмәтхан Дәүләтбаев (30) сугышка алынган, йортында хатыны (25) һәм кызы (3) калган, 1,45 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе бар.

254. Шәех Дәүләтбаев (38), хатыны (36) һәм 3 улы (0, 5, 12) белән яши; 2,63 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе бар. Такта яручы.

255. Дәүләтгир Дәүләтбаев (54), хатыны (50) һәм кызы (12) белән яши; 3,93 дисәтинә җире, аты, 2 кәҗәсе бар. Такта яручы.

256. Салих Шәрипов (54), авылдан чыгып киткән.

257. Хәбир Насыйров, авылдан чыгып киткән.

258. Хафизвәли Мөхәммәтов, авылдан чыгып киткән.

259. Габделлатыйф Гаянов, авылдан чыгып киткән.

260. Нургали Сафин (48), хатыны (50), 2 улы (14, 16) һәм кызы (18) белән яши; 1,68 дисәтинә җире, аты бар. Көтүче.

261. Кашшафетдин Шәйхетдинов, авылдан чыгып киткән.

262. Сираҗетдин Камалетдинов, авылдан чыгып киткән.

263. Садретдин Камалетдинов, авылдан чыгып киткән.

264. Сәмигулла Сәйфуллин (30), сугышка алынган, йортында хатыны (28), 2 улы (5, 7) һәм кызы (3) калган; 3,52 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

265. Галиәхмәт Галиуллин, авылдан чыгып киткән.

266. Гыйндулла Габдуллин, ике иманасын арендага биреп, авылдан чыгып киткән.

267. Хәерзаман Вәлиәхмәтов (41), хатыны (38), 3 улы (0, 6, 9), 2 кызы (7, 12) һәм сеңлесе (25) белән яши; 4,90 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

268. Миңлехан Тәхаутдинов (57), 2 улы (13, 20) һәм кызы (15) белән яши; 3,19 дисәтинә җире, аты бар.

269. Шәрәфетдин Камалетдинов (50), авылдан чыгып киткән.

270. Габдулла Фазлыйәхмәтов (38), сугышка алынган, йортында хатыны (30), 2 улы (5, 8) һәм анасы (70) калган; 4,67 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры, 3 сарыгы бар.

271. Габдрахман Фазлыйәхмәтов (44), хатыны (43), улы (16) һәм 2 кызы (5, 9) белән яши; 5,34 дисәтинә җире, аты, сыеры һ.б. маллары бар.

272. Әхмәтзариф Фазлыйәхмәтов (35), хатыны (25) һәм кызы (2) белән яши; 6,10 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры һ.б. маллары бар. Итекләр тегә.

273. Мөхәммәтсадыйк Хаҗипов (40), хатыны (25) һәм кызы (3) белән яши; 2,74 дисәтинә җире һәм кәҗәсе бар.

274. Нуримөхәммәт Хаҗипов (45), хатыны (25), 2 сеңлесе (8, 15) һәм энесе (17) белән яши; 3,42 дисәтинә җире, аты, кәҗәсе бар. Энесе хезмәтче булып ялланган.

275. Заһиретдин Әдһәмов (49), хатыны (45), 3 улы (0, 7, 18) һәм 2 кызы (7, 11) белән яши; 8,62 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар. Хезмәтче яллаган.

276. Хәйретдин Әдһәмов (44), хатыны (30), 2 улы (3, 6) һәм кызы (3) белән яши; 1,24 дисәтинә җире һәм 2 кәҗәсе бар.

277. Хөҗҗәт Әдһәмов (35), сугышка алынган, йортында хатыны (30) һәм улы (3) калган; 1,4 дисәтинә җире бар.

278. Мөсәлимвәли Әхмәтов (25), ялгыз яши; 4,21 дисәтинә җире бар. Итекче.

279. Галиәхмәт Нәдерголов (31), сугышка алынган, йортында хатыны (39), улы (7) һәм кызы (5) калган; 0,78 дисәтинә җире бар.

## 1917 елда Яңа Катай авылы хуҗалыклары

1. Дәүләтгани Дәүләтгәрәев (43 яшь), хатыны (37) һәм 5 улы (10, 12, 13, 14, 15) белән яши; 9,37 дисәтинә җире, 2 аты, сыеры, 6 сарыгы бар.

2. Садретдин Гайнетдинов (67), улы (35) сугышка алынган, хатыны (65), килене (35) һәм 2 оныгы (3, 10) белән яши; 9,54 дисәтинә җире, 3 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

3. Гыймадетдин Гаязетдинов (24), сугышка алынган, йортында хатыны (20) һәм кызы (2) калган; 2,52 дисәтинә җире, аты һ.б. маллары бар.

4. Гыймадетдин Сәйфуллин (75), улы (39) сугышка алынган, хатыны (75), кызы, килене (35) һәм 2 оныгы (2, 10) белән яши; 5,80 дисәтинә җире бар, маллары юк.

5. Гали Әхмәтвәлиев (25), үзе һәм энесе (22) сугышка алынган, йортында анасы (65) һәм икенче энесе (16) калган; 11,58 дисәтинә җире, 2 аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

6. Миңлеханнан Әхмәтвәлиев (35), сугышка алынган, йортында хатыны (30), улы (9) һәм кызы (5) калган; 0,77 дисәтинә җире, аты һ.б. маллары бар.

7. Әхмәтнәби Әхмәтвәлиев (41), хатыны (37) һәм 6 улы (3, 5, 7, 9, 11, 13) белән яши; 8,30 дисәтинә җире, аты, 2 сыеры һ.б. маллары бар.

